# ТЮРКСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ

## ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ

# ТӨРКИ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ

## ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ ПЕРСПЕКТИВАЛАР

# TURKIC LINGUISTIC CULTUROLOGY

## PROBLEMS AND PERSPECTIVES

Казань-Казан-Kazan
2022

**ТЮРКСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ:**
**ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ**
материалы XIII Международной научно-практической конференции
учащихся, студентов и аспирантов
Казань, 21 февраля 2022 года

**ТӨРКИ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ:**
**ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ ПЕРСПЕКТИВАЛАР**
гомуми урта, махсус урта һәм югары белем бирү йортларында
укучыларның XIII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе
материаллары
Казан, 21 февраль, 2022 ел

**TURKIC LINGUISTIC CULTUROLOGY:**
**PROBLEMS AND PERSPECTIVES**
the proceedings of the XIII International Scientific and Practical Conference
for pupils, undergraduate and postgraduate students
Kazan, 21 February, 2022

КАЗАНЬ – КАЗАН – KAZAN
2022

УДК 811.512.1
ББК 81.2
Т98

НАУЧНЫЙ РЕДАКТОР
доктор филологических наук, профессор Р.Р. Замалетдинов

ФӘННИ МӨХӘРРИР
филология фәннәре докторы, профессор Р.Р. Җамалетдинов

SCIENCE EDITOR
Doctor of Philology, Professor R.R. Zamaletdinov

**Т98 Тюркская лингвокультурология: проблемы и перспективы:** материалы XIII Международной научно-практической конференции учащихся, студентов и аспирантов (Казань, 21 февраля 2022 года) / сост. Р. С. Нурмухаметова. – Казань, 2022. – 404 с.

**Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар:** гомуми урта, махсус урта һәм югары белем бирү йортларында укучыларның XIII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Казан, 21 февраль, 2022 ел) / төз. Р. С. Нурмөхәммәтова. – Казан, 2022. – 404 б.

**Turkic Linguistic Culturology: Problems and Perspectives:** the proceedings of the XIII International Scientific and Practical Conference for pupils, undergraduate and postgraduate students (Kazan, 21 February, 2022). – Kazan, 2022. – 404 p.

**ISBN 978-500130-021-2**

В сборник включены материалы исследований участников конференции, связанные с изучением тюркских языков и литератур, взаимоотношения языка и общества, культуры.

Ответственность за достоверность информации возлагается на авторов и научных руководителей.

Җыентыкта конференциядә катнашучыларның төрки телләр һәм әдәбиятлар, тел һәм җәмгыять, мәдәният белән бәйле мәсьәләләрне өйрәнү юнәлешендәге эзләнүләре, фикерләре урын алды.

Материалларның эчтәлеге, фактларның дөреслеге өчен авторлар һәм фәнни җитәкчеләр җавап бирә.

The collection includes materials of research related to the study of Turkic languages and literatures, the relationship between language and society, language and culture.

The authors and academic advisors are responsible for the accuracy of the information.

© Казанский федеральный университет, 2022
© Институт филологии и межкультурной коммуникации, 2022

# I кисәк.

## “КАРТ ШОМЫРТ ХАТИРӘСЕ” ӘСӘРЕНДӘ ОБРАЗЛАР БИРЕЛЕШЕ

*Әүхәдеев И.,Саба р-ны, Шәмәрдән лицее, X сыйныф*
*Җит. – Әүхәдеева А.В.*

Р.Шәйдуллинаның һәр әсәрендә кеше язмышы һәм хисләр бирелеше югары дәрәҗәдә бирелә. Образлар чынбарлыктан алына, аларның һәрберсенең үз язмышы, кичерешләре. Мин дә бу фәнни хезмәтемдә кеше язмышы мәсьәләләрне хәл итү, тарихи вакыйгаларның дөреслеген тикшерү өчен якташ шагыйрәләребезнең иҗатыннан җавап эзләргә булдым. Алга таба да әсәргә күзәтү ясап, тарих һәм аның кеше язмышына тәэсире мәсьәләсе ничегрәк бирелүен ачыкларга телим, киләчәктә дә әлеге теманы өйрәнүне дәвам итәргә уйлыйм.

Вакыйга шагыйрәнең туган авылы Аланда бара. Репрессияләрнең золымның канлы тәгәрмәче аның үз нәселен, укымышлы, затлы, булдыклы Котдус картның, Муратовларның ишле гаиләләрен таптап, сытып уза.Романда төп вакыйгалар Габдрахман хәлфә гаиләсенең Себергә сөрелүе белән башлана. Әсәрдә образлар бирелеше автор тарафыннан бик көчле бирелгән. Габдрахман абый һәм Зөһрә апаны гына алыйк. Нинди көчле ихтыярлы,тормыш авырлыкларын сыкрап булса да үтә алалар, балаларына көч бирәләр,киләчәккә өметне югалтмыйлар. “Зөһрә исә, һавасызлыктан, сусаудан тәмам интегеп, аңкы-миңке килеп ята. Ялантау чишмәсе җырлый-җырлый ага.Зөһрә саф чишмә суын туктый алмыйча эчә...” [4: 44-45]. Йөзембикә образы әсәрнең үзәк урынын алып тора.Бу образда көчлелек, серлелек, ныклылык сизелә. “Йөзембикә абыстай безне коткарыр өчен күктән төшкән бер фәрештә инде ул” [4: 138]. Әсәрдә, гомумән, башка образлар да аерым бер урынны алып тора. Мәсәлән, Әминә, Усман, Гөлҗамал, Мифтахетдин, Факиһә, Әсмабикә, Гарифҗан, Зөлхиҗә. Боларның барысы да Себер далаларында газап чигеп, туган якларына кайтырга хыялда гына яшәп, чит җирдә – еракта ятып калган. Романда үзәкне өзүче образларның берсе – Гәрәй. Ул кечкенәдән әти-әнисен югалтып, чак үлемнән калган бала. Сабый адаша, поездга утырганда апасыннан аерыла, кая барырга белми. Ләкин аны Аллаһ ташламый, рус кешесе таба, тәрбияли, ул бөек галим була, туганнарын гомере буе эзли һәм таба, нәселен, динен, халкын онытмый. Әйе, монда һәр авыл– үзе тарих, һәр кеше – үзе китап язарлык язмыш. “Авылга ямь биреп торган мәчет, башы киселгән пәһлеван кебек, нәүмизләнеп, моңаеп калды. Халык әйтерсең миңгерәүләнгән, диваналанган. Инде куыласылар куылып, үтерелергә тиешлеләр үтерелеп, таланасы

таланып беткән. Авылга хәерчеләр, куштаннар, икейөзлеләр, динсезләр хуҗа. Алансу әллә нинди хәвеф көткән кебек тынып калды” [1: 101]. Әйе, авылда дингә, иманлы, булдыклы, хәлле кешеләргә каршы власть башына менеп утырган надан Шәрәфи, ирдәүкә Наһар, Габдрахман хәлфәне Себергә сөргәннән соң аның намазлы йортына кереп оялаган һәм тараканга батырган ата ялкау Галәү, үзенең мөгаллимен штыктерәп илдән куган сакау Мансур көрәшә.

Фәнни-эзләнү эшемне башлаганда, бу геройларның чынбарлыктагы язмышлары мине бик кызыксындырды һәм мин дәү әниемә мөрәҗәгать иттем. Дәү әнием мине дәү бабам язмышы белән таныштырды. Дәү бабам – сугыш ветераны, ул, Бөек Ватан сугышында катнашып, бик күп орден-медальләр белән бүләкләнгән. Ләкин Сталин афәте аны урап уза. Дәү әнием, сөйләве буенча, дәү бабам Равилә Шәйдуллинаның бабасы белән аралашкан, бер-берсе белән дус булган, хәтта бер урамда яшәгәннәр. Ә язмышның сынавы икесенә дә тигезләп бирелә. Дәү бабамны авылдагы бер явыз җан юк сүз белән донос ясаган һәм аны, төнлә белән кара машинага утыртып, Казан төрмәсенә алып киткәннәр. Төрмәдәге газапларны аңлатып бетереп тә булмый. Әле өстәвенә атарга дигән хөкем карары белән алып чыгалар һәм шунда аның бәхетенә таныш җитәкче очрап, дәү бабам исән кала, ләкин йөрәк җәрәхәте мәңгегә бетми. Ул соңгы сәгатенә кадәр иленә, Ватанына, милләтенә, халкына тугрылыклы булып кала. Алан авылы халкы аның турында сокланып һәм горурланып искә ала. Дәү әнием бу вакыйгаларны ачы күз яшьләре белән өзгәләнеп сөйләде. Кечкенә генә кызчык булса да, әнисенең елаганын, әтисенең моңлы күзләре беркайчан да күз алдыннан китмәячәк. Равилә апайның әбисе белән дәү әби һәрчак бергә булганнар, кайгыны да шатлыкны да бергә уртаклашканнар. Бу елларны оныту мөмкин түгел. Без шушындый бабаларыбыз һәм әбиләребез белән горурланырга, киләчәк буынга алар турында җиткерергә, аларның сабырлыгына, горурлыгына сокланып яшәргә тиеш. Шушы фәнни эшне тикшерү барышында җәмгыять һәм кеше язмышы турында тулырак күз алдыма китердем. Алга таба да тарихи вакыйгаларны өйрәнүне дәвам итәргә уйлыйм.

Шулай итеп, буйга җиткән һәр биш кешенең берсе сәяси репрессия корбанына әйләнә. Бернинди киртәләрне белмәгән репрессия сәясәте илебезгә һәм халыкка бик зур зыян һәм төзәтә алмаслык яралар ясый.

**Әдәбият**

1. Казан утлары. – 2020. – № 2, 3.

2. Мәхмүдов Х. Борынгылар әйткән сүзләр. – Казан: Фикер, 2002. – 432 б.

3. Мәхмүтов Х. Татар халкының афористик иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1987. – 288 б.

4. Шәйдуллина Р.Ш. Карт шомырт хатирәсе. –Казан: Ак Бүре, 2020. –367 б.

5. Шәйдуллина Р.Ш. Ялантауга ай кунган: повестьлар. – Казан: Ак Бүре, 2016. – 335 б.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ “ОҖМАХ” ҺӘМ “ТӘМУГ” КОНЦЕПТЛАРЫ

*Әхмәдуллина Э., Мортазина К., Түбән Кама ш., 13нче гимназия-интернат, X сыйныф*

*Җит. – Ишмөхәммәтов И.Ш.*

Татар халкының рухи һәм дини яктан үсеш үзенчәлекләрен билгеләүче төп факторларның берсе – ахирәткә ышану. Аның нигезендә тәкъвалар үлгәннән соң оҗмахка эләгә, ә гөнаһлылар – җәһәннәмгә. Гомернең чиклелеге тою һәм бу дөньядагы гамәлләр өчен җавап тоту кирәклеге һәрберебезне борчый һәм уйландыра. Шуны истә тотып, тикшерену өчен “оҗмах” һәм “тәмуг” концептларын өйрәнүне алдык, үзалдыбызга аларның татар телендә чагылышын тикшерү максатын куйдык.

“*Оҗмах*” һәм “*тәмуг*” сүзләре, гарәп-фарсы алынмалары булуга карамастан, татар теле тарафыннан тирән үзләштерелгән. Моңа дәлил буларак “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “*оҗмах*” һәм “*тәмуг*” лексемаларының икешәр мәгънәләре китерелә [5: 406, 585].

“Татарча-русча сүзлек”тә “оҗмах” сүзенең бер мәгънәдәге тәрҗемәсе, ә “тәмуг” сүзенең 2 мәгънәдәге тәрҗемәләре китерелгән.

“Синонимнар сүзлеге” нигезендә “оҗмах” концептының синонимик рәте төзелде: ***оҗмах*** *– җәннәт, хур*; “тәмуг” концептының синонимы: ***тәмуг*** *– җәһәннәм*.

Антонимнар сүзлегенә мәрәҗәгать итеп, әлеге концептларның антонимнарын барладык. “*Оҗмах*” лексемасының антонимнары булып ***тәмуг*** һәм ***җәһәннәм*** сүзләре китерелгән. “*Тәмуг*” концептының антонимы булып ***оҗмах***, ***җәннәт*** лексемалары тора.

Г.Х. Әхәтовның “Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге”ндә әлеге концептлар кергән фразеологизмнар урын алмаган, тик шулай да “*тәмуг*” концептының синонимы *җәһәннәм* лексемасы белән берничә фразеологизмны очраттык: *җәһәннәм тишегендә, җәһәннәм төбенә җибәрү (җәһәннәмгә җибәрү)* [1: 174]. Ә Н.Исәнбәтнең “Татар теленең фразеологик сүзлеге”ндә “*оҗмах*” концепты һәм аның синонимы булган *җәннәт* лексемасы белән – *оҗмах кошы, оҗмахтагы кебек тору, җәннәт күрдеңме әллә*. Ә “*тәмуг*” концепты һәм аның синонимы *җәһәннәм* лексемасы белән – *тәмуг кисәве, җәһәннәм асты, җәһәннәмгә керсә дә йөзе кызармас, җәһәннәмгә җибәрү, җәһәннәм кисәве, җәһәннәм машинасы, җәһәннәмнең теге кырыенда (җәһәннәм тишегендә), җәһәннәм терәве, җәһәннәм өрлеге* кебек фразеологик әйтелмәләр бирелгән [4: 50, 168, 362-363]. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә, боларга өстәп, “оҗмах” концепты белән бәйле *оҗмах кошлары, оҗмах байлыгы, җәннәт күрдеңме әллә, җәннәт хуры* фразеологизмнары [5:

406, 788]. “Тәмуг” концепты белән бәйле *тәмуг базы, тәмуг газабы* (*җәһәннәм газабы*)*, тәмуг кисәве* (*җәһәннәм кисәве*)*, тәмуг уты, җәһәннәмгә китү (очу)* тотрыклы әйтелмәләр китерелгән [5: 582, 789]. Болардан тыш “Татарча-русча сүзлек”тә “оҗмах” концепты кергән 11 фразеологизмның тәрҗемәсе китерелгән. “Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек”тә боларга өстәп “оҗмах” концепты кергән алда искә алынган 2 фразеологизмның тәрҗемәләре китерелгән һәм шулай ук “тәмуг” концепты кергән алда искә алынган 2 фразеологизмның тәрҗемәсе бирелгән. Боларга өстәп *җәннәт* лексемасы белән ***җәннәт түрендә*** кебек һәм ***җәһәннәм*** лексемасы белән 10 фразеологик әйтелмәнең тәрҗемәләре тәкъдим ителгән. Болардан ***җәһәннәм аша узу, җәһәннәмнең теге кырыенда*** кебекләре кабатланмый.

Г. Тукайның шигърият теле сүзлегеннән күренгәнчә, шагыйрь үз иҗатында “*оҗмах*” концептын 9 тапкыр кулланган, аның белән беррәттән “*оҗмах*”ның синонимнары булган “*җәннәт*” лексемасы 6 тапкыр, “хур” лексемасы 1 тапкыр күзәтелә. Шулай ук “*тәмуг*” концепты 2 тапкыр, “*җәһәннәм*” лексемасы 4 тапкыр кулланылган [2: 71-72, 175, 296-297].

М. Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре” теле сүзлегендә “оҗмах” һәм “тәмуг” концептлары кергән строфаларны очратырга туры килмәде. Бу, безнеңчә, шагыйрьнең совет чорында яшәп иҗат итүе һәм шул чорның иҗтимагый-сәяси мохите, шартлары белән аңлатыладыр. Чөнки ул чорда атеизм идеологиясе нәтиҗәсендә дин искелек калдыгы буларак кабул ителә, шуңа күрә ислам белән бәйле һәр нәрсәгә табу салына.

Дөнья тел картинасын анализлау өчен мәкаль һәм әйтемнәрне анализлау мөһим санала. Шуның өчен без “*оҗмах*” һәм “*тәмуг*” компоненты булган паремияләрне барладык. Татар халкы әлеге төшенчәләр хакында һәрвакытта да истә тота. Мәкальләр арасында теге дөньяда яшәүне инкарь итүчеләре дә бар, алар бу дөньяда яшәүне теләмичә генә яшәргә өндиләр [3: 785-786].

“*Оҗмах*” һәм “*тәмуг*” концептлары югары ешлыкка, күпмәгънәлелеккә ия; актив лексика; ясагыч нигезле сүзләр (оҗмахлы, тәмуглы, тәмуглык). Алар бер составлы атау җөмләнең баш кисәге, шигырь исеме була ала.

Күргәнебезчә, телдә *“оҗмах”, “тәмуг”* концептларына караган күренешләрне атаган сүзләр дә байтак. Болар *оҗмах, тәмуг, сират, фирдәвес, бу дөнья, теге дөнья, ахирәт, кыямәт, җәннәт, җәһәннәм* кебек берәмлекләр.

Шулай итеп, татар телендә “*оҗмах*” һәм «*тәмуг*» концептлары, үзәгендә кеше булган, пространство һәм вакыт белән чикләнгән ниндидер үлчәүләр рәвешендә бирелгән. Ике концепт та дөньяның

татар тел картинасындагы төп онтологик концептларга карый, чөнки аларда вакыт, киңлек, яшәеш һәм үлем төшенчәләре чагылыш таба һәм алар кешенең җәмгыятьтә үз-үзен тотышы моделенә йогынты ясарга һәм яшәү рәвешен билгеләргә сәләтле. Алар, тулаем алганда, кешенең тормыш мәгънәсе, билгеләнеше, шулай ук халыкның рухи кыйммәтләре һәм дине белән бәйле.Куллану даирәсе белән чикләнмәгән бу концептлар татар халкының ментальлеген, дөньяны күзаллау үзенчәлеген чагылдыра.

**Әдәбият**


1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 176 б.
2. Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек. 2 китапта. 1нче һәм 2нче китаплар / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина. – Казан: Мәгариф, 2009. – 527 б.
3. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 2нче басма. Т. III. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 799 б.
4. Исәнбәт Н. С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. II том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 365 б.
5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.


## ҚАЗАҚ ТІЛІНДЕГІ ӘЙЕЛ ЕСІМДЕРІНІҢ ЖІКТЕЛІМІ


*Базарова Д, Қазақстан, Алматы қаласы, № 59 мектептің*
*10-сынып оқушысы*
*Ғыл. жет. – филол. ғыл.док., проф. Ермекова Т.Н.*


Тіл – ұлт өмірінің айнасы. Әр халықтың тілінде оның өзіндік ұлттық құндылықтары мен тарихы, болмысының ізі жатады. Сондай тілдік бірліктердің қатарына адам есімдері де жатады. Ат қою процесі әрбір кезеңдерде орын алған тарихи оқиғаларға қарай өзгеріп отырады. Қазақ тілінде ғалым Т.Жанұзақов тілімізде кездесетін ономастикалық атауларды жан жақты қарастырады [1]. Әйел антропонимдерін дәуірлерге бөліп қарастыру үрдісі де бар Мысалы, жас ғалым М.Бигельдиева қазақ және түрік әйел антропонимиясын осы тұрғыдан қарастырады:

«Бірінші дәуір – көне түркі кезеңі (V-Xғғ.) пұтқа табынуға байланысты жалқы есімдер. Мысалы: Айкүн, Айсұлу, Күнсұлу, Айтолды, Айжарық, Күнай, Gün, Ay, Yıldız, Günay, Yıldızay, Günhan, Ayhan, Ayfer, Aytuğ, Aygüzel, Altunhan т.б. Екінші дәуір – ортағасырлық кезең (X-XVII ғғ.). Бұл дәуірдегі антропонимдер көбіне туыстық атаулар, тайпа, ру атауларымен, мәдениет пен тұрмыс, әлеуметтік-саяси терминдермен байланысты болып келеді. Мысалы: Ақжібек, Ақшолпан, Аққүміс, Айғаным, Ақтолқын, Бибіжамал, Бибісара, Қаншайым. Үшінші дәуір – XVII – XIX ғасырларды қамтиды. Бұл дәуір – негізінен аппелятивтік лексикамен байланысты қалыптасқан жаңа атаулармен ерекшеленеді. Мысалы: *Жібек, Баршын,*

*Қамқа, Шекер, Алуа* және т.б. Осы үшінші дәуірде әйел есімдерінде айтарлықтай өзгешеліктер болмады. Төртінші дәуір – Совет кезеңі. Орыс тілінен жалқы есімдер, әсіресе әйел есімдері төртінші кезеңде яғни, Октябрь революциясынан кейін, Кеңес заманында кеңінен жайыла бастағандығы байқалады. Мысалы: *Лиза, Марина, Клавдия, Римма, Рита, Светлана, Тамара, Клара, Мира, Мая, Жеңіс* сияқты есімдер көбіне XX ғасырдың орта кезінде дүниеге келген балаларға берілген [2]. Осындай зерттеулер нәтижелеріне сүйене отырып, жаңа жіктемелер ұсынамыз:

1. Табиғат құбылыстарына мен аспан денелеріне (астронимдерге) байланысты есімдер: *Айбала, Күнсұлу, Нұрсұлу, Айасыл, Күнай, Айдай, Айым, Шолпан, Венера, Жұлдыз, Ақжаңбыр т.б.*

2. Табиғаттағы құстар мен аңдарға, үй жануарларына байланысты есімдер: *Қарлығаш, Лашын, Қаршыға, Ботагөз, Тоты, Ақтоты, Бұлбұл т.б.*

3. Асыл бұйымдар мен бағалы тастарға және қымбат материалдарға байланысты туындаған есімдер: *Меруерт, Гауһар, Маржан, Інжу, Жібек, Мақпал, Торғын, Алтын, Қамқа, Барқыт, Күміс, Жауһар, Динара т.б.*

4. Өсімдік аттарына байланысты есімдер: *Қызғалдақ, Райхан, Раушан, Роза, Гүлім, Гүлдер, Гүлдана, Гүлниса, Гүлайым, Гүлбақыт, Гүлім,Гүлнәр т.б.*

5. Жеміс-жидек аттарына байланысты есімдер: *Алма, Алмагүл, Анар, Мейіз, Құлпынай, Қарақат т.б.*

6. Халықтың ежелден қалыптасқан наным-сенімдері мен тілек-қалауларынан туған есімдер:

– бала ақылды, дана болсын деген ниетпен: *Дана, Данагүл, Айдана, Гүлдана, Ақылай т.б.*

– жанұяда ұл бала дүниеге келсін, «осы туылған қыздың соңынан ұл жалғассын» деген ниетпен: *Ұлболсын, Ұлдана,Ұлту, Ұлмекен, Ұлымай, Ұлтуар, Ұлту, Жаңылсын Жаңыл, Ұлжан* сынды есімдер қойылған.

– жанұяда бала тұрмай өле беретін болса,тоқтасын, өмірі ұзақ болсын деген ниетпен: *Тұрсынгүл, Тұрсынай т.б.*

– жаңа туған сәби «мейірімді, жақындарына жанашыр болсын» деген ниетпен: *Мейірім, Шапақ, Шапағат, Мейір, Мейіргүл т.б.*

7. Тұрмыста қолданылатын заттарға байланысты есімдер: *Айна, Айнагүл, Шара, Балтагүл т.б.*

8. Санадан тыс құбылыстарға және абстракт мәндегі заттарға байланысты: *Сезім, Махаббат, Бақыт, Бақытгүл, Бақгүл, Наз, Ерке, Назерке, Іңкәр, Сағым, Гүлсезім, Тыныштық, Болғанай, Ләззәт т.б.*

9. Бала туылғанда оның сыртқы бітіміндегі кейбір артықшылықтарына (меңінің көп болуы, маңдайының кеңдігі, аппақ немесе қара түстілігі, көзінің бота көзіндей үлкен болуы) байланысты *Ботагөз, Ақмаңдай, Аймаңдай, Ақбала, Аққыз, Қарақыз, Қалдықыз, Меңдіқыз, Меңдігүл, Қалдықыз, Қалдыгүл т.б.*

10. Халықтық уақыт, яғни күнтізбелік атауларға байланысты туындаған есімдер: *Дүйсенгүл, Сәрсенгүл, Жұмагүл, Бейсенкүл, Майгүл т.б.*

11. Жыр-дастандардағы қаһармандардың есіміне негізделіп қойылған аттар: *Ләйлі, Еңлік, Назым т.б.*

12.Ислам дінінің абылдануына байланысты қазақ отбасыларында киелі кітап болып саналатын Құрандағы пайғамбарлар мен олардың жанындағы барша жақындарының есімдеріне, яғни агионимдерге байланысты туған антропонимдер: *Амина, Фатима, Мәриям т.б.*

Тарихымызда өткен ұлы тұлғалар мен лиро-эпостық жыр-дастандардағы қаһармандар есімдері арадан сан ғасырлар өтсе де әлі күнге дейін жалпыхалықтық қолданыстан шыға қойған жоқ. Керісінше, заманауи қалыпқа еніп, жаңарып келуде. «Ләйлі-Мәжнүн» дастанындағы *ЛӘЙЛІ* (Ләйлә,Ләйлім формаларында да кездеседі), «Еңлік-Кебек» дастанындағы *ЕҢЛІК*, «Фархат-Шырын» дастанындағы Шырын, «Қыз Жібек» жырындағы *ЖІБЕК,* «Алпамыс батыр» жырындағы батырдың жары – *ГҮЛБАРШЫН,* «Қамбар батыр» жырындағы батырдың жары – *НАЗЫМ,* «Ер Төстік» жырындағы *КЕНЖЕКЕЙ.*

Әрбір тілдің сөздік қоры тек өзінің төл сөздері есебінен ғана толығып қоймай, сонымен қатар өзінде жоқ сөздерді басқа тілдерден қабылдап алу нәтижесінде ол өзінің сөздік құрамын жетілдіріп отырады. Мемлекеттердің бір-бірімен түрлі дипломатиялық қарым-қатынас жасауы салдарынан олардың арасында түрлі мәдени, рухани байлықтардың алмасу процесінің орын алғандығына куә боламыз.

**Әдебиет**

1. Жанұзақов Т.Ж. Қазақ есімдерінің тарихы. (Лингвистикалық және тарихи этнографиялық талдау). – Алматы, Ғылым, 1971. – 218 б.

2. Бигельдиева М. Қазақ және түрік әйел антропонимиясы. Филол. ғыл. канд. дисс. авторефераты. – Алматы, 2010. – 24 б.

## РЕНАТ ХАРИС ИҖАТЫНДА ТЕЛ МӘСЬӘЛӘСЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Биктимерова Г., Буа ш., Вахитов ис. гимназия, X сыйныф*

*Җит. – Исмәгыйлева Г.Т.*

Туган як! Туган җир! Туган туфрак! Туган төбәк! Туган табигать! Туган тел! Һәрбер кеше өчен нинди газиз, тирән мәгънәле сүзләр! Нинди генә язучылар, шагыйрьләр аны зурламаганнар, күкләргә чөеп

мактамаганнар. Туган илебезгә, аның үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә туган якны өйрәнүнең мөмкинлекләре аеруча зур. Туган як һәм туган тел бербөтен.

Тел – халыкның, милләтнең көзгесе. Һәр халык өчен үз теле якын һәм кадерле һәм якын булырга тиеш. Туган телнең яшәеше, сафлыгы турында Ренат Харис иҗатында да шактый табарга була.

Туган телнең универсаль билгеләре булып аның эчке билгеләре – «якын» (близкий), «минем» (родной, мой), «тәмле, татлы» (сладкий), «моңлы» (певучий), «кадерле» (дорогой), «чиста», «саф» (чистый), «бөек» (великий), «әни, әнкәм (теле)» (мамин), «әти, әткәй (теле)» (папин) и һ.б. тора.

Эзләнү эше барышында Ренат Харис иҗатында “Туган тел” мәсьәләсенең зур урын алуын күрдем.

Ренат Харис шигырьләрендә татар теленең төрки телләр арасында лаеклы урын тотуын да күрәбез. Ул «куәтле» дә, «бөек» тә, «җылы» да, «төз» дә, «яңгырашлы» да һ.б.:

Төрки халык әгәр бер авыздан Татар теле мәгърур хорда яңгырар – Ул куәтле, дәртле, җылы, төз! («Төрки телләр» шигыре) Ренат Харис өчен туган тел – еллар белән генә түгел, гасырлар белән сыналган көч.

Татар телем! Алтын акчаларга
Басылдың син Болгар, Биләрдә...
Ярлыкларга ятып, кенәзләргә
Рөхсәт булдың ниләр биләргә. («Чехов базары»)

Ренат Харис үзенең теле, халкы белән горурлана.

Тел – бәхет сакчысы булуын да күрәбез. Анда җылылык та бөркелә.

Чәчләремнең көлсу төсе
Балкыды көмеш булып.
Кочагым – чәчәкләр тулы,
Телем – җылы сүз тулы. («Шөкер» шигыре)

Ренат Харис шигырьләрендә телебезне үстерү өчен киңәш, үгет тә күрергә була.

Тотнаклыкта да чама бел –
Саран дип телгә кермә,
Ләкин өч бөек нәрсәне,
Үлсәң үл, ләкин бирмә:
Бүгенгеңне, Иртәгәңне,
Үткәнеңнең мирасын –
Бирмә хәтта пәйгамбәрләр
Яный-яный сорасын.
Ләкин сорамасалар да-
Телиме, теләмиме –

Бир балаңа, оныгыңа
Изге туган телеңне,
Бир урамда йөргән чакта;
Татар телендә макта;
Орышмыйча торып булмый –
Орышканда бир хәтта!
Татарча сөйләп аш пешер
Һәм ипи кис телемләп –
Кухня теле кадерлерәк
Парламентлар теленнән! (“Бир һәм бирмә”)
Үткәннәр белән генә дә яшәп булмый, телнең киләчәге борчый.
Бабаңның татар булуы
Синең казаныш түгел.
Оныкларның татар булып
Яшәве кирәк бүген! (“Бир һәм бирмә”)
Кыскасы, татар, яши бел
Заман күзенә карап –
Кичәгеңне, бүгенгеңне,
Иртәгесенне ярат. (“Бир һәм бирмә”)
Рус теленә тәрҗемәсе дә бик мәгънәле яңгырый.
Когда я на татарском говорю, увереннее гордость бьётся в сердце,
и разум разгоняет сумрак серый уныния – и снова я творю...
Когда я на татарском говорю (“О родном языке”. Марина Ахмедова Колюбакинаның татарчадан тәрҗемәсе)

Күңелемдә рухи төшенкелек вакытында якташымның шигырьләр җыентыкларын кулыма алам, һәм уйландыра, моңландыра, сөендерә, көлдерә торган әсәрләр горурлану хисләре уята...

Аның шигырьләре кайберәүләргә артык катлаулы булып күренә. Ләкин игътибар белән укырга тотынсаң, гади һәм аңлаешлы, тышкы бизәкләрдән азат булуын күрәсең. Эчтәлеген бөтен тирәнлегендә аңлар өчен, аны бер кат түгел, күп мәртәбәләр укырга кирәк.

## ПРОИСХОЖДЕНИЕ ГЕОГРАФИЧЕСКИХ НАЗВАНИЙ В ВЕЛИКОБРИТАНИИ, США И РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

*Булякова Д., г. Набережные Челны, ГБОУ «Набережночелнинская школа № 87 для детей с ОВЗ», XII класс*
*Рук. – Фатхиева Р.З.*

Целью данной работы является проведение этимологического анализа топонимов Великобритании, США и республики Татарстан.

*Этимологический анализ топонимов Великобритании.*

Примерами британских топонимов, имеющих кельтское происхождение, являются Belfast, Mullaghbane, Dumbarton... Кроме этого, почти все названия рек имеют кельтское происхождение Avon, Thames, Severn, Axe... Примерами британских географических названий латинского происхождения являются Manchester, Oxford, Lincoln, Guillford, Thelford, Fossway, Fosbroke, Ipswich …

Лондон (London), образован от кельтского londun «укрепление на возвышенности». Ливерпуль- от pool «заводь, бухта», -англ. liver «мутный, илистый». Оксфорд происходит от слов «ox» – бык и «форд» – брод (место перехода реки). Саффолк (Suffolk) означает “the south folk” – южный народ (of Angles). Оттершоу (Ottershaw) обозначает “small wood frequented by otters”- роща, где живут выдры. Сэндвич- город на юго-востоке Англии. Название происходит от двух слов «sand»-песок и «wich» (устаревшее от village) – деревня.

*Этимологический анализ топонимов США.*

Например, Кентукки – «земля лугов», Айова – «красивая земля», Аляска – «великая земля», Висконсин – «травянистая равнина». Примерами англоязычных названий могут служить Лонг-Айленд в Нью-Йорке («длинный остров»), Солт-Лейк-Сити («город Соленого озера»). Особенно многочисленны названия с приставкой «сан» – «святой». Например, Санта-Крус («святой крест»), Санта-Фе («святая вера»), Сакраменто («таинство»).

Иногда такие названия начинаются со слова «новый»: Нью-Джерси (Джерси – остров в Ла-Манше), Нью-Гэмпшир (Гэмпшир – графство в Англии), Нью-Виндзор, Нью-Лондон, Нью-Плимут, Нью-Эдинбург. Особенно многочисленны названия с приставкой «сан» – «святой». Например, Санта-Крус («святой крест»), Санта-Фе («святая вера»), Сакраменто («таинство»).

*Этимологический анализ топонимов республики Татарстан*

Актюбинск и Ахтуба – города в Казахстане и России, от татарского Ак түбә: буквально «белая крыша». Арбат – улица и исторический район в Москве, от татарского словосочетания арба-ат («телега да лошадь»). Байкал – озеро в Сибири, от татарского словосочетания Бай күл («богатое озеро»). Карское море – море в России, от татарского Кар диңгезе («снежное море»). Саяны – горы в России, от татарского слова Сыен (одно из значений – «прибежище», пристанище»). Тула – город в России, татарское тулы («полный, изобильный Яуза (река в Москве) – татарское Яу уза: «место прохода войск (войсковой брод)». Позднее закрепилось как название всей реки. Альметьевск. Аль+мат (Әл +мәт) – название образовалось путём сложения первого и четвёртого слогов от Альмухаммат (образованный человек того

времени). Агрыз «Агерже» является изменённым от татарского слова «Агирча» – «агир»+ «ча». «Агир» («Акар») – русло реки постоянных потоков минерализованной воды. Бугульма. Гидроним от татарского бегелме – «извилина, загиб, изгиб». Буинск. Название связано с татарским «запруда».

Этимологический анализ топонимов свидетельствует о том, что они возникают в конкретных исторических условиях, отражая различные стороны жизни и деятельности человека. Источником топонимии послужили личные имена первопоселенцев, владельцев земель и поселений, святых, исторических деятелей, фамилии людей, характеристики местности, географического положения.

Проведенное анкетирование учащихся 9-12 классов подтвердило актуальность данного исследования. Знания детей о городах изучаемого языка поверхностны.

С помощью изучения географических названий Великобритании, США и республики Татарстан был составлен список топонимов и произведена классификация по их происхождению. На этом этапе были определены основные способы образования топонимов, с точки зрения их значения. Выявлены иноязычные компоненты при помощи этимологического анализа.

Анализ топонимов дает возможность прочитывать неизвестные страницы истории народов Великобритании и США, изучать ареалы расселения народов, их происхождение, миграцию и многое другое.

**Литература**


1. http://human.snauka.ru/2014/02/8698
2. https://sibac.info/studconf/science/iii/27989
3. slovarozhegova.ru/word.php?wordid=31980
4. http://englishgu.ru/angliyskie-goroda/#ixzz4WcAsQ6Sg


## ТАТАРСКИЕ ПОЭТЫ И ПИСАТЕЛИ – ГЕРОИ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ


*Валиева Э., г. Казань, МБОУ «Школа №10», XI класс*

*Рук. – Хадиева Ф.И., Бердникова Л.Г.*


Великая Отечественная война останется в истории как время величайшего патриотического подъема миллионов людей разных возрастов и разных национальностей. Таким примером высочайшего патриотизма являлась в те годы деятельность писателей и поэтов Татарстана. Они боролись с врагом и пером, и оружием, в самом пекле – на фронте.

Все национальные литературные сообщества Советского Союза понесли потери в этой страшной войне, но жертва татарской литературы была самой большой.

Союз писателей Татарстана к началу войны насчитывал в своем составе 50 писателей. Из них около сорока ушли на фронт. В 1943 году руководитель Союза писателей СССР Александр Фадеев, узнав об этом, выразил свою серьезную озабоченность и предложил предпринять меры, чтобы вернуть хотя бы некоторых из них обратно в тыл. Но ни один из татарских писателей не принял этого предложения.

Целью моего проекта является активизация интереса к истории Великой Отечественной войне и ее героях, родного края, родного языка и литературе.

Для достижения цели мне было необходимо:

- составить список татарских поэтов и писателей - героев Великой Отечественной Войны.
- создать тематический сайт на платформе Wix.
- составить каталог видеороликов с участниками образовательного процесса МБОУ «Школа 10» и разместить на сайте.
- для каждого из 99 татарских поэтов и писателей – фронтовиков создать свою страницу на сайте, где будут размещены фото, документы, биография поэта, ссылки на онлайн библиотеки, видеоролики с чтением произведений поэта.

Необычная подача материала позволит заострить внимание учащихся на биографии героев Великой Отечественной войны, искать дополнительный материал, заинтересует изучением родного языка и литературы.

Я решила создать образовательного пространство в нашей школе, которое могли бы использовать все участники образовательного процесса: учителя с помощью этого сайта готовили бы конспекты уроков, классных часов и планировали бы мероприятия, ученики могли бы с помощью сайта готовить домашние задания по темам, связанным с Великой Отечественной войной.

Обратившись с нашей идеей к директору школы Желтяковой А.Р., я не ожидала поддержки в виде выделения целой стены в коридоре второго этажа. Приглашенный в школу художник обсудил видение проекта с нами и нашими руководителями и совместно появилась идея рисунка.

На стене коридора второго этажа расположиться большая книжная полка, на которой будут лежать книги с произведениями татарских поэтов и писателей – героев Великой Отечественной войны. У кого-то тонкие книжки, у кого-то большие многотомные собрания. Но каждый поэт и писатель, добывший Великую Победу получит свое место на книжной полке нашей школы.

На каждой книге помимо имени и фамилии автора будет прикреплен QR- код, благодаря которому любой желающий сможет попасть на сайт проекта и получить доступ к интересующей его информации.

Мы не остановились лишь на визуализации сайта и решили почтить память каждого поэта и писателя по-своему. В сентябре мы запустили конкурс чтецов произведений наших земляков-героев в каждой параллели классов, выступления победителей и призеров мы опубликовали на сайте проекта. К проекту присоединились и учителя нашей школы, а позднее и родители наших учеников. Нам очень приятно, что проект объединил всех участников образовательного процесса нашей школы единым делом, которое останется в памяти.

По моим подсчетам, работа над проектом завершится к маю 2022 года.

Я уверена, что совсем скоро каждый день в перемену будем видеть ребят возле той самой полки. Кто-то будет забивать в поисковиках мобильного телефона имена героев и делиться впечатлениями с одноклассниками. Кто-то, просканировав QR-код, увидит себя или своих родителей, старшего брата или сестру, читающих отрывок из произведений. Кто-то запишет на бумажке имена героев, чтобы дома узнать о них больше и рассказать родителям о них. Учителя будут использовать сайт для дистанционных уроков или классных часов, посвященных годовщине Великой Победы. А это будет значить, что мы достигли своей цели.

**Литература**

1. Ахметшин Ш.К. Татары на службе Отечеству. Долг. Отвага. Честь. Страницы истории татарских воинских частей в Российской армии и Императорской гвардии / Ш.К. Ахметшин, Ш. А. Насеров. – СПб.: Славия, 2006. – 240 с.

2. Гиниятуллина А.К. Писатели Советского Татарстана: библиогр. справочник. – Казань: Татар. книж. изд-во, 1970. – 511 с.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ “ӘБҮГАЛИСИНА” ӘСӘРЕНДӘ АЛЫНМА СҮЗЛӘР

*Галиева К., Саба р-ны, Байкиев К.С. ис. Икшермә кадет интернат мәктәбе, VIII сыйныф*

*Җит. – Гарәфиева М.И.*

Телебезнең сүзлек составы – зур тарихи үсеш нәтиҗәсе ул. Аның төп сүзлек фондын гомум-төрки сүзләр тәшкил итә. Татар теленең сүзлек составы күп гасырлар дәвамында тулыландырылган. Аның формалашуында, үсүендә төп ике юлны – татар теленең үз сүзләре һәм башка телләрдән сүзләр алу юлын күрсәтеп булыр иде. Татар теленең сүзлек составында гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләр күп.

Гасим Лотфи эшкәртмәсендәге “Әбүгалисина” әсәрендә гарәп-фарсы, рус һәм рус теле аша чит телләрдән кергән сүзләр бар.

Әсәрдә күпчелекне гарәп алынмалары, аннан фарсы, рус һәм рус теле аша үтеп кергән чит тел алынмалары тәшкил итә: *кәгазь, гыйлем, гадәт, галим, мәгарә, гыйбарәт, зәйтүн, халык* һ.б. “Әбүгалисинаның иптәшләре аның киезе астына бер бит кәгазь салып куялар, ә үзләре, Әбүгалисина нишләр икән дип, кызыксынып карап торалар” [2: 76].

Гарәп алынмалары белән беррәттән фарсы алынмалары да бар: *надан, дәрья, сәүдә, бәрабәр, фәрман, падишаһ, таҗ* һ.б. “Хәлвәфрүшнең сәүдәсе зураеп китте” [5: 84].

Алынмаларның иҗтимагый – тарихи җирлеге төрле булган. Бер халыктан матди байлык элементлары алышканда теге яки бу сүзләр керсә, икенче халыктан сәясәткә, дингә, сәүдәгә һәм башка мөнәсәбәтләргә бәйле алынмалар кергән. Ә хәзер һәркайсына аерым тукталып үтәм.

Дингә бәйле сүзләр: *Хак, тәсбих*. “Шулай ачуы чыгып утырганда, таягына таянып, тәсбихын тотып, күрше карчык килеп керде” [5: 119].

Фән һәм мәгариф өлкәсенә караган төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *кәгазь, гыйлем, галим, каләм, мәктәп, китап, фән*. “Озак еллар буена шунда калып, Ибне Сина исеме белән дан казанган зур галим булып китте” [5: 132].

Әдәбият һәм мәдәният өлкәсенә караган сүзләр: *хикәя*. “Матур-матур хикәяләр сөйләүчеләрнең сүзләренә караганда, Кирман дигән шәһәрдә Мәхмүд исемле бер патша булган” [5: 122].

Иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *халык, шаһзадә, вәзир, хаким, шәһәр, падишаһ, дәрәҗә, команда, тәхет, таҗ, мәмләкәт*. “Тиздән мәгарә ишеге ачылыр, өч сәгатькә мәгарә халык белән тулар” [5: 80].

Тормыш-көнкүрешнең төрле якларына караган сүзләр (гаилә, хезмәт, гореф-гадәтләр, ашамлык-ризыклар): *никах, зәйтүн, хәлвә, хат, хезмәт, вәгъдә, һөнәр, начар, хуп, мәшәкать, рәхмәт, ярдәм*. “Әбүгалисина кибәкләр тирәсендә нидер эшләде: кибәкләр барысы да хәлвәгә әверелделәр” [2: 83].

Сәүдә һәм юл йөрү төшенчәләрен белдерә торган сүзләр: *базар, сәүдә, дәрвиш, җиһаз, сәяхәт, магазин*. “Менә ул дәрвиш шушы кеше!” [5: 97].

Кешенең эчке һәм тышкы сыйфатларын, психологик кичерешләргә бәйле төшенчәләрне белдерүче сүзләр: *гадәт, галим, надан, фәкыйрь, ләззәт, гыйшык, газап, бәла, тәкатем, ләгънәт, вөҗдан, гайбәт, мәсхәрә, гыйбрәт, мәхәббәт, дус, дошман, фәкыйрь, кыяфәт, хөрмәт, фикер*. “Патша кызына гашыйк булуын яшермәде” [2: 85].

Медицина, хәрби, хокук төшенчәләрен белдерүче сүзләр: *хаким, баһадир, гаскәр, фәрман, җәллад, һәлак*. “Ике йөз мең гаскәр сафка басты” [5: 106].

Төрле өлкәләргә караган абстракт һәм конкрет төшенчәләрне белдерүче сүзләр: *мәгарә, гаять, гаҗәеп, мәйдан, дәрья, гаҗәп, хуп, зиннәт, чарлак, бәрабәр, сихер, зәгъферан, шакал, палас, сафьян, заман, дөнья, хәбәр, тәэсир, хайван, сәлам, афәт, хәйран, сәбәп*. “Әбүгалисина, зур бер хайваннар бакчасы ачып, аларны халыкка күрсәтә башлады” [5: 105].

Вакытны белдерүче сүзләр: *вакыт, сәгать*. “Шул вакыт Әбүгалисина, ул тәрәзәне ябып, икенче тәрәзәне ачарга кушты” [5: 123].

Кыйммәтле ташларны, казылма байлыкларны белдерүче сүзләр: *алмаз, гәүһәр*. “Башына энҗе-мәрҗән, гәүһәр-якутлар белән бизәлгән таҗ кигән” [5: 127].

Кеше исемнәре: *Әбүгалисина, Әбелхарис, Мәхмүд, Җалут, Мәнҗәль, Юхна, Милад*. “Шаһның Милад исемле акыллы вәзире була” [5: 129].

Татар теленә рус теленнән нинди сүзләр кергән соң? Татар халкы борын-борыннан руслар белән икътисади, сәүдә, сәяси һәм башка мөнәсәбәтләрдә булган. Шунлыктан татар теленә күпләп рус сүзләре килеп кергән һәм бу сүзләрне ике чорга бүлеп карарга мөмкин:

1. Октябрь революциясенә кадәр кергән сүзләр.

2. Октябрь революциясеннән соң кергән сүзләр.

Октябрь революциясенә кадәр кергән сүзләрнең күпчелеге татар теленең үз фонетик законнарына буйсындырылганнар: кесәл, ләгән, әвен, келәт. Ә октябрьдән соңгы чорда рус теле сүзләре үзгәрешсез, ягъни рус телендә ничек әйтелсәләр, шулай кабул ителгәннәр: печать, подвал, крепость. [3: 67] Гасим Лотфи эшкәртмәсендәге “Әбүгалисина” әсәрендә рус теленнән *расход, подвал, крепость, число* сүзләре кулланылган. “Стенага үрмәләп карады – тотына алмады” [5: 108]. Әсәрдә шулай ук рус теле аша чит телләрдән үтеп кергән сүзләр дә очрый. Грек теленнән: *музыка*. “Бу музыкадан колаклар рәхәтләнә, күңелгә шатлык тула” [5: 104]. Инглиз теле аша: *шкаф, керосин*. “Шәһәр һәм аның әйләнә-тирәсе, керосин сибеп ут төрткәндәй, дөрләп яна” [5: 123]. Немец теле аша: *флаг*. “Аптырагач, җиңелүләрен белдереп, ак флаг күтәрделәр” [5: 129].

Фәнни эшемә нәтиҗә ясаганда, халкыбызның олпат язучысы, күпкырлы талант иясе Каюм Насыйри үзенең “Әбүгалисина” әсәрен халык теленә якынайтуны максат итеп куя, ләкин әсәрдә барыбер яшь буынга аңлашылмаган гарәп – фарсы алынмалары кала. Г.Лотфи

эшкәртмәсендә, төрки-татар сүзләреннән тыш , күпчелекне гарәп алынмалары, аннан фарсы, рус һәм рус теле аша чит телләрдән кергән сүзләр тәшкил итә. Күпчелек гарәп – фарсы сүзләренең алынма икәне яшь буынга хәзер бөтенләй сизелми. Күп гасырлар буе татар теленә керә барган гарәп һәм фарсы алынмалары татар теленең лексикасында шактый зур урын биләп тора.

**Әдәбият**


1. Әдәбият белеме сүзлеге. – Казан: Татар кит. нәшр., 1990. – 238 б.
2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 368 б.
3. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
5. Хәмидуллин Л. Маҗаралар дөньясында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 255 б.


## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ УРТАК ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


*Галимуллина А., Казан ш., МГББУ“159 нчы лицей”, X сыйныф*

*Җит. – Галимуллина Л.Ф.*


Сүз – катлаулы тел берәмлеге. Һәр сүзгә килеп чыгышы, стилистик бизәге, кулланылыш үзенчәлеге, төзелеше ягыннан билгеләмә биреп була. Ләкин кайбер төшенчәләрне бер сүз белән генә түгел, ә сүзтезмәләр белән белдерергә туры килә. Мондый сүзтезмәләрне фразеологизмнар дип атыйлар. Фразеология лексикологиянең аерым бер бүлеге булып тора. Бу тотрыклы гыйбарәләр үзләренең эчтәлекләре, мәгънәләре белән аерым сүзләргә якын торалар һәм лексик берәмлек булып исәпләнәләр, ә инде формалары буенча алар сүзтезмәләргә охшыйлар.

Татар телендә фразеологизмнарны туплау, өйрәнү XX йөздә башлана. Беренче “Русча-татарча фразеологик сүзлек” 1959 елда басыла. 1982 нче елда Г.Х. Әхәтовның “Татар теленең фразеологик әйтелмәләре сүзлеге” нәшер ителә. Ә 1989-1990 елларда Н.Исәнбәтнең ике томлы “Татар теленең фразеологик сүзлеге” басылып чыга. Бу җыентыкта 10 меңләп фразеологизм урын ала. 2001нче елда Ф.С. Сафиуллинаның “Татарча-русча фразеологик сүзлеге” дөнья күрә. Сүзлектә 16 меңнән артык фразеологик берәмлек рус эквивалентлары белән, аерым очракларда тәрҗемә итеп бирелә. XX йөз башында фразеологик берәмлекләрне тел гыйлеменең мөстәкыйль бер тармагы итеп карау башлана. 40 нчы елларда исә бу эзләнүләр тагын да тирәнәйтелә һәм тел гыйлеменең яңа бер тармагына әверелә. Л.Җәләй, Ш.Рамазанов, Л.Мәхмүтова, Н.Борханова, В.Хаков, К.Сабиров, Г.Ахунҗанов, Х.Курбатов, Ф.С. Сафиуллина – татар тел гыйлемендә бу өлкәдә тикшеренүләр алып бара. Хәзерге вакытта да фразеологизмнарны өйрәнү актуаль мәсьәлә булып кала бирә, чөнки алар әдәби әсәрләрдә дә, халык сөйләмендә дә еш очрый. Татар теленең

фразеологик әйтелмәләре һәр яклап шактый тулы өйрәнелә. Ләкин аларны башка телнең фразеологик әйтелмәләре белән чагыштырып өйрәнүгә караган хезмәтләр татар телендә юк диярлек. Шул сәбәпле, без “Татар һәм төрек телләрендә уртак фразеологизмнарның үзенчәлекләре” дигән тема астында фәнни-үзләнү эше башкардык. Ике телдә дә очраган уртак фразеологик берәмлекләрне табып барладык, ике телдә саннар кергән фразеологизмнарны билгеләдек, аларның тематикасын ачыкладык.

Төрек телендә deyimler «әйтемнәр, фразеологик берәмлекләр” мәгънәсендә кулланыла. Якуп Кавас фикеренчә, фразеологизмнар мәкальләрдән кыскарак булулары, кимендә ике сүздән торулары белән һәм бер төшенчәне, бер фикерне белдерү өчен кулланылган гыйбарә калыбы булулары белән аерылалар. Әмма җөмлә хәлендәге deyimler дә була. *Her kuşun eti yenmez «Бөтен кошның да итен ашамыйлар” мәкале тәҗрибәгә нигезләнеп барлыкка килә. Ул тышкы күренешкә алданмаска кирәклекне искәртә һәм мәгънәсе татар телендәге “һәр ялтыраган алтын түгел” мәкаленә туры килә.*

*Фразеологик берәмлекләр, башка телләргә сүзгә-сүз тәрҗемә ителә алмыйлар. Etekleri zil çalıyor.* “İteklere qmğırau bulıp çınlıy” фразеологик берәмлеге татар теленә сүзгә-сүз тәрҗемә ителгәндә берни аңлатмый. Бу *мәгънәне фразеологик берәмлек, яисә әйтем белән белдерергә теләсәк, “эшләре юлында”, “күңеле түгәрәкләнгән” кебек гыйбарәләрне кулланырга тиеш булабыз.*

*Төрек һәм татар телләре өчен уртак фразеологик берәмлекләр аз түгел. Мәсәлән: aç gözlü – ач күзле, adamdan saymak – кешегә сана, akıl vermek – акыл бирү, diş bilemek – теш кайрау*. Шул ук вакытта төрек теле җирлегендә генә туа алган, бик үзенчәлекле фразеологик берәмлекләр дә күп. Алар төрек теленең матурлыгын, тирәнлеген күрсәтә торган тотрыклы гыйбарәләр очрый: *anladımsa arap olayım “аңласам, гарәп булырмын”, ягъни, берни дә аңламадым, at görür aksar, su görür susar “ ат күрер – аксар, су күрер – сусар”, ягъни, күргән бөтен нәрсәгә кызыгучы.*

Татар һәм төрек телләрендә саннар кергән уртак фразеологизмнар да шактый. Ике телдә дә аларның мәгънә уртаклыгы саклана. Бердән алып унга кадәрге саннар арасында, бары сигез саныннан кала барлык саннар белән дә ясалган фразеологизмнар очрый. Бу ике телдә *бер, ике¸ өч* саннары белән фразеологизмнар бик күп: *Алла да бер, шайтан да бер.* – Икесеннән дә тартынып тормауны, үз кирәгенә карап кайсын булса да чара итеп куллануны аңлата. *Бер казанга ике тәкә башы.* – Бер-берсе белән сыешмый торган ике каршылыкны бергә сыйдырырга тырышуга мисалдан. *Өч минутта.* – Бик тиз. *Дүрт колак белән тыңлау.* – Ике колак белән ишетү генә җитми дигән кебек, бөтен

игътибарны биреп, тырышып тыңлау. *Бер телгә биш тел.* – Сүз көрәштерү. *Ун бармагында уны утыра.* – Күп балалы. *Булмаса – биш, булса – унбиш.* – Акчаң югын белсә биш сумга да килешә, булганын белсә, унбиш сумыңны алмыйча китми, әрсез димәктән.

Татар һәм төрек телләрендә дә яхшылык, сабырлык, тыйнаклык категорияләренә караган, тәңгәл килгән фразеологик берәмлекләр очрый. Яхшылык категориясенә килгәндә, уртак яклар шундый: яхшылык та, яманлык та кешенең үзенә әйләнеп кайта, шуңа күрә яман эшләрдән тыелу кирәк; яхшы эшләрнең дә, яман эшләрнең дә гадәткә әйләнүе мөмкин, яманлыкка иярергә ярамау искәртелә.(İyiliğe iyilik her kişinin kârı, kötülüğe iyilik er kişinin kârı – Яхшылыкка яхшылык белән җавап бирүне һәркем булдырыр.) Һәр ике телдә дә сабырлык категориясе белән беррәттән, азга канәгать булу категориясе карала. (Köpek ekmek veren kapıyı tanır. – Эт тә ипи ашаткан ишекне таный). Татар телендә дә, төрек телендә дә сабырлыкның уңышка, бәхеткә китерүе искәртелә. Шулай ук рәхим-шәфкать, изге гамәлләр кылу, яхшы холык, оялчанлык, тыйнаклык кебек кыйммәтләр уртак әхлакый-этик кыйммәтләрне тәшкил итәләр. (Edeplerin anası, az konuşmaktır. – Әдәпле булуның анасы – аз сөйләшү.)

Татар һәм төрек теленең фразеологик фонды бай һәм күп кырлы. Ул кеше сөйләмен баетуда, үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә, художествалы әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне тулырак ачуда әһмиятле роль уйный. Кеше үзенең сөйләмендә мәкаль-әйтемнәр, фразеологик берәмлекләрдән ни дәрәҗәдә мул һәм уңышлы файдаланса, аның фикере кешеләргә шул дәрәҗәдә җиңелрәк һәм күркәмрәк булып ирешә. Мәдәниятле һәм тәрбияле кешенең сөйләме төгәл, аңлаешлы, саф, җыйнак һәм аһәңле булырга тиеш.

**Әдәбият**


1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 176 б.
2. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том– Казан: Татар. кит. нәшр, 1989. – 495 б.; II том – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 365 б.
3. Onarh I. Atasozleri ve Deyimler Sozlugu. – Istanbul, 2001. – 98 s.
4. Рахимова А.Р. Төрек грамматикасы. – Казан. 2002. – 345 б.
5. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 221 б.


## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ


*Гыйниятуллина А., Биектау р-ны, Коркачык гомуми урта белем бирү мәктәбе, XI сыйныф*

*Җит. – Рамазанова Р.Г.*


Әдәби әсәрнең теле дә, аның эчтәлеге кебек үк, билгеле, беркайчан да күктән генә килеп төшми, үзеннән-үзе генә чәчрәп чыкмый. Кыскасы,

юктан бар булмый. Яхшы әсәр языйм, үз сүземне үземчә әйтим дигән әдип иң элек телен баетырга тырыша. Халык тормышында телнең тоткан урынын, аның әһәмиятен тирәнтен аңлап, телгә мәхәббәте булган язучы гомер буе тел байлыгы җыя. Андый язучы һәм галим өчен һәр сүзнең үзенә генә хас кадерле үзенчәлеге, үз кыйммәте бар.

Әсәрнең теле образлы да, нәфис тә, җиңел дә һәм, шуларның һәммәсе өстенә, дөрес тә булырга тиеш. Һәр сүзне, һәр җөмләне, бөтен көче, бөтен нәфислеге ачылып җиткәнче, ювелир кебек, иң нечкә кораллар белән эшкә китерүче язучылар безнең әдәбиятта байтак ук җыелыр иде. Шундый тел осталары дип мин иң башта Ә.Еникине, Ф.Хөснине, И.Газины, Н.Исәнбәтне, шагыйрьләрдән Х.Туфанны, С.Хәкимне, Г.Афзалны атар идем.

Талантлы әдипләрдән, әдәби телнең көчен, кадерен, аның әһәмиятен Н.Фәттах, минемчә, шулай ук тирән аңлаучы язучы. Аның әсәрләренең теле бай һәм үтемле. "Әтил суы ака торур" романын ул кыю рәвештә, беренче буларак, халыкның ислам динен кергәнче яшәгән теле белән язарга батырчылык иткән. Моның өчен әдәби таланттан тыш тагы әле галим булу да кирәк. “Кол Гали” пьесасында ул үзенең әдәби тел остасы булуына тагын бер мәртәбә инандыра. Ә.Баянның проза теле вакыт-вакыт ярсып аккан язгы инешкә охшый. Кайчагында ярларыннан да чыгып киткәли, тора торгач юашланып та кала.

“Хәзинә” романының авторы Г.Ахунов исә ансат укыла торган йөгерек, җиңел тел белән язучы әдип. Ул юморга, халык телендәге тапкыр әйтемнәргә бик бай.

М.Мәһдиев – әдәби телгә Казан арты сөйләшенең үзенә генә хас интонациясен, моңарчы читтәрәк кала биргән, әдәбиятта кулланмаган аһәңен алып килүче.

Башка язучыларыбызның да байтагы әдәби телгә һәркайсы үз өлешен кертә, үз теле белән яза, үз алымын камилләштерә.

Никадәр тырышып язса да, соңыннан язып тәмамлаганнан соң, әсәрнең үзен канәгатьләндерми башлавы турында язучыларның үзләреннән дә ишетергә мөмкин. Нигә болай? Нигә хикәянең күңелдә уйнаганы шундый дулкынландыра да, нигә ул кәгазьгә төшкәндә зәгыйфьрәк чыга соң? Бу сорауга җавап итеп, Г.Бәшировның бер язмасыннан өзек тәкъдим итәсем килә: “Баштарак язган хикәяләремнең теле күп вакытны үземне канәгатьләндермәде... Әмма тирәнрәк алганда, моның нигезендә шул тел көчсезлеге ята иде. Тел кимчелекләренең тагын бер сәбәбе, минемчә, әдәбиятның үзендә әйләнә торган тел байлыгын куллану белән генә канәгатьләнүдә булса кирәк. Мин ул вакытта халык теленнән яңа байлык эзләргә, әсәремне моңарчы әдәбиятта булмаган отышлы яңа сүзләр, яңача әйтелешләр

белән баетуга кирәгенчә игътибар итми идем. Татар әдәбиятының якты йолдызларына гашыйк кеше буларак, Г.Тукай, Г.Ибраһимов һәм башка кайбер язучыларның теленә шулкадәр сокланып яши идем, аларны камиллекнең шундый югары баскычына күтәргән идем ки, алар теленнән дә баерак, нәфисрәк телнең булу ихтималы турында бәлки уйлап та карамаганмын.

Телемне баету, әсәрләремдәге тел кимчелеген бетерү өчен халыкның бетмәс-төкәнмәс күңел хәзинәсенә – халык иҗатына, халыкның сөйләү теленә мөрәҗәгать итәргә булдым 〈...〉".

Матур әдәбият һәм фольклор гомер-гомергә бер-берсе белән җитәкләшеп, үзара керешеп яшәгәннәр һәм яшиләр. Әмма Борынгы һәм Урта гасырларда алар арасында бәгләнеш аеруча көчле булган. Туып һәм үсеп килгән язма әдәбият мифологиягә, фольклорга ныклап таянган, иҗади материалны, сәнгатьчә фикерләү алымнарын һәм чараларын алардан күпләп алган. Мәсәлән, Йосыф–Зөләйха, Ләйлә–Мәҗнүн, Таһир–Зөһрә, Фәрһад–Ширин, Сәйфелмөлек һәм Бәдигылҗәмал сюжетларының һәммәсе дә диярлек язма әдәбиятка фольклор аша килеп кергән.

Татар халык иҗатында әйтеп бетергесез бай хәзинә тәшкил иткән афористик жанр төрләре үзләренә лаек урын алып тора. Шулар арасында беренче урынны, һичшиксез, макаль һәм әйтемнәр били. Мәкаль һәм әйтемнәр фольклорның кечкенә күләмле жанрлары. Бу жанр халык иҗатында бик күптәннән барлыкка килгән. Элек-электән халыкның аерылгысыз юлдашы, киңәшчесе булган. Мәкаль һәм әйтемнәргә тирән фикерне җыйнак итеп әйтеп бирү хас. Аларда ана телебезнең матурлыгы һәм камиллеге, үткенлеге һәм байлыгы чагыла. Фольклор әсәрләреннән әдәби иҗат эшендә нәтиҗәле файдалануның гүзәл үрнәкләрен без Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәрендә күрәбез.

Мәкальләргә охшаш тагын бер төр – канатлы сүзләр. Аларның мәкальләргә охшашлыгы шулкадәр ки, халык телендә йөри-йөри канатлы сүзләр мәкальләргә әверелергә мөмкин. Г.Тукай, М.Гафури, Һ.Такташ кебек күренекле шагыйрьләребезнең күп санлы канатлы сүзләре, халык телендә мәкальләр белән беррәттән әйтелеп йөриләр. Мисал өчен, Тукай шигырьләреннән мәкаль җыентыкларына күчкәннәр. Алар 150 гә якын исәпләнә.

Кыскасы, бу ике арадагы бәйләнеш әдәби әсәр теленең матурлануына, баюына һәм камилләшүенә һәрьяклап ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры. – Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.
2. Бәширов Б.Б. Бүген дә, иртәгә дә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 272 б.
3. Сүз эчендә хикмәт бар: Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 1999. – 287 б.

# НАЗВАНИЯ ГОР В ЯКУТСКОМ ГЕРОИЧЕСКОМ ЭПОСЕ ОЛОНХО

*Докторова К., г. Якутск, ГБНОУ РС(Я) РЛИ, X класс*
*Науч. рук. – учитель якутского языка ГБНОУ РС(Я) РЛИ, специалист Музея Письменности СВФУ им. М.К. Аммосова, аспирант Института филологии СО РАН Стручкова Я.В.*

На современном этапе развития якутского языкознания актуальным является масштабное исследование языка героического эпоса олонхо, т.к. он, будучи вершиной всех жанров устного народного творчества якутов большую ценность представляет и в собственно лингвистическом плане [3: 26].

Ороним – собственное имя любого элемента рельефа земной поверхности (положительного и отрицательного), т.е. любого орографического объекта: названия гор, хребтов, долин, пиков, оврагов [2: 105].

Целью данной работы является лексико-семантическая классификация названий гор в героическом эпосе олонхо.

Актуальность выбранной темы обусловлена отсутствием исследования названий гор героического эпоса олонхо, которые несут ценнейшую лингвистическую, этнографическую и историческую информацию.

Горы как пространственный элемент часто упоминаются в экспозиционной части олонхо и обрамляют пределы *Аан Ийэ Дойду* ‘мать-земля’ [1: 118].

В данной работе рассмотрены оронимы в 22 героических эпосах. В ходе исследования были отобраны названия 50 гор и 27 других орографических объектов, всего 77 оронимов. Их наибольшее количество оказалось в олонхо И.И. Бурнашева-Тоҥ Суоруна «Сын лошади Богатырь Дыырай» – 22 названий.

Оронимы при анализе были классифицированы нами по 9 лексико-семантическим группам.

Особую семантическую категорию названий в олонхо составляют ***горы, связанные с реальными географическими объектами.*** Таким примером является гора *Дьааҥы* ‘Голец; голый утес, высокая каменистая гора с обнаженной вершиной’, которая встречается в героических эпосах «Уолусхан Улаан аттаах Үһүк Туйгун бухатыыр», «Дьыырай Бэргэн», «Хорула Боотур». Скалистые останцы горных пород, представляющие собой причудливые формы, в якутском языке обозначаются как *Туруук таас хайалар* ‘Стоячие горы’ и *Киһилээх хайалар* (букв.: горы, имеющие человека), которые упоминаются в олонхо П. Оготоева «Элэс Боотур».

В якутском героическом эпосе олонхо выделилась ***группа гор, отражающие размер объекта***. В олонхо Н.М. Тарасова «Ала Туйгун» встречается гора *Үрдүк Хайа* ‘Высокая гора’; в олонхо Ю.П. Борисова «Баһырҕастаах аттаах Баабый Баатыр» – *Баараҕай Мыраан Хайалар* ‘Громадные, исполинские горы’; в эпосе И.И. Бурнашева-Тоҥ Суорун «Сын лошади Богатырь Дыырай» – *Күтүр Таас Хайа* ‘Громадная, массивная гора’.

Разные ***формы орообъекта*** передаются в названиях различными способами. В олонхо «Сын лошади Богатырь Дыырай» встречаются следующие названия оронимов: *Очуос Таас Хайа* ‘Утесистая гора’, *Туруору Таас Хайалар* ‘Стоячие горы’, *Дэбилгэ Хайа* ‘Растущая гора’.

***Названия гор, указывающие на слагающие породы, почвы, минералы***. В олонхо встречаются названия гор, образованные от названий металлов: *тимир* ‘железо’ – *Килэгир Тимир Дэриэспэ Таас, Тимир Күкүр Таас Хайа*; *көмүс* ‘золото, серебро’ – *Көмүс Дуулла Хайа*; *алтан* ‘медь’ – *Алтан Хайа*. А также встречаются оронимы, указывающие на почву: *Буор хайа* ‘Земляная гора’, *Дэриэспэ Хайа* ‘Дресвяная гора’.

***Оронимы, отражающие цветовую характеристику объектов***. Ороним *Үрүҥ Таастаах Хайа* ‘Гора из белых камней’ часто встречается в текстах эпоса. Ороним *Хара Таас Хайа* ‘Черная скалистая гора’ упоминается в олонхо И.И. Бурнашева-Тоҥ Суорун «Сын лошади Богатырь Дыырай». Прилагательное *кыһыл* указывает на наличие красных глин и красных скалистых пород камней: *Кыһыл Хайа* ‘Красная гора’.

***Числовые показатели в оронимах***. По частоте употребления на первом месте стоит числительное *үс* ‘три’. Например, горы *Үс биэрэстэ Үрдүктээх Олох Таастар*. Также встречаются числа *два* и *девять*, например, в олонхо И.И. Бурнашева-Тоҥ Суорун «Сын лошади Богатырь Дыырай» мы находим оронимы *Икки Суоруна Таас Хайа* и *Тоҕус Туой Саар Булгунньах* .

***Оронимы, содержащие зоонимы***. По представлениям древних якутов, конь – животное божественного происхождения. Наверное, поэтому это лексема *ат* ‘конь’ часто участвует в образовании оронимов, например, *Ат Хайа* (букв.: конь-гора).

***Оронимы, содержащие информацию о событиях***. В героическом эпосе сражения происходят на горах, поэтому в текстах олонхо встречаются следующие названия гор: *Кыргыһар Кырыы Хайа* ‘Скала для сражений’, *Иирээннээх Эҥэр Хайа* ‘Гора раздора’, *Охсуһар Очуос Хайа* ‘Утес для битв’; *Охсуһар Очуос Хайа* ‘Утес для поединков’,

*Кыргыһар Кындыа Хайа* ‘Скала для схватов’; *Кыргыһа Турар Кындыа Хайа* ‘Бьющиеся строптивые скалы’.

***Оронимы, связанные с верованием народа***. Оронимы с лексемой *ытык* встречаются довольно часто, например, *Ытык Хайалар* ‘Священные горы’, *Ытык Дуулла Хайа* ‘Священная мощная гора’.

Названия гор в героическом эпосе несут важную культурно-историческую информацию и служат одним из источников, используемых в истории, этнографии и лингвистике.

**Литература**

1. Ефимова Л.С., Павлова О.К. Структура олонхо северной региональной традиции якутов: вступление // Вестник Калмыцкого института гуманитарных исследований РАН. – Элиста, 2016. – С.102-108

2. Подольская Н.В. Словарь русской ономастической терминологии. – М., 1978. – 199 с.

3 Роббек Л.В. Лексико-семантические особенности языка героического эпоса олонхо. – Новосибирск: Наука, 2014. – 128 с.

## ХӘЗЕРГЕ УКУЧЫНЫҢ СМАЙЛЛАР БЕЛӘН АРАЛАШУЫ

*Закирова А., Саба р-ны, “Үсеш” Шәмәрдән лицее, X сыйныф*

*Җит. – Закирова Ә.М.*

Интернет пәйда булу белән, телгә игътибар кимеде дигән фикерләрне еш ишетергә туры килә. Компьютерлаштыру телләргә, бигрәк тә татар теленә бик нык тәэсир итә. Әйтик, “ВКонтакте”, “Одноклассники”, “Фейсбук”, “Инстаграм” һәм башка социаль сайтларда утыручылар татарча уку-язуны онытып бара, дисәң дә була. Интернет челтәрендә татарча клавиатура була торып та, яшьләр рус телендә генә язышa. Аралашканда өтер, нокта, сорау билгесе кебек тыныш билгеләрен куеп торуның кирәген тапмыйлар. Куштырнаклар, җәяләр, ике нокта, ноктaлы өтерләрне укучылар дәреслекләрдә генә күрәләр. Шулай ук баш исемнәрне дә кечкенә хәрефтән язу күренеше бар. Мәктәп укучысы компьютерда, телефонда татарча сөйләмне урыслаштырып язгач, мәктәптә татар теленнән диктант язганда урыслаштыруның йогынтысы чагылачак. Иң еш җибәрелә торган хаталарның берсе – “ә” хәрефе урынына “э” язылу очрагы көннән көн арта гына

Белгәнебезчә, язмача аралашу экстралингвистик чаралардан мәхрүм. Мәсәлән, ым, ишарә, хәрәкәтләр һ.б. Әмма язмача сөйләмдә төрле тел чаралары, символлардан файдаланырга була. Укучыларның көне тоташ телефон белән бәйле булганга күрә, алар еш смайллар кулланалар. Интернет челтәре аларның санын ай саен арттырып тора. Укучыларның аларга карата кызыксынулары зур, башкалардан аерылып тора торган смайллар кулланыр өчен аларны акчага сатып та алалар.

Смайл – язуда эмоцияне тапшыру чарасы. Ул узган гасырның 70 нче елларында ук барлыкка килгән. Башта алар компьютер уеннарында да кулланылган булсалар, заман технологияләре зур үсеш алгач, аралашу киңлекләренә дә үтеп керә.

Интернетта аралашу барышында без әңгәмәдәшебезне күрмибез һәм шул вакытта смайллар ярдәмгә килә. Шартлы рәвештә смайлларны 2 төркемгә аерырга мөмкин:

1) пунктуация тамгасы ярдәмендә барлыкка килгән смайллар;

2) рәсем тәшкил иткән смайллар.

Смайлларның беренче төре узган гасырда ук барлыкка килгән. Карнега-Меллон университеты галиме Скотт Фалман, ике ноктаны, сызыкны һәм җәяне кешенең уңай эмоциясен тасвирлау өчен кулланган – :-) .

Күренекле язучы Владимир Набоков та кешенең эмоциясен тасвирлау өчен пунктуация билгесе кулланган. Алга таба әлеге тамгалар системасы баетылган. Бүгенге көндә мәктәп укучыларына таныш булган пунктуацион тамгалар җыелмасы:

(^ _ ^) – елмаю;

(9 _ 9) – төне буе йокламадым;

8-) – кара күзлекле кеше;

(- _-) – битарафлык;

(>_<) – елаю, кәеф төшү;

(º_º) – ярату;

(‿‿) – оялу;

(*_*) – шаккату, гәҗәпләнү;

[:] – робот.

Икенче төргә хас смайл 1982 нче елның 19 нчы сентябрендә Microsoft компаниясе тарафыннан кулланыла башлый. Вакытлар узу белән, аларның саннары арта. Бүгенге көндә “мем” дигән төрен дә аерып чыгарырга мөмкин.

“Смайликларны” без вербаль булмаган аралашу чарасына кертә алабыз. Алар ярдәмендә төрле эмоцияләрне, уй-хисләрне, теләкләрне җибәреп була. Мәсәлән, елмаю, орышу, көлү, усаллану, ярату, нәфрәт, мактау, хөрмәтләү, йокы, ашыйсы килү һ.б. Сүзсез генә аңлашу барлыкка килә. Бер тамга белән генә аралашучыга билгеле бер вакыйгага карашыңны, хис-кичерешләреңне белдереп була. Кайбер смайликлар хәрәкәт барлыкка китерәләр яки анимацион булалар. Укучылар арасында иң актив кулланылган смайлларны карап китик:

Ярату, рәхмәт әйтү йөзеннән – кызыл йөрәк;

Исәнләшү – уң кул сурәте;

Кайдадыр бару яисә мәктәпкә бару һәм кайтып китү – баручы кыз яки малай;

Укытучы – күзлекле апа сурәте;

Тырнак ясау (маникюр) – тырнаклар белән лак сурәте;

Нииндидер мөһим хәбәр – SOS язуы;

Кылану, кызык икәнен аңлату – күзләрен каплаган маймыл.

Әлеге мисаллардан кала кешенең эмоцияләрен, хәрәкәтләрен, тамгаларны, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын, ашамлыклар һәм эчемлекләрне, сәламәт яшәү рәвешен, предметларны, флагларны һ.б. күренешләрне аңлаткан символлар да бар. Укучылар арасында смайллар белән генә аралашу да популярлык казана. Смайллар ярдәмендә гади җөмләләр төзелә. Шулай ук мәктәп укучылары арасында кинофильм исемнәрен смайллар белән язу күренеше активлаша башлады.

**Әдәбият**

1. Абдуллина Р.С. Сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 527 б.

2. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 93 б.

3.Галиуллина Г.Р Фейста чиз шәпский! Яки татар яшьләре сөйләменә бер караш // URL: http://idel-tat.ru/festa/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 03.04.2019).

4. История происхоцдения смайла // URL:https://10pix.ru/istoriya-proishozhdeniya-smaylika.html (дата обращения: 29.03.2019).

5.Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

## ИСТОРИЯ СТАНОВЛЕНИЯ И ТРАДИЦИИ ТАТАРСКОГО ЖЕНСКОГО ПРОСВЕТИТЕЛЬСТВА

*Закирова Д., г. Казань, МАОУ «Гимназия-интернат №4, XI класс*

*Рук. – Гимадиева Г.И.*

Вторая половина XIX – начало XX веков – эпоха перемен в социально-экономической и культурной жизни татарского народа: происходят изменения в устоявшихся ценностях, поиски новых ориентиров. В 1890 году усилиями Г.М.Галиева (Баруди) и его жены Магруй абыстай была открыта первая женская новометодная школа. Позже такие школы появились и в других регионах России, где проживало татарское население. Наибольшую известность приобрели Иж-Бобинская школа (Вятская губ.), школы Лябибы Хусаиновой, Маргуй Музаффарии, Рабиги и Сагадат Амирхании, Фатихи Аитовой в Казани, Фагимы Гайнутдиновой в Чистополе, Фатимы Агдамовой, Магубы Рамеевой, Багбостан Мукминовой в Оренбурге, Галимателбанат Биктимировой в Касимове, Ханифы Урмановой в Благовещенске и Агафуровых в Екатеринбурге. Открывались аналогичные школы для девочек в Рязани, Уфе, Астрахани, Перми, Томске, Симбирске, Ростове-на-Дону, Москве.

В архивах сохранились как заметки иностранных ученых-путешественников, так и работы русских исследователей о национальной системе образования татар, о «девичьих школах». Например, Сперанский в историко-этнографическом очерке «Казанские татары» пишет: «…Между татарками мало найдется таких, которые не умеют надлежащим образом читать и писать. Кроме грамоты, они обучаются шитью, вышиванию шелками и золотом».

Есть материалы о соплеменницах, которые после получения образования в учебных заведениях высшего разряда (медресе) сдавали экзамены по курсу гимназии или учились в вузах России и зарубежья. Уже найдены сведения о сотнях татарок из разных губерний, сумевших получить элитарное образование. Выдержав дополнительные экзамены (как иноверки), они наряду с русскими девушками поступали на курсы: Бестужевские, Высшие женские педагогические, Высшие медицинские, Стебутовские сельскохозяйственные, Раевские научные, Политехнические, а также в университеты. Так, Сафия Сыртланова и Мариам Габдрахманова закончили Женевский университет. Позже Сыртланова вышла замуж за немца; ее сын, носивший фамилию Менде, знал язык матери, занимался изучением татарского народного творчества, а в годы Второй мировой войны спасал наших военнопленных в германских концлагерях.

В Сорбонне учились пять татарок, одна даже осталась преподавать в этом элитном французском университете. Сару Ахмерову после окончания Бестужевских курсов отказались утвердить приват-доцентом в русском вузе, и девушка вынуждена была уехать за границу и работать в немецком университете. Как видим, в престижных европейских учебных заведениях татарок ценили, а в России к ним относились с недоверием Шакуловой. В 1913 году она получила диплом об окончании факультета А первыми татарками, поступившими в Казанский университет, были Гайша Апанаева (медфак) и Амина Мухутдинова (медфак, через год перешла на юрфак). Это случилось в 1915 году.

Короткой была жизнь другой просветительницы – Фатимы-Фариды Вагаповой-Наврузовой. Она родилась в 1889 году в Чистополе в состоятельной семье. Училась у своего земляка, выпускника Каирского университета Ибрагима Камалова, затем занималась самообразованием в Стамбуле. По возвращении в 1908 году на родину преподавала, писала актуальные статьи. Затем с просветительской целью вместе с мужем отправилась в Томск, где на свои средства учредила газету «Сибирия» и добилась открытия за счет казны школы для татарских

девочек. Писатель и общественный деятель Гаяз Исхаки посвятил ей драму «Мугаллимэ» («Преподавательница»).

Я завидую образованным татаркам, жившим в начале двадцатого столетия: мужчины их уважали – за ум, красоту, чувство собственного достоинства, поддерживали их идеи, посвящали им свои произведения. А в советские времена многие из этих благородных женщин оказались в опале и даже прошли ад сталинских лагерей. Не всех мы еще вернули из забытья.

Основателями таких школ для татарских девочек были представители крупной татарской буржуазии. Среди них особое место занимает татарская мектебе для девочек Фатихи Абдулвалеевны Аитовой.

После смерти своего отца, Троицкого купца-миллионера А.Яушева, Ф.А.Аитова (1866–1944) стала единственной наследницей его состояния. Все деньги она хотела использовать в деле просвещения татарских детей.

Открытие мектебе состоялось 27 августа 1909 года.

В 30 женских высших учебных заведениях к 1917 г. училось 38 913 женщин.

Среди девушек, принятых в Казанский университет уже на правах полноправных студенток, были и две татарки – Гайша Апанаева и Амина Мухитдинова. Обеих зачислили на медицинский факультет, хотя затем А. Мухитдинова перевелась на юрфак.

**Литература**

1. Биктимирова Т.А. Ступени образования до Сорбонны. – Казань: Алма-Лит, 2003. – 184 с.

2. Биктимирова Т.А. Ил язмышын салып иңнәренә. – Казан: Алма-Лит, 2006. – 239 б.

3. Иванов А. Е. Студенчество России конца XIX – начала XX века. – М., 2010. – 333 с.

4. Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / төз.-авт. А.Х. Мәхмүтова. – Казан: Җыен, 2012. – 558 б.

## ЯЗЫК ЖЕСТОВ В МОЕЙ СЕМЬЕ

*Каримова К., г. Казань, МБОУ «Многопрофильная школа №181»*

*Рук. – Валиуллина А.Ф*

В один год я выучила базу жестового языка. Я наблюдала за общением между родителями, во время того, как мама использовала жесты, она проговаривала слова вслух и таким образом я сопоставляла определенный жест с ее устной речью. На мои громкие возгласы и музыку они никак не реагировали. Я понимала, что родители глухие, но какое-то время я думала, что они разыгрывают меня, и что на самом деле они слышат. Я пошла в детский сад в 3 года. У меня сложно формировалась русская устная речь, так как у родителей были

проблемы с произношением слов и ударениями. И все равно я была общительной и легко находила друзей. Мои бабушка с дедушкой по маминой линии в детстве учились в обычной школе. Они всегда разговаривали на татарском языке, пытались научить меня этому языку, но мне было сложно. В детском саду нас учили татарскому, и моя воспитательница жаловалась маме, что я недостаточно хорошо разговариваю на нём.

Мою маму зовут Эльмира. Мама родилась в Казани. Она заболела бронхитом в 5 месяцев, у неё болели уши. Когда она лежала в больнице, ей делали уколы, и из-за них она потеряла слух. Ей было 1 год 8 месяцев, когда она с родителями переехала в Азнакаево. В 5 лет она пошла в подготовительную группу в школу-интернат города Бугульмы для слабослышащих детей. В 6 лет мама переехала учиться в школу-интернат города Елабуги для глухих детей. Там она жила и училась до 8 класса. Учительницы и воспитательницы общались с детьми на языке жестов, учили их правильно разговаривать. Дальнейшее обучение мама продолжила в школе-интернате им. Е. Г. Ласточкина г. Казани вплоть до 12 класса. В то время глухие и слабослышащие дети не обучались татарскому и иностранному языках в школах. После школы мама устроилась швеёй в Азнакаево. Мама может читать слова по губам, если появляются трудности, то устная речь переходит в письменную форму. В 2001 году мама вышла замуж, через год родилась моя старшая сестра, а в 2006 году появилась я.

Моего папу зовут Кахрамонжан. Он родился в Узбекистане, пошел в 1 класс в школе для глухих детей. Затем с братом и родителями он переехал в Татарстан. В Казани он снова учился в первом классе. Его родители и старший брат Наиль тоже слабослышащие. Папа вырос и учился в Казани до 8 класса. После школы он пошел работать на завод слесарем, потом в частную фирму плотником. Ему намного труднее общаться с людьми, чем маме. Папе в разы чаще нужен переводчик. Моя старшая сестра почти с самого детства выступала главной переводчицей. Смотря на то, как ей приходилось жить в сложной плоскости между мирами глухих и слышащих, это меня иногда беспокоило. А иногда радовало, ведь мне казалось очень важным и интересным быть взрослым. Начиная примерно с 8 лет я заняла её место. К такому темпу жизни мы с сестрой быстро привыкли. Для нас это было рутиной. Когда всю жизнь живешь с особенностями родителей, перестаешь замечать, что что-то отличается от нормы, и ничего странного в этом уже не видишь. Но иногда было неудобно, например, когда родители использовали неправильные ударения в

словах или неправильно формулировали свои мысли, не контроллировали громкость голоса.

Мама всегда говорила, что для неё слух — это что-то очень ценное. Её частым вопросом было то, как звучит пение птиц, звуки машин, голос её детей и её собственный.

Наше общество бывает очень несправедливым и крайне равнодушным к глухим. Мне бы очень хотелось, чтобы про глухих людей и про их проблемы знало как можно больше людей, которые с пониманием и уважением относились бы к этому недугу; к трудностям, которые вероятнее всего возникнут при общении с глухим человеком. Глухих или слабослышащих считают «отстающими от нормы», называют глупыми, неполноценными. Слышащие получают около 90% информации, а глухие только около 30-50%. Сейчас многие телевизоры оснащены программой, обеспечивающей субтитры при трансляции общедоступных каналов. Эта функция позволяет людям с нарушениями слуха иметь доступ к информации, как и остальным телезрителям. Многие слышащие даже не догадываются, но каждый глухой знает этот секрет телевизора. Бывали ситуации, когда не было субтитров или сурдопереводчика на том или ином канале и нам с сестрой приходилось переводить звуковую информацию на языке жестов для мамы и папы.

Общество не принимает и не хочет принимать глухих и слабослышащих людей. Если бы все глухие дети в России могли получить соответствующее образование и развитие, глухота стала бы для них особенностью, а не инвалидностью. Именно так дело обстоит у глухих в Европе и США. До сих пор нельзя сказать, что глухие, как любое полноправное меньшинство, в достаточной мере могут участвовать в жизни общества, иметь доступ к информации, наравне со слышащими получать образование, успешно трудоустраиваться, быть экономически самостоятельными. Глухие воспринимают окружающий мир иначе, не как мы мы, но при этом они не могут представить, как это возможно – слышать, и что это такое. У них есть нарушения слуха, но зато другие чувства обострены. Они не слышат (или почти не слышат) музыку или звонок телефона, но чувствуют вибрации. И несмотря на это, все мы – люди, как с биологической, так и с психологической точки зрения, и относиться к глухим нужно как к обычным людям. Многие здоровые люди считают, что глухие – это бедные-несчастные инвалиды. Но при этом глухие ведут максимально полную жизнь: учатся, занимаются бизнесом, водят машину, заводят семьи, воспитывают детей. Для этого и нужен ВОГ (всероссийское общество глухих) – чтобы бороться за права глухих.

Лечить их не надо, они не больны. Создайте глухому условия, дайте ему жестовый язык, образование, и он ни в чем не будет отставать от слышащих. В мире ведь множество глухих спортсменов, художников, артистов, бизнесменов. Глухота не помешала Франциску Гойе, Томасу Эдиссону или Людвигу ван Бетховену реализоваться, работать, создавать шедевры.

В 2012 году в России Русский жестовой язык получил статус официального языка, но его до сих пор многие пугаются.

## ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВНЫҢ «БЕР КӨН – БЕР ГОМЕР» РОМАНЫНДА «ДӨНЬЯ» КОНЦЕПТЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

*Кашапова З., Казан ш., А.Алиш ис. 20 нче гимназия, XI сыйныф*
*Җит. – Фәхретдинова Г.М.*

Соңгы елларда тел белемендә күп кенә төшенчәләрне дөнья тел картинасына бәйләп тикшерү, өйрәнү һәм анализлау өстенлек итә башлады. Фән урынында гына тормый, үсә, аның гыйльми-фәлсәфи концепциясе тирәнәя. Нәкъ менә гасыр башында фәндә үзгәрешләр, борылышлар булу тенденциясе күзгә ташлана. Тел гыйлеме фәне – җәмгыятьнең көзгесе, ул җәмгыятьтә барган процессларга битараф булып кала алмый. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр белән параллель рәвештә фәндә дә төрле үзгәрешләрне күрәбез. Билгеле бер язучының концептларын анализлау, ягъни алар иҗат иткән әсәрләргә концептуаль анализ ясау, милли дөнья картинасын күзаллау, милләт менталитетын билгеләү, милләт вәкилләренең дөньяга карашын, яшәү мәгънәсен билгеләү өчен бик мөһим фактор булып тора.

Дөнья сүзенең аңлатмасы күпкырлы. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә генә дә әлеге төшенчәнең утызга якын аңлату очрагы теркәлгән. Шулай ук әлеге концептны («дөнья» концепты) җир алмасы, җир асты куышы, җир рентасы, җир алу, җир өсте һ.б. тезелмәләр составында күзәтергә була. «Дөнья» концепты күп мәгънә төсмерләренә ия булганын күздә тотып, тел гыйлемендә кулланылучы аның түбәндәге вариантларын да атап үтәргә кирәк. Мәсәлән, планета, Җир шары, Җир, галәм, Җиһан, Галактика, дала, космос һ.б.

Ч.Айтматовның «Бер көн – бер гомер» әсәрен анализлау барышында, язучының «дөнья» концепты төшенчәсен бирүе үзенчәлеге игътибарга алынды. Һәм бу төшенчәләрнең бирелеше авторның геройлар аша вакыйгаларга бәйле хисләр төрлелеге белән нигезләнде.

Конкрет мисаллар, әсәрдән китерелгән өзекләр ярдәмендә әлеге концептның кулланылышы һәр автор өчен уртак һәм аермалы булган үзенчәлекләре ягыннан, төрле категорияләргә бүленеп, классификация

ясалды, әдип тарафыннан «дөнья» концептының төрле мәгънәләрен куллануы ачыкланды. Ч. Айтматов «Бер көн – бер гомер» әсәрендә «дөнья» концептының кулланылыш дәрәҗәсен, даирәсен ачыклау йөзеннән әсәрдә әлеге сүзнең төрле мәгънәләрдә бирелгән өзекләре мисал итеп алынды.

Әсәрдә әдип кеше белән җәмгыятьнең, кеше белән дөньяның мөнәсәбәтен тикшерә, аңа бәя бирә. Кешенең дөнья белән бәйләнеше гаять көчле, алар бер-берсеннән башка яши алмыйлар. Яшәеш прогрессив үсештә булсын өчен, кеше дөньяның матурлыгын сакларга, аны үстерергә, тарихи хәтерне, гореф-гадәтләрне, үзенең тамырын хөрмәт итәргә тиеш. Әсәрнең төп герое – Идегәй Җангилдин чын җир кешесе образы, укучыга үрнәк һәм шул ук вакытта таяныч буларак тасвирлана. Кешенең бу дөньяда олы зат булуын дәлилли. *Дөнья* сүзе могҗиза мәгънәсендә бирелә. Могҗизаны күзаллау йөзеннән, әсәрнең үзенә мөрәҗәгать итеп, түбәндәге өзеккә игътибарны юнәлтик: «*Дөньяда* нинди генә могҗизалар юк... Кайсы чын икәнен кем белсен. *Дөнья* киң, аның күп серләре адәмнең алмадай башына сыймый».

Әлеге концептны әсәр исеме белән бәйләп тә аңлата алабыз. Гомер – кешенең дөньяга килүе, дөньяда яшәве һәм аннан китүе. Шуңа күрә «дөнья» концепты Җир, Галәм, космос, планета, Галактика берәмлегендә карала. Авторның әйтәсе килгән сүзе: «Үзе яшәгән Җир, Вакыт өчен, һәркем җаваплы». Конкрет әсәргә килгәндә «дөнья» концепты биредә берничә мәгънә төсмере функциясен үти: җир шарының өске катлавы, Җир – бу сүзнең баш хәрефтән язылуы җирнең якын, изге булуына басым ясый, үз күчәрендә һәм Кояш тирәсендә әйләнә торган, тереклек дөньясы булган планета, Галәм, Галактика, космос, туган, үскән ил, туган җир мәгънәсендә һ.б.

«Дөнья» концептының кулланылышы, күбрәк очракта, җир кешесен тасвирлау, аның кылган эш-гамәлләре, үз-үзен тотышы, аның хыяллары, уйлары белән бәйле. Вакыйгаларның тирән мәгънәсен, аларның серле бәйләнешен, кешеләрнең эчке кичерешләрен язучы «дөнья» концепты белән элемтәдә биреп, ихсанның дөньяның баласы – иң кирәкле кадерлесе икәнен ассызыклый. Берәү дә ялгыз гына котыла алмаячак. Үзеңне һәм Дөньяны коткарырга кирәк. Моның өчен тарихи хәтер, гореф-гадәтләр, йолалар, нәсел чылбырын белү зарур.

*«Ана – Бәйетне **җир** белән тигезләргә ярамый».*

Бу өзектә *җир* сүзе җир шарының өске катлавын күрсәтә. Ә менә җир кешеләре дигәндә автор дөньяда гомер кичерүче, җир белән тыгыз бәйләнештә булган, җирнең яшәешенә җаваплы караган инсаннарны күз алдында тота. «Җир кешеләре» дөньяның яшәү чыганагы хезмәтен үти.

«Дөнья» концепты автор тарафыннан Җир, Галәм, Җиһан, Галактика, планета кебек сүзләр белән баетыла. Төрле планеталарда кеше затына охшаган вәкилләрне табу, күк җисемнәрен өйрәнү, яңа планеталар очу кешелекнең иң зур хыялы. Ул кул җитә алмаслык, тормышка аша алмаслык билгесезлек, өметсезлек. Әйе, өметсезлек. Халыкның гореф-гадәтләреннән, йолаларыннан читләшүе, аларны онытуы кешене әхлакый деградациягә, ә милләтне (күләмле итеп алсак – кешелек дөньясын) үлемгә, онытылуга алып килә.

Фәнни-фантастик сюжет линиясен кертү, романның композициясен катлауландыра. Әсәрдә ике дөнья янәшә яши: Буранлы разъезды һәм Җир шары (дөнья), галәм, планеталар, космос һ.б

Иҗатында «дөнья» концептын кулланып, Ч. Айтматов казах халкының җиргә карата булган борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, ышануларын, йолаларын, мифларын оста сурәтләп бирә алган.

Без тикшергән әсәрдә геройлар – үз чорларының каһарманнары. Аларның гадел, игелекле, олы җанлы, иманлы, шул вакытта тормыш авырлыгыннан кырыс, аз сүзле булулары билгеләп үтәргә була.

**Әдәбият**


1. Айтматов Ч.Т. Бер көн – бер гомер. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 287 б.
2. Гарипова Л.Р. Лингвокультурологические особенности концепта «Дөнья» («Мир») / Материалы респ. научно – практич. конф. – Казань: ТГГПУ, 2005. – С. 65-67.
3. Җамалетдинов Р. Р. Тел һәм мәдәният. Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. – Т. 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 832 б.


## «КРАСНАЯ РОМАШКА» МУСЫ ДЖАЛИЛЯ В РАЗНЫХ ПЕРЕВОДАХ НА РУССКИЙ ЯЗЫК


*Лагунова А., г. Набережные Челны, МАУДО «ГДТДиМ №1», обучающаяся объединения «Флексия», VIII класс*

*Рук. – Грошева Е.Л.*


Актуальность темы подтверждается двумя факторами. Первый заключается в том, что 2021 год был объявлен в Республике Татарстан Годом родных языков и народного единства. В нашей республике давно сосуществуют русский и татарский языки, при этом они обогащают друг друга, но не теряют своей самобытности. Русская и татарская литература тоже обогащают и разнообразят друг друга за счёт переводных произведений и труда их создателей, переводчиков.

Второй фактор объясняется необычайной востребованностью обществом темы исторической памяти, и особенно памяти о событиях Великой Отечественной войны. Потому не случайно, что в последнее время сильно возросло внимание к творчеству и к

личности знаменитого татарского поэта Мусы Джалиля. Ведь большинство его произведений о войне. Да и сама биография поэта – пример героизма и посвящения себя Родине и народу.

Доказательство тому – старт в 2018 году двух крупных международных литературных конкурсов: «Джалиловских чтений» (в Татарстане) и «Звезды Джалиля» (в Казахстане).

В «Джалиловских чтениях» мы участвовали три года подряд, и всегда на них неоднократно звучало известнейшее стихотворение «Красная ромашка», но в совершенно разных переводах. Нам стало интересно, какой же именно перевод точнее, ближе всего к оригиналу.

Наша гипотеза строилась на мнении, что перевод Ильи Френкеля, который начинается словами «Луч поляну осветил и ромашки разбудил», ближе всего к оригиналу, потому что это самый известный перевод «Красной ромашки» на русский язык. Но обо всём по порядку.

В ходе работы нами была изучена биография Мусы Джалиля, благодаря чему мы смогли выделить основные факторы, повлиявшие на его творчество.

Стихотворение Мусы Джалиля “Красная ромашка” является одним из самых знаменитых в его творчестве. Оно было написано в июле 1942 года, то есть уже в плену. В стихотворении раскрывается тема индивидуальности, весомой потери, нынешнего одиночества. Лирический герой этого произведения – красная ромашка, которая бок о бок сражалась с благородным солдатом. В стихотворении используются такие художественные средства, как эпитет, сравнение, олицетворение, метафора, антитеза, риторический вопрос. Оригинал стихотворения написан силлабическим стихом, свойственным татарскому языку, рифма использована перекрёстная.

Нам удалось отыскать пять стихотворных переводов «Красной ромашки» на русский язык: 1) И. Френкеля, 2) Р. Гардиева, 3) Ю. Кушака [1], 4) С. Северцева [2], 5) Р. Бухараева [3].

Стихотворный перевод является самым сложным видом перевода. Мы выделили его основные особенности: 1) наличие рифмы, 2) соблюдение стихотворного размера (если это возможно), 3) сохранение смысла, стиля и настроения произведения, 4) сохранение оборотов речи, средств художественной выразительности, 5) наличие у переводчика знаний в области теории литературы, поэтического таланта и опыта.

Мы сделали дословный перевод (подстрочник) стихотворения «Красная ромашка» с татарского языка на русский.

Для сопоставления стихотворных переводов с оригиналом мы разработали критерии, позволяющие сравнить произведения с точки зрения 1) формы, 2) содержания и 3) художественных особенностей.

Например, мы выяснили, что перекрёстная рифма, использованная Джалилем в Красной ромашке, сохраняется только в переводах Бухараева, Северцева и Гардиева, а два других переводчика использовали смежную рифму. Оказалось, что с точки зрения формы наиболее точным является перевод Р. Бухараева, так как в нем соблюдена и перекрёстная рифма, и количество четверостиший, и даже строгое количество слогов в строке, характерное для силлабического стиха.

Сравнивали переводы и с точки зрения художественных особенностей. Например, к слову «роса» поэт применяет эпитеты *«чистая, душистая»,* но они сохранены лишь в переводах Кушака и Френкеля. В описании красной ромашки поэт использует сравнение с кровью: «Лепестки не белые, очень красные, *как кровь*». Этот приём есть только в переводах Френкеля и Гардиева. Автор использует в стихотворении и риторический вопрос: «Как она одна оделась в красное?» Этот вопрос в разных вариациях присутствует в четырёх переводах, но в переводе Френкеля его нет совсем. В конце стихотворения использована антитеза: «Парень ушёл, я осталась». Это противопоставление сохранено только в переводе Гардиева, в остальных этот приём отсутствует.

Наконец, сравнение с точки зрения содержания. Например, в оригинале указано точное количество врагов, с которыми сражался воин – 15: «один воевал против *пятнадцати* стрелков». Или тот факт, что солдат был ранен именно в руку. Здесь лидируют переводы Р. Гардиева и С. Северцева.

После сравнения рассмотренных переводов «Красной ромашки» по всем критериям (их 21) оказалось, что наиболее близкими к оригиналу являются переводы Р.Гардиева и С.Северцева. Они совпадают с оригиналом по 15 критериям. По 13 критериям обнаружилось совпадение у перевода Ю.Кушака, по 10 – у перевода Р.Бухараева. И только по 8 – у перевода И.Френкеля.

Таким образом, наша гипотеза не подтвердилась. Оказалось, что самый распространённый перевод И.Френкеля является наименее точным. А самые точные – это переводы Р.Гардиева и С.Северцева.

А какой же перевод больше всего нравится школьникам? Чтобы это узнать, мы предложили учащимся прослушать «Красную ромашку» во всех пяти переводах и затем проголосовать за наиболее понравившийся. Самыми красивыми и поэтичными дети признали переводы И.Френкеля и Ю.Кушака.

Конечно, создание стихотворного перевода – целое искусство. Точность и красоту далеко не всегда удаётся совместить. И если мы хотим в полной мере насладиться благозвучием, смыслом и художественными особенностями стихотворения, то лучший способ – читать его на языке оригинала.

**Литература**

1. Джалиль М. Вольные ветры. – М.: Малыш, 1981. – 60 с.
2. Джалиль М. Сквозь бури. – М.: Советская Россия, 1986. – 133 с.
3. Джалиль М. Стихотворения. – М.: Художественная литература, 1986. – 152 с.

## ТАРИХИ ӘСӘРЛӘРДӘ ИСКЕРГӘН СҮЗЛӘР

*Матзянова А., Саба р-ны, Олы Кибәче урта гомумбелем бирү мәктәбе, XI сыйныф*
*Җитәкче – Гафиятова Ә.Ф.*

Минем фәнни-тикшеренү эшемнең максаты – В.Имамовның “Сәет батыр” һәм Җ. Рәхимовның “Батырша” китапларындагы искергән сүзләрне чагыштыру.

Искергән сүзләр тарихи сүзләргә һәм архаизмнарга бүлеп өйрәнелә. Кулланылыштан төшеп калган предметларның, күренешләрнең исемнәре тарихи сүзләр дип атала. Алар беренче чиратта тарихи хезмәтләрдә урын ала. Ә архаизмнарны тарихи сүзләрдән аерып карарга кирәк. Алар нинди дә булса төшенчәләрнең, күренешләрнең искергән атамалары.

В.Имамовның “Сәет батыр” һәм Җ.Рәхимовның “Батырша” китапларындагы искергән сүзләрне тематик төркемгә бүлгәч, алар арасыннан гаскәр һәм корал атамалары, туганлык терминнары, һөнәр иясенең исемнәрен аерып чыгардым. Мәсәлән: старшина, кенәз, тархан, өяз, кала, тоткын, кабилә, кардәш, морза, дәресханә һ.б. Әсәрләрдә башка өлкәләргә караган атамалар да еш очрады. Гомумән, искергән сүзләрне тематик төркемгә бүлеп караганда, һәр ике язучы да урын һәм һөнәр иясе исемнәрен күбрәк кулланганнар, еш кабатлана торган сүзләр дә байтак.

Искергән сүзләрне сүз төркемнәре ягыннан карасак, алар арасында иң күп урынны исем сүз төркеме алып тора, башка сүз төркемнәре азрак кулланылган.

Искергән сүзләрне килеп чыгышлары ягыннан анализлаганда, аларны гарәп – фарсы, төрки – татар һәм рус сүзләренә аерып булыр

иде. Гарәп – фарсы сүзләре: шаһ, сәүдәханә, дәресханә, гаурәт, миһман, фәрман, мөһер, яран, кәнизәк, пот, дәрвиш, хаким, чирү, сәмән, хәрам, хөкемдар һ.б. Төрки – татар сүзләре: ясак, кабилә, кала, сәмән, мәдрәсә, шөбхә һ.б. Бу сүзләр татар теленә төрле заманнарда, төрле юллар белән килеп кергәннәр. Рус теленнән кергән сүзләр: старшина, драгун, приказчик, император, бояр, губерна һ.б

Фәнни эшемә йомгак ясап шуны әйтәсем килә: үткен телле публицист, "Батырша" әсәре белән танылган Җәмит Рәхимов та, "Сәет Батыр" китабы авторы тарихчы Вахит Имамов та искергән сүзләрне күп кулланганнар. Һәр ике язучыда да күпчелек сүзләрне гарәп- фарсы алынмалары тәшкил итә. Рус теленнән кергән сүзләр ике язучыда бер үк сүзләр кабатлана. Шунысы куанычлы: соңгы елларда искергән сүзләрнең күбесе яңадан кулланылышка кереп бара. Димәк, халкыбызның үткәненә кызыксыну, телебезгә хөрмәт арта дип уйлыйм мин.

**Әдәбият**


1. Гарәпчә-татарча – русча алынмалар сүзлеге. – Казан: Иман нәшр., 1993. – 853 б.
2. Имамов В. Сәет Батыр. – Яр Чаллы: КАМАЗ, 1994. – 382б.
3. Ногманов М. XII – XIII йөзләрдәге русча – татарча кулъязма сүзлекләр. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1969. – 110 б.
4. Рәхимов Җ. Батырша. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1994. – 472 б.
5. Сафиуллина Ф. С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: Хәтер, 2001. – 383 б.


## ҮЗ ИЛЕМДӘ – ҮЗ ТЕЛЕМДӘ


*Минһаҗева Д, Мөслим р-ны, Тойгелде урта мәктәбе, X сыйныф*

*Җит. – Дәүләтова Р.Ф.*


Һәр халыкның – үз тарихы, үз кыйбласы, үз гореф-гадәтләре, үз теле. Бик кадерле, бик ягымлы, әни кебек якын булганга аңа безнең халык ана теле, туган тел дип исем кушкан. Ана һәм туган тел! Мәңге аерылгысыз, изге төшенчәләр. Кешегә нәселенең, халкының асыл гадәт-сыйфатларын да иң әүвәл тел тәме, тел кодрәте ярдәмендә Ана бирә.

Татар теле бик бай, аһәңле һәм бөтен дөньяга билгеле тел. ЮНЕСКО тарафыннан дөньяның иң дәрәҗәле 14 теле билгеләнгән, шулар арасында татар теле дә бар. Чөнки татар теле аркылы бөтен төрки телле халыклар диярлек бер-берсе белән аралаша, аңлаша алалар.

XX гасырга кадәр телебез гарәп сүзләре белән баетылган иде, бу күренеш, ул чорда билгеле динебезгә дә бәйле рәвештә тормышка ашырылган. Ә менә XX гасыр башыннан, бигрәк тә октябрь инкыйлабыннан соң телебез рус сүзләре белән чуарлана. XX гасырның 50-60 нчы елларында сөйләмгә рус сүзләре кушып сөйләшү, бигрәк тә туган телеңне белмәү дәрәҗә санала иде.

80 нче еллар уртасында илдә демократияләштерү процессы башлангач, татар халкының милли үзаңы һәм татар теленең дәрәҗәсе

үсә башлады. Татар мәктәпләре, гимназияләре ачылды, хәтта татар теле дәүләт теле дип игълан ителде. Нәкъ шушы елларда ана телебездән рус сүзләре кысрыклап чыгарыла башлады һәм аларның урынына гарәп, фарсы, татар сүзләре кулланышка керде. Бик актив рәвештә сәнәгать, мәдәният, җөмһүрият, вәзгыять, гаилә һәм башка сүзләр лексикабызны бизи башладылар. Чөнки гарәп теле динебез теле булса, ә татар теле – безнең ана телебез, туган телебез. Билгеле, телебездә төпләнеп, тамыр җәйгән рус сүзләрен бөтенләй чыгарып бетерү дә уңай күренеш түгел. Ә рус сүзләренең күбесе татар сүзләреннән ясалганын да онытмаска кирәк. Шулай ук дөнья телләре арасындагы ассимиляция күренешен дә бер халык та инкарь итә алмый. Дөньядагы телләрнең барысы да диярлек башка телләрдән алынган алынма сүзләр белән баетылган. Һәм ул шулай дәвам итә дә. Мәсәлән, әгәр сез рус теленең аңлатмалы сүзлеген ачып карыйсыз икән, анда А хәрефенә башланган бер генә саф рус сүзен дә тапмассыз.

Соңгы вакытларда русча нәшер ителә торган газета-журналларның кайсын гына алсаң да, рус сүзләренең килеп чыгышын, куллану тәртибен һәм шул нисбәттән Россия тарихын аңлаткан язмаларга зур урын бирелә башлады. Ә безнең татар матбугатында бу мәсьәлә ни сәбәпледер аз яктыртыла. Халык үзебезнең тарихны, сүзләрнең килеп чыгу, дөрес куллану тәртибен белми, ә кайберәүләр кирәк дип тә санамый. Соңгы елларда күпчелек ата-аналар, төрле сәбәпләр табып, татарча да юньләп укый алмаган балаларыннан "вундеркинд" ясамакчы булып, рус классларына күчереп бетерделәр. Нәтиҗәдә, мәктәпләрдә татар сыйныфлары саны бик нык кимеде.

Һич яшермичә, йкейөзлеләнмичә тәкрарлап әйтик: тел бетү – халык бетү ул. Бүген 7 генә процент татар баласының туган телендә белем алуы – шуның иң аяныч дәлиле. Телебез яклауга мохтаҗ. Бөек Тукаебыз телебезнең матурлыгын ачып, аның "туган тел" дигән изге төшенчәгә әверелүе, өчен өч шарт кирәклеген язган. *Беренче шарт:*

*И туган тел, и матур тел,*
*Әткәм-әнкәмнең теле*
*Дөньяда күп нәрсә белдем,*
*Син туган тел аркылы*. [2: 164].

Димәк, беренче шарт: туган телне бөтен матурлыгы белән баланың әтисе, әнисе белергә тиеш. Алар аша ана бала да үзләштерә һәм "дөньяда күп нәрсә белә". Кызганычка каршы, бүген туган телне белүче, аны кулланучы ата-ана бик сирәк. Шул сәбәпле бала да туган телне үзләштерә алмый. "Күп нәрсә белү"дән мәхрүм кала. *Икенче шарт:*

*Иң элек шул тел белән*

*Әнкәм бишектә көйләгән.*
*Аннары төннәр буе әбкәм*
*Хикәят сөйләгән.* [2: 164].

Кая инде ул бүген бәбкәсенә туган телендә бишек җыры җырларлык аналар һәм оныкларына төннәр буе туган телдә хикәят сөйләрлек әбиләр. Алар юк дәрәҗәседә булганнарының бала карарга вакытлары калмый. Бала ана җылысын да, әби назын да тоймый кала, изге күңел җылысыннан мәхрүм итәлә. Шуңа ул каты бәгырьле булып үсә. *Өченче шарт:*

*И туган тел! Синдә булган*
*Иң элек кылган догам.*
*Ярлыкагыл ,дип, үзем һәм*
*Әткәм – әнкәмне ходам!* [2: 164]

Кая инде ул бүген татар баласына туган телендә дога уку һәм кая инде ул туган телендә үзен һәм әткә-әнкәсен яклау. Ул күптән юк инде, без андый изгелектән бик ерак торабыз. Шул сәбәпле бала күңеле иман нурыннан мәхрүм кала.

Соңгы вакытларда ата-аналарның: “Татар телендә, татар мәктәбендә белем алу балага БДИ тапшыруда кыенлык тудыра”, дигәнен эш ишетергә туры килә. Минем сүзем БДИ турында түгел, ә ата-аналарның, халкыбызның үз теленә, милләтенә мөнәсәбәте хакында. “Олы туганы”на бил бөгеп яшәргә өйрәнгән халкымның һаман да үзен түбәнсетүе, кимсетүе җанны өшетә. Үз телен, динен саклыйсы урында ул ана телен укытуга каршы булып чыга!? Я, уйлап карагыз: үз телен белү кемгә нинди зыян сала?! Киресенчә: ана телен белмәгән кеше башка телләрне дә бөтен нечкәлекләре белән өйрәнә, тулаем аңлый алмый, минемчә.

Татарстанда яши торган әрмән, әзербайҗан, үзбәк гаиләләренә карасаң шаккатмалы, алардагы үзаң, милли горурлык шулкадәр югары куелган ки, өйдә балалары белән һәрвакыт үз телләрендә сөйләшәләр, туган илләрендәге туганнарына атна саен хатлар яздырталар, шигырьләр-җырлар өйрәтәләр. Төрле юллар белән балаларын үз милли гореф-гадәтләрендә тәрбияләргә тырышалар. Шул ук вакытта аларның балалары татарчаны да, русчаны да әйбәт үзләштерә. Ә безнең халык балаларын туган теленнән биздереп русча укыту өчен җан тартыша, өендә дә вата-җимерә русча сөйләшеп газаплана.

Дөрес аңлагыз: мин рус телен яки башка телләрне өйрәнүгә каршы түгел. Телләр белү бирәүгә дә зыян итми, киресенчә, файдага гына. Тик туган телемә мөнәсәбәт, милләттәшләремнең үз ана теленә мөнәсәбәте җанны телә. Бер көн килеп, ана телебездә укырга китап, газета-журнал таба, татарча сөйләшергә кеше очрата алмасак, нишләрбез?!

Үзен, ата-анасын, илен, телен, халкын, аның үткәнен һәм киләчәген хөрмәт иткән һәркем туган телен белергә һәм аның чисталыгын сакларга тиеш.

**Әдәбият**

Тукай Г. Әсәрләр / төзүчеләр һәм редакторлар: Гали Халит, Рашат Гайнанов, Рәис Даутов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 1 том. – 423 б.

## ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫ СӨЙЛӘШЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Нәгыймова Н., Яңа Чишмә р-ны, Шахмай урта гомуми белем мәктәбе, X сыйныф*

*Җит. – Гыйльманова К. К.*

Башка халыклардагы кебек үк татар халкының да сөйләмә теле ике төргә бүлеп өйрәнелә. Беренчесе – халык авыз иҗаты әсәрләре теле, мондагы тел тәртипкә салынган һәм төрле диалектлар өчен уртак булган, шулай ук милли язма әдәби тел нигезендә ята торган сөйләмә тел. Икенчесе – теге яки бу урынчылыктагы халыкның тәртипкә салынмаган көндәлек сөйләмә теле, монысын диалект дип атыйлар.

Әдәби тел нормалары милләт өчен гомуми булса, сөйләмә тел төрле урында төрлечәрәк була. Бер якның сөйләме икенче якныкына охшамый, алар бер-берсеннән төрле үзенчәлекләр белән аерылып торалар.

Телнең билгеле бер төбәктә генә таралган төрен диалект, җирле сөйләш дип атыйлар. Диалектларга бүлә башласаң – һәр авылның үз диалекты, хәтта бер авылның ике очында ике диалект булырга мөмкин, без аны да беләбез.Шушы төбәккә генә хас булган, гомумхалык теленә кермәгән сүзләрне диалекталь сүзләр дип әйтәләр.

Безнең Яңа Чишмә районы сөйләме Көнбатыш (мишәр) диалектына карый. Шуңа бәйле рәвештә, мин үзебезнең җирле сөйләмебезгә характерлы булган кайбер лексик-семантик үзенчәлекләргә тулырак тукталып китәм.

Яңа Чишмә районы Татарстанның Чистай, Чирмешән, Аксубай, Әлмәт районнары белән чиктәш. Районыбызда җиде татар авылы бар. Мин үзем Чертуш авылыннан. Районда көнбатыш мишәр диалектында сөйләшүче халык яши.

Көнбатыш мишәр диалектына караган сөйләшләр күп төрле. Мәсәлән, сергач сөйләше, темников сөйләше, кузнецк һәм хвалын сөйләше, ләмбрә сөйләше, мәләкәс сөйләше, чистай сөйләше һ.б.

Яңа Чишмә районы кешеләренең сөйләшләрен чистай сөйләшенә кертәләр. Революциягә кадәрге бүленеш буенча бу төбәк Чистай өязенә кергән, халыкта Чистай ягы, Чистай мишәрләре дигән тәкъбирләр билгеле. Менә шулардан чыгып, сөйләшнең исеме чистай сөйләше дип атала.

Үземнең күзәтүләремнән чыгып шуны әйтә алам: Яңа Чишмә төбәге мишәрләренең сөйләшләре Чистай сөйләменнән бераз булса да аерыла. Алай гына түгел, районгагы Акбүре, Зирекле, Тубылгы Тау авылларының сөйләме безнең Чертуш авылы сөйләменнән аерыла. Нәкъ безнең авыл сөйләшенең үзенчәлекләре мондый. Сузык авазлар кулланылышы ягыннан:

- фонетик яктан иренләшкән[*а*]авазы юк, (да,бала, ана һ.б.)
- ү сузыгы алгырак позициядә һәм таррак әйтелә; (үсмер, күркә)
- Сөйләштә кайбер сүзләрдә әдәби телдәге ***и*** авазы урынына киң әйтелешле ***ә*** авазы кулланыла (ипи-әпәй, ким-кәм, миләш-мәләш һ.б.)
- ***0-Ө*** авазларын иренсезләштерү күзәтелә (дөрес-дерес, көтү-кетү һ.б.)
- Әдәби телдәге ***у*** авазын ***о/ы*** авазы белән алмаштырып әйтү (усак-ысак)
- ***Ө,э(е),ү***–алмаштыру (күңел-кеңел, бүген-беген-бөген һ.б.)
- дифтонгларны монофтонглаштыру( сүләү, әдә, ү, бәрәм)
- Рус алынмаларында басымлы иҗектәге ***о*** авазы сөйләштә ***у*** сузыгы белән , ***о*** авазы ***а*** авазы белән алмашына (окоп-акуп, погон-пагун, колхоз-калхуз)
- ***һ*** авазын ***х*** авазы кебек әйтү, ***х*** авазыннан соң нечкә сузык урынына калын сузык әйтү; (Халим, Хамидә, Хатимә һ.б.)
- Кирәкмәгән аваз өстәлү ( төр-этер, этереп бир, мәк-макы, тап-тапы, -врач-ырач, значок-ызначук, стакан-ыстакан, клуб-кылуп, пункт-пункыт һ.б.)

Тартык авазлар ягыннан:

- сөйләмдә увуляр ***[къ][гъ]*** авазы бөтенләй кулланылмый;
- өрелмәле ***[ч]*** авазы юк; (чыпчык-цыпцык, мәче-мацы, чабата-цабата. *Цәтрән күперен цыккан цакта цабатамның башы царт итте;Цәцәкле цәйнектән цыпыр-цыпыр цәй эцәм-* нәкъ безнең сөйләшкә карыйлар да инде)
- билгеле бер төркем сүзләрдә әдәби телдәге тел очы ***н*** урынына ирен-ирен ***м*** авазы яки киресенчә ***м*** урынына ***н*** авазы әйтелә (үлән-үләм, мөгез-негез һ.б.)
- ***й-ләштерү*** күзәтелә (җырлый-йырлый, җимеш-йемеш, җитеш-йитеш һ.б)
- составында саңгырау тартык булган сүзләрнең башындагы яңгырау ***б*** авазы саңгыраулаша (бет-пет, бот-пыт, ботак-пытак һ.б.)
- әдәби телдәге ***х*** урынына ***к*** авазын әйтү (хаста-каста-касталанган)
- ***м,н,ң*** борын авазларыннан соң килгән л тартыгы тел очы н авазына күчә (бөтенләй-бетеннәй, наданлык-наданнык, унлап-уннап һ.б.)
- кайбер авазлар төшеп калу ( илт-ит, белән-белә, аның белә бара,)

- янәшә тартыкларның урыннары алмашыну (азбар-абзар, бүрек-бүрке, һ.б.)

- ***Әйе*** сүзе урынына һәрвакыт рус телендәге ***да*** сүзе кулланыла

Сөйләмебезгә морфологик яктан игътибар итсәк, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Мәсәлән:

- кеше исемнәренә ук-үк кушымчалары ялгана (Нурулла – Нурук, Габдулла – Габдук, Әсәдулла – Әсук һ.б.);

- күрсәтү алмашлыклары үзгәртеп әйтелә (әнә – аня, тәнә, тәнәгенәк);

- сорау алмашлыклары әйтелешендә үзгәрешләр күзәтелә (кайсы – касе, нәрсә – нәстә, кайчан – качан, кайцан);

- рәвеш сүз төркемнәре әйтелешендәге үзенчәлекләр (шуңа кадәр – шыңганчы, икенче елга – иякенгә, аңарчы – аңгинча, кичә – тенә, тиз – йәт – друг, көчкә – насила, насила килеп җиттем, һаман – буйлый, бертуктаусыз – бербуйдан);

- теләк белдерә торган фигыльләр безнең якта ***–к,-ке,-ге + кели*** формасы белән ясала (ашак кели, эцке кели, унак кели һ.б.);

- йөкләтү юнәлеше кушымчасы ***–кыр-кер, -гыр-гер*** урынына ***–гыз,-гез*** кушымчаларын өстәү (кигез, йаткыз, менгез һ.б.);

- хәл фигыльнең ***ганчы-гәнче*** кушымчалары урынына ***–гынца,- гинцә-гинцы*** кушымчалары ялгана. (Барганцы, киткинце, алгыйнцы һ.б).

Болардан тыш бары безнең Яңа Чишмә төбәгенә караган гына сүзләр дә бар. Мәсәлән: тәнә – әнә, зәнәтуй – берьеллык печән, зәмәт – койма; нүеш – почмак, чашкыасты – чәй тәлинкәсе, палауник – аш чүмече, палавик – идән паласы, кистек – киез итек, кәкәш – бәрәңге бөккәне, кыстырган – пирог, күмәч, курляк – кура җиләге, эләккә бару – җиләккә бару, укурат – төп-төгәл, (чаклы мәгънәсендә), пицарасы – мич арасы, ызба – өй, аня – әнә, матик – китмән, митла – себерке, тирмән – тегермән, бәли – бияләй, клагарка – алка, читәй – яртының – яртысы, мәче – мацы, кычыткан – кецеркән, кайчы – качы, мунча – мунца, пизбашы – мич башы, әрекмән – әпертмән, тигәнә – улак, крича – өй алды, ызба башы – түбә чорма, паетбашы – печән куя торган урын, аймут – өскерт, путлы – әйбәт, ятрәк – кызурак, кучат – әтәч, билдәмә – пута, дустыган – чүмеч, кырмавык – тигәнәк,

Сөйләгәндә татар телендәге бәрәңге утыртабыз урынына бәрәңге чәчәбез, өстәлне себерәбез, пычракта итек киябез, авызыңны сөрт түгел, ә себер дип сөйләшәбез. (Татарларда итек ул киез итек мәгънәсендә кышкы кием буларак билгеле, ә мишәрләрдә бутый урынына итек дип сөйләшәләр).

Болардан тыш тагын сөйләгәндә без сөйләмебезне сузып, башкалар әйткәнчә, "җырлап” бетерәбез. Әгәр дә урта диалект вәкилләре булган

аудиториядә мишәр телле кеше чыгыш ясаса, аны аваз үзенчәлекләреннән генә түгел, ә интонациясеннән чыгып та танып була. Шуңа күрә безнең укытучы апабыз дәресләрдә аваз, сүзнең әйтелеш үзенчәлегенә генә игътибар итеп калмыйча, интонациябезгә дә игътибар итә. Дәресләрдә, җәмәгать урыннарында, сәхнәдә, җыелышларда матур әдәби телдә сөйләшергә өйрәтә.

Мин боларны үземнең күзәтүләремннән чыгып кына яздым. Фонетик, морфологик, синтаксик үзенчәлекләрне тагын да "төбенә төшеп" карасаң мондый үзенчәлекләрне безнең төбәк сөйләшеннән тагын да күбрәк табарга мөмкин. Киләчәктә дә бу өлкәдә эшләргә тырышырмын дип уйлыйм, чөнки мин татар теленә, үземнең туган җирле сөйләмемә битараф түгел. Җирле сөйләм ул – туган телне чүпләүче түгел, ә аны тагын да баетучы сөйләм.

**Әдәбият**

Баязитова Ф.С., Рамазанова Д.Б., Хәйретдинова Т.Х. Татар халык сөйләшләре. – Казан: Мәгариф, 2008. – 461 б.

## Ә.БАЯНОВНЫҢ "ТАУ ЯГЫ ПОВЕСТЕ"НЕҢ ЛИРИК-ЭМОЦИОНАЛЬ КАТЛАМЫ

*Отаева Г., Казан ш., ГБМБУ "144нче мәктәп", X сыйныф*

*Җит. – Ганиева Г.Г.; Габдуллина Р.А.*

Ә.Баянов иҗаты татар әдәбиятында шактый үзенчәлекле һәм югары урыннарның берсен алып тора. Ә.Баянов – иң әүвәл шигъри әсәрләре белән танылган әдип. Шигырьләре район газетасында 1943 елдан, республика матбугатында 1951 елдан басыла башлый, беренче җыентыгы («Диңгез шавы») Татарстан китап нәшриятында 1959 елда чыга. Ә.Баянов – шигъри әсәрләре тупланган дистәдән артык китап авторы. Аның күп санлы лирик һәм фәлсәфи-публицистик шигырьләре, балладалары һәм «Яшел мәйдан» (1957), «Диңгез шавы» (1958), «Мират» (1959), «Сез аңларсыз мине» (1963), «Сәяхәтнамә» (1969), «Кышкы чәчәкләр» (1974) кебек поэмалары егерменче гасырның икенче яртысындагы татар поэзиясе хәзинәсендә лаеклы урын алып торалар. эшебезнең актуальлеге түбәндәгеләр белән билгеләнә: Ә.Баянов әсәрләрендәге лирик-эмоциональ башлангычны өйрәнү омтылышы; Ә.Баянов иҗатына соңгы елларда игътибар киму; Әдәбият белемендә әдипнең әсәрләрендә лирик-эмоциональ башлангычны өйрәнүгә багышланган махсус хезмәтләр булмау, максаты – Ә.Баяновның "Тау ягы повесте" әсәрендә лирик-эмоциональ башлангычның үзенчәлекләрен билгеләү, тикшерү объекты – Ә.Баяновның "Тау ягы" повесте. Тикшерү предметы итеп югарыдагы әсәрнең лирик-эмоциональ композицион катламы алынды. Лирик-эмоциональ башлангыч, бер яктан, әсәр тукымасында субъектив

Все вышеперечисленные играют важную роль, чтобы понять зависимость развития языка от развития общества. Эти два понятия крепко связаны между собой, и существовать автономно они не смогут. Поэтому необходимо понимать, что любые изменения, которые происходят в обществе, обязательно отразятся и на языке, и язык, в свою очередь, тоже способен влиять на общество. Язык – это явление общественное, и пока будет существовать общество, будет существовать и язык, потому что эти два понятия неразделимы.

**Литература**

1. Звегинцев В.А. Теоретические аспекты причинности языковых изменений // Новое в лингвистике. Вып. 3. – М.: Издательство иностранной литературы, 1963. – С. 125–143.

2. Соссюр Ф. Курс общей лингвистики. – М.: Книжный дом “Либроком”, 2012. – 256 с.

## ИСКУССТВЕННЫЙ ЯЗЫК НАУКИ – ХИМИЯ

*Тарівердиев Д., г. Набережные Челны, МБОУ “СОШ №24”*
*Рук. – Якупова Г.Р.*

Испокон веков знания передавались с помощью языка. Для выражения научных познаний применяются натуральные и искусственного происхождения языки науки. К ним относится и химический язык, имеющий в собственном составе химическую терминологию, номенклатуру и символику. В отличие от языка хим. науки, школьный химический язык больше адаптирован к целям изучения. Без него исследование почв химии было бы достаточно затрудненным. Он обширно и деятельно применяется на всех шагах изучения предмета. С поддержкой языка передаются и усваиваются мнения, осваиваются различные методы познавательной работы, нужные для воплощения учения.

Основные понятия, термины, номенклатура, формулы – все это основные составляющие языка химии. Он как и все имеет свой алфавит, грамматику и синтаксис. Ведь запись химических формул и уравнений, тоже являются своеобразными предложениями, в которых в роли букв выступают символы химических элементов. Благодаря ему мы имеем возможность не только именовать вещества, но и проводить над ними арифметические операции, но лишь относительно химических формул и уравнений. В химии так же присутствует достаточное количество терминов которые имеют свои тематические группы (свойство, хим. процесс, вещество, материал и т.д.), а в связках могут образовывать систему логических связей. Так же очень интересным морфологической составляющей этого языка, я считаю суффиксы и префиксы, ведь каждый из них несет в себе информацию, принадлежность к какой либо группе, а так же свойства.

Что касается истории, сама химия берет свое начало еще в древности, когда люди учились разводить огонь, готовить лекарства из трав, варили еду. Но основными прародителями данной науки, все же считают египтян и греков ведь именно они во втором тысячелетии до нашей эры обладали знаниями в этой области, которое в последствии привело к созревании такой науки как алхимия. В 600 г. до н.э. появились первые философские представления о материи. Позже, впервые столетия нашей эры начали появляться ассоциации металлов с небесными телами. Так же известно, что в греческих рукописях имеется список, в котором есть обозначения металлов и символы некоторых химикатов

В России же становление языка химии происходило с помощью лексических способностей русского языка, так и за счет

заимствования. Так первородный Гидрогениум в России стал Водородом, Оксиген – Кислородом, а Карбо – Углеродом. Выработка русского научного языка не могла произойти сразу, ведь требовалось время на создание принципов его формирования, именно от этого происходили активные процессы заимствования, а так же поиском более подходящих слов.

*«Когда оныя иностранныя слова были в России с начала приняты, то сие было наипаче от иностранных учителей; и нужда нам тогда надлежала вещей паче, нежели слов»* – говорил переводчик В.Н. Никитин, объясняя причины активного заимствования иностранных слов. Так же не малую часть в формирование внес и М.В. Ломоносов своими трудами под названием «Первые основания металлургии, или рудных дел».

Химический язык вносит немаловажную лепту в реализацию развивающей функции изучения. Тем более велика его роль в развитии мышления студентов и формировании их творческой работы, например как все операции с этим языком считаются интеллектуальными. Более нередко при оперировании им применяются сопоставление, абстрагирование и иные мыслительные операции

Химический язык так же вносит важный вклад в реализацию воспитательной функции обучения. Он может использоваться как активное средство формирования научного мировоззрения учащихся, поскольку позволяет раскрыть многие мировоззренческие вопросы. Например, символически выраженная периодическая система химических элементов Д.И. Менделеева используется для подтверждения законов диалектики

Он представлен, прежде всего, знаками – заменителями предмета или явления, используемыми для приема или передачи информации об этом предмете или явлении. Знак, по сути, является вторичным. Это овеществленный носитель образа предмета.

Основная масса химических определений образовано из греческих и латинских текстов. Материалистические представления о мироздании возымели более абсолютное выражение в учениях древних философов Греции. Их учения явились плодом исследования, обдумывания различных явлений и стремления предоставить сплошное комментарий обилию вещей. Естественнонаучный материализм античных греков послужил почвой для появления научных доктрин и учений. Это сказалось и на языке науки.

Свой вклад в развитие языка внесли не только современные ученые, но и деятели древности, в частности и Аристотель который начал использовать латиницу в качестве химических терминов, антибиотики,

антифризы, антисептики, в которых фрагмент «анти» в переводе с греческого означает «противоположный». «Крио» по-гречески означает лёд, холод. Отсюда: криолит – холодный камень (внешне похож на лёд); кристаллы – лёд, горный хрусталь. «Гидро», означающее влажность, и слово «гидро», означающее воду, входят фрагментами в современные слова: гигроскопичность (влажность + наблюдение); гидрофобность (вода + боязнь) и др. Другой пример. Термин азеотропный состоит из трех частей: «а» (отрицание), «зео» (кипение), «троп» (изменение). Этот термин характеризует смеси веществ, которые кипят при постоянной температуре без изменения состава.

Латинский язык до XVIII в. был интернациональным языком науки, в следствие этого оставил большущий отпечаток в определениях. Определения, интеллектуальные от латинских текстов, почаще всего значат какую-нибудь технологическую операцию, воздействие. К примеру: адсорбция – поглощение; связь – соединение; диссоциация – разъединение; диффузия – распространение; нейтрализация – ни тот, ни иной (реакция взаимодействия кислоты с базой, при которой ни кислоты, ни причины не остается).свежей для появления научных доктрин и учений.

Итак, язык химии содержит большой смысл в обучении химии, выполняя различные функции. С его поддержкой передаются и приобретаются познания, складываются и развиваются важные мнения. Он принимает участие в знании определенных препаратов и реакций, в описании итогов знания. С поддержкой символики в школьных учебниках и учебных пособиях проявлены различные мнения и абстрактные возведения, отражающие закономерности состава, строения и качеств препаратов и их взаимодействий. Велик смысл хим. языка в повторении, совершенствовании и проверке познаний, умений и способностей, в интенсивном использовании, применении их на практике. Все это разрешает считать хим. язык важным средством и способом изучения химии. В случае если при исследовании языка закрадывается оплошность, то неизбежно в последующем отблеск реальности проявляется в искаженном виде.

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЗООНИМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*Төхвәтуллина А., Казан ш., ГБМБУ “144нче мәктәп”, X сыйныф*
*Җит. – Җиһангәрәева Л.Һ.; Төхвәтуллина Л.Р.*

Әдәбият образлы фикерләү дөньясы. Шагыйрь, прозаик яки драматург никадәр образлы фикер йөртсә, ул тудырган әдәби әсәр укучы яки тынлаучы күңеленә шулкадәр ныграк тәэсир итә, камилрәк һәм матуррак тоела. Поэзиянең кешеләргә уй-тойгы тудыру өчен

хезмәт итүен искә алган хәлдә, теге яки бу шагыйрьнең, шагыйрәнең образлы сүрәтләүгә омтылуын аңлату кыен түгел [4: 12]. Бу максатка ирешү барышында сүз остасы аеруча поэтик шагыйрь жанрында телнең лексик сурәтләү чаралары аша сүзләрне күчерелмә мәгънә аша куллана, сурәтләүдәге аерым күренешләргә, предметларга фәлсәфи мәгънә сала. Әдәбият белемендә исә, әлеге төшенчә поэтика дип атала, ягъни әдәби әсәр структурасын, әсәрнең оешу алымнарын, чараларын, рәвешләрен өйрәтә торган өлкәсе. Шигърият, шигъри сүз – илаһи төшенчә. Шуңа күрәдер шигъриятгәге образ, фикерләүләр табигать дөньясы аша, сихри күренешләр аша күзаллана. Шигъриятгә хайван атамаларын куллану зур кызыксыну уята. Безнең фәнни эшебезнең темасы да “Хәзерге шигъриятгә зоонимнарның кулланылышы” дип билгеләнә. Хезмәтнең максаты – хәзерге шигъриятгә зоонимнарның кулланылыш үзенчәлекләрен билгеләү.Әлеге максатка ирешү юлында түбәндәге бурычларны чишәргә кирәк дип табылды:зооним төшенчәсенә ачыклык кертү; поэтик ономастика хакында мәгълүмат бирү; хәзерге шигъриятгән зоонимнарны барлау; хайван атамаларының поэтик вазифаларын ачыклау. Безнең тикшеренү объекты итеп хәзерге татар шигъриятендә актив иҗат итүче мәшһүр авторлар – Р.Аймәт һәм Ф.Җамалетдинова шигырьләре алынды. Тикшерү предметы – шигъриятгә кулланылган зоонимнар.

Зоонимика хайван атамаларын тикшерә. Зоонимнар тел белеменең ономастика тармагында өйрәнелә Тел белемендә зооним төшенчәсе берничә мәгънәдә кулланыла: 1) хайваннарның кушаматлары; 2) хайваннарның уртак исемнәре, ягъни күбәләк, ат, керпе кебек төр атамалары; 3) фаунага караган барлык терминнар. Поэтик ономастика бүгенге татар тел белемендә актив өйрәнелә торган тармакларның берсе булып тора. Әдәби әсәр тукымасындагы ономастик берәмлекләрне, шул исәптән зоонимнарны, халыкның, язучының дөньяга карашы, менталь сыйфатлары, психологиясенә бәйле өйрәнү – бик актуаль һәм шул ук вакытта кызыклы мәсьәләләрнең берсе булып тора. поэтик ономастика гаять кызыклы өлкә. Ул әдәби әсәрләрдәге барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә. Аларны язучылар төрле максатлардан кулланалар. Кеше исемнәре, географик объект атамалары әсәрнең идея-тематикасын ачуда, сюжет-композициясен коруда, сәнгатьчә матурлыгын булдыруда зур роль уйныйлар. Хәзерге шигъриятгә зоонимнар кулланылышы да зур кызыксыну уята. Барлык шагыйрьләр дә иҗат процесында төрле поэтик алымнар кулланалар. Поэтик әсәр нигезендә образлылык ята. Сүздән сурәт ясаудагы образлылык – беренчел образлылык.

Зөлфәт әйтүенчә: “Шигырь язу өчен күңелнең мөлдерәп торуы, соңгы тамчысының ташуы кирәк. Шигырь – язмыш” [3: 8]. Әнә шул ташу, мөлдерәүдә табигать әнкәнең кайсы балалары (бу очракта хайваннар дөньясы) җан халәтенең нинди мизгелләрен чагылдаруын шагыйрьләребез иҗатында барлап карыйк.

Рәмис Аймәт үзенең шигырьләрендә хайваннар дөньясына, кошлар иленә еш мөрәҗәгать итә. Р.Аймәтнең “Ярты юлда” шигырендә аккош һәм бүре зоонимнары кулланыла. Бүре зоонимы ач метафорасы белән берлектә бирелә һәм куркынычлык, ерткычлык төшенчәсен аңлата. Р.Аймәт шигыръләрендә эт зоонимы актив. Автор аларны төрле метафоралар белән берлектә тәкъдим итә. Мәсәлән, “Шигырьгә кайту” шигырендә. *Р.Аймәтнең “Уяну” шигырендә дә эт зоонимы очрый. Бирегә үзәккә эт улау күренеше куела.* Әлеге шигырьдә шигырь һәм эт, эт улау һәм шагыйрьнең уйлары төшенчәләре янәшә тәкъдим ителә. Эт зоонимы сукбай, *йортсыз калган ерткыч* метафоралары белән сурәтләнә. Эт улау күренеше белән бәйле юрауларны татар халык ышануларында да очратырга мөмкин.

Эт зоонимын фәнни эшебезнең тикшерү объекты итеп алынган Ф.Җамалетдинова шигырьләрендә дә очратабыз. Мәсәлән, “Туган ягымда” шигыре. Р.Аймәт шигырьләрендә эт образы корткычлык, ерткычлык һәм сукбайлык төшенчәләре белән бәйле булса, Р.Җамалетдинова өчен этләр -яшьлек, бала чак, туган як билгесе. Ат – бар татар әдәбиятын, татар тормышын иңләгән хайваннарның берсе. Ат образы ярдәмендә җырларда кешенең кайгы-хәсрәте белдерелә, узган гомере, киләчәге турында уйлану чагыла. Без ат зоонимын Ф.Җамалетдинова шигъриятендә дә очратабыз.( (“Карлар ята нарат түбәсендә...”). Борынгы һәм урта гасыр әдәбияттан килгән, халык җырларында актив кулланылган күбәләк образы да хәзерге шигърияттә еш очрый. Мәсәлән, Ф.Җамалетдинованың “Ничә яшь дип сорамагыз миннән...” шигырендә. Татар халкының ышануларына, юрауга бәйле күренешләрне Ф.Җамалетдинова шигырьләреннән дә табарга мөмкин. Бу очракта да төп юрау предметы булып зоонимнар тора. Мәсәлән “Исән чакта” шигырендә мәче зоонимы “кара мәче юлны киссә, юл уңмый” дигән ышануны аңлата һәм лирик геройның күңел халәтен тулырак, төгәлрәк чагылдыру максатыннан кулланыла. Ф.Җамалетдинова шигырьләрендә елан зоонимы да килеп керә. Автор гомер узышын, үткән елларны еланнарга охшата. Бирегә, безнең карашка, беренче чиратта, аваз охшашлыгы зур роль уйный *(“Еллар-еланнар”).*

Шул рәвешле, хәзерге татар шигъриятендә хайван атамаларыннан – ат, эт, бүре, ә кош исемнәреннән былбыл, күбәләк, аккош, акчарлак

актив кулланыла. Эт һәм бүре зоонимнары хәзерге чорны, яшәешне чагылдыру өчен файдаланыла. Лирик геройның күңел кичерешләре исә татар халкының борынгы традицияләренә охшашлыкта аккош, акчарлак, күбәләк һ.б. зоонимнар белән аңлатыла.

**Әдәбият**


1. Аймәт Р.К. Шомырт салкыннары: шигырьләр. – Казан: Мәгариф, 2000. – 110 б.
2. Җамалетдинова Ф. Толымлы ай: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 174 б.
3.Зөлфәт. Йөрәгемне былбыл чакты. – Казан: Рухият., 1999. – 415 б.
4. Саттаров Г. Ф. Ни өчен шулай аталган? – Казан: Татар.кит. нәшр., 1971. – 128 б.
5. Юзеев Н. Хәзерге татар поэтикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 351 б.


## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ АШЛАРЫ


*Узум С., Бөгелмә р-ны, Мостафа Өнҗәл ис. лицей-интернат, X сыйныф*

*Җит. – Юнысова С.Г.*


Мин, Бөгелмә шәһәрендә Мостафа Өнҗәл исемендәге лицей-интернатта укыйм, катнаш гаиләдә тәрбияләнәм. Минем әнием – татар, әтием – милләте буенча төрек. Бу эшемдә мин татар һәм төрек халыкларының милли ризыклары турында язып үтәсем килә. Ял көннәрендә мин әнием белән татар һәм төрек халыкларының телеңне йотарлык тәмле ризыкларын пешерәбез, әнием миңа ризык әзерләүдә үзе генә белгән серләрен өйрәтә, киңәшләрен бирә.

Татар халкынына милли традицияләргә бай ашлар әзерләү осталыгы бик күптәннән килә. Күп гасырларга сузылган тарих дәвамында милли оригиналь ашлар барлыкка килгән, алар үзләренә генә хас сыйфатларны әлегә кадәр саклаганнар. Аларның үзенчәлеге халык тормышының иҗтимагый, икътисадый, табигый шартларына, аның этник тарихына бәйле. Ләкин татар халкының милли ашлары үз этник традицияләре нигезендә генә үсмәгән, аңа күрше халыкларның – руслар, мари, удмурт һ.б., шулай ук Урта Азия халыкларының, аеруча үзбәк һәм таджикларның ашлары йогынты ясаган. Башка халыкларга хас ашларны әзерләү, азыкларның төрләрен ишәйтү татар ашларының төп этник үзенчәлекләрен үзгәртмәгән.

Бәлеш – милли татар ашы, ул бәйрәм табынының төп бизәге. Шулпалы бәлешне гадәттә төче камырдан ясыйлар, ачы камырдан шулпасы агарга мөмкин. Әзер бәлеш өчен табага җәйгән камырга ит-бәрәңгене өеп салалар да, камырның кырыен күтәреп, бөрәләр. Шуннан соң капкач өчен калдырган камырны җәеп, бәлеш өстенә тишек тишеп, камырдан бөке ясап куялар. Бәлешне ясап бетергәч, өстен майлап мичкә яки духовкага куялар. 1-1,5 сәгатьтән соң бәлешне мичтән алалар, бөкесен ачып, алдан әзерләгән ит шулпасы салалар, аннары бөкесен ябып, яңадан мичкә тыгалар. 30-40 минуттан бәлеш

әзер була. Әзер зур бәлешне ашауның үз тәртибе бар: башта, түгәрәкләп, аның капкачын кисеп алалар, аны, кунак санынча өлешләргә бүлеп, бәлеш эче белән табынга чыгаралар. Ә аннары, бәлешнең төбен бүлеп, һәр кунак алдына тәмле шулпа тәме сеңгән камыр кисәкләрен куялар.

Татар халкы бик борынгыдан ук аш-су әзерләргә оста булган, тәмле ашлар пешергән. Халкыбызның күп еллардан бирле сакланып, безнең көннәрдә дә яратып ашала торган ризыкларының берсе, татар халык ашларының алтын хәзинәсе – чәкчәк. Чәкчәк – татар халкының милли ризыгы, табын күрке. Туйларны, төрле бәйрәмнәрне аннан башка күз алдына да китереп булмый. Чәкчәкне кияү йортына кәләш һәм аның эти-әниләре алып килә. Юка гына җиләк-җимеш кагына төргән чәкчәк туйда аеруча хөрмәтле сыйлардан санала. Чәкчәкне ашавы да бик рәхәт бит! Чәкчәк өстенә чәчәк тә куярга була. Чәкчәкне шоколад, чикләвек һәм кунжут һәм тагын бик күп тәмләткечләр белән ясыйлар. Тарихи чыганакларга күз салсак, татар халкы элек-электән умартачылык белән шөгыльләнгән. Балдан менә шундый татлы чәй ризыгы уйлап тапкан. Аны бары тик кунак килгән вакытларда гына пешерә торган булганнар. Аеруча туй өстәлендә бик популяр булган. Бүген әлеге татлы ризыкны кибетләрдән дә сатып алырга була. Күп кенә икмәк пешерү заводлары аны җитештерү бенча махсуслашып, килгән кунаклар өчен сувенир кебек итеп тә пешерә башладылар. Чәкчәкне татар халкының визит карточкасы дияргә була. Татарларда кунакларны чәкчәк белән каршылау гадәткә кергән. Кунакка барганда һәркем күчтәнәчкә чәкчәк ала. Россиянең башка шәһәрләрендә, чит илләрдә яшәүче татарлар гына түгел, башка милләт кешеләре дә әлеге ризыкны үз итә, ярата. Чәкчәкне берничә төрле итеп пешерәләр. Һәр төбәкнең үз чәкчәге бар. Кайбер якларда аны токмач кебек кисеп пешерсәләр, чикләвек кебек түгәрәкләп ясаучылар да юк түгел. Көньяк-көнчыгыш төбәгендә исә бавырсак кебек ясыйлар. Аны пешерү гадәти чәкчәктән аерыла.

Çorba bir çok türlüdür.Mercimeklisi de var,domateslisi de. Çorba çoğunlukla sıcak servis edilir. Türkiye'de tatil yaparken, kesinlikle bu Türk çorbasını denemelisiniz, çünkü şimdiye kadar tattığınız tüm yemekler arasında benzersizdir. Çorba, Türk restoranlarındaki en ünlü yemeklerinden biridir ve çoğu restoranlar menülerine dahil etmiştir.

Börek başka bir geleneksel Türk yemeğidir. Büyük miktarlarda hazırlanan ve hazır olduğunda küçük porsiyonlarla servis yapılır. Börek iç malzemesi ile birlikte hazırlanır. Börek, ince yufkalardan hazırlanır. Daha sonra peynir, patates veya ıspanakla doldurulur.

Gözleme-doldurulmuş krep gibi bir şey. Elle karıştırılmış hamurdan hazırlanır ve daha sonra yağ ile yağlanır. Daha da lezzetli hale getirmek için

kendi malzemelerinizle doldurabilirsiniz. Çoğu zaman peynir, patates, yeşillik, patlıcan veya diğer malzemeler kullanılır. Türkiye'ye gelirseniz ve Gözleme'yi denemezseniz, en iyi Türk geleneksel yemeklerinden birini kaçırırsınız. Belki de bu ülkeyi ziyaret eden ve bu lezzetli yemeği denemeyen tek kişinin siz olduğunuzu öğrenmenize şaşıracaksınız.

Türkiye'de genellikle doğranmış etle doldurulmuş sarmaşıkların bükülmüş yaprakları olan geleneksel bir yemektir. Üzüm yapraklarının doldurulması ve bükülmesi biraz zaman alır, ancak sonunda birkaç gün içinde yiyebileceğiniz büyük miktarda sarma elde edersiniz.

Hiç tatlı ve aynı zamanda tuzlu yoğurt denediniz mi? Eğer değilse, mutlaka ayran'ı deneyin. Ne zaman yemek sipariş edersem, her zaman yanında bir ayran vardır. Ve eğer bu içeceği ilk kez denerseniz, biraz garip gelebilir, ancak birkaç gün içinde kesinlikle bu içeceğin hayranı olacaksınız.

Татар халкының яраткан эчемлеге – чәй. Камыр азыклары – кабартма, коймак белән чәй кайчагында иртәнге ашны алыштыра. Чәйне каты итеп, кайнар көе, кайчагында сөт белән эчәләр. Чәй белән сыйлау татар халкында кунакчыллыкның бер билгесе булып тора. Өйгә кем генә кермәсен, барысын да чәй белән сыйлап чыгаралар. Чәй тиз арада популярлык казана. Чәйдән башка бер генә милли бәйрәмне дә күз алдына китереп булмый. Чәйне каты итеп пешергәннәр һәм ул һәрвакыт самовар өстендә торган. Татар чәе турында бик күп атаклы шәхесләр искә алган. Мәсәлән, тарихчы Н.Воробьев: “Татарларда иң киң таралган эчемлек – чәй. Алар аны бик еш һәм бик озак итеп эчәләр”, – дип яза. Ә К.Фукс исә, “Татарлар чәй эчәргә ярата. Аны бал белән кимендә 4 чынаяк эчәргә кирәк”, – дип искә алган.

## КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛЫНДАГЫ КУШАМАТЛАР

*Фәйзрахманова Д., Казан ш., 177 лицей, X сыйныф*
*Җит. – Воробьева Л.Н., Хәмитова Р.Р.*

Һәр авылның үз гореф-гадәтләре, үз фольклоры һәм һәр нәселгә яки аерым кешеләргә хас кушаматлары бар.

Борынгы заманда кушаматлар фамилия функциясен башкарган, ягъни кеше исеменә өстәлеп, шәхесне тагын да конкретлаштырган. Авыл җирендә һәр кешенең диярлек кушаматы бар. Бу бик үк әдәпле гамәл булмаса да, кайчакта файдасы тия. Бигрәк тә авылда бер үк исемдәге кешеләр күп булганда.

Лаеш районы Кече Елга авылында кушаматсыз гына яшәүчеләр сирәктер. Кушамат – тигәнәк кебек килә дә ябыша, хәтта фани дөнья белән тәмам хушлашканчы тагылып йөри. Кушаматтан мәңге котылам димә. Үпкәлә, гарьлән, кимсен-башкаларның анда эше юк. Кушаматлар сиңа гына түгел, нәсел-ыруыңа да ябышып кала.

Авыл халкы кечкенә генә җирлектә яшәсә дә, анда көн күрүче кешеләрнең үзенә генә хас, берсеннән-берсе кызыклы кушаматлары бар. Алар кушаматларга шулкадәр күнеккән, алар өчен бу гадәти, табигый күренеш. Кушаматлар нигездә, тышкы кыяфәт, холык-фигыль буенча кушыла.

Кече Елга авылындагы кушаматларны барлап, аларны түбәндәге төркемнәргә бүлдек:

1. Фамилиягә нигезләнгән кушаматлар: Әкбәров – Әкбәр Ильясы, Мулюков – Мөлек Рәисе, Хәзиев – Хаҗи, Вәлиуллин – Вәлкә, Зарипов – Зариф, Шәвәлиев – Шәвәли, Кашапов – Кашаф, Гатауллин – Гата, Муксинов – Мөхсин, Сиразиев – Сираҗи, Нәбиуллин – Нәби, Низамов – Низами, Каюмов – Каюм, Яруллин – Ярый, Закиров – Закир, Зарипов – Зарипыч.

2. Кеше исемнәреннән ясалган кушаматлар: Ахунҗан – Ахуныч, Миңлекәй – Михәй, Вәли – Вәлүш, Шәмси – Чәмеш, Шахиҗихан – Шахи, Саимә – Саимыч, Сәлмән – Сәлмәнеч, Бәдретдин – Бәдри, Гәбделхәй – Тукай. Әлеге төркемнәрдән тыш, исем, фамилия, атасының исемен кыскартып ясалган кушамат: БАХ (Батталов Азат Хәйдәр улы).

3. Кешенен тышкы кыяфәте яки холкыннан чыгып бирелгән кушаматлар: Озынборын Миңнуласы, Ашыгыч Галимҗаны, Пырмаз Миңнуласы, Сызгыравыч Габделхәе, Кылчык Хәбире, Тупый Миңнуласы, Кысыр Кәрим, Чарли Илназы, Кара Гали, Кытай Әнисәсе, Чыр-Чык Наиләсе, Тар-Тар Зәкиясе, Алдар Зәйнәбе, Чаян Таһиры, Айнымас Нәҗибе, Әкрен Зиннәт, Кәтүк Рифкате, Акбаш Ризваны, Тычтый Әхәте, Полтора Бибисара, Булдырый Шамиле, Пружин Рифкате, Качкын Хәйдәре, Чаян Таһиры, Тупый Миннуласы.

4. Кош, балык, хайван һәм җәнлек исемнәрен кулланып бирелгән кушаматлар: Мәче Равиле, Куян Габдрафигы, Бүре Зиннәте, Бака Раузасы, Бак-Бак Мәдинәсе, Торна Гайнулласы, Дию Кәриме, Тавык Фоаты, Камбала Фәните, Саескан Әлфиясе, Грач Илгизе, Әпипә Миңнегалие, Поши Нурулласы, Чәүкә Мәгьшиясе, Чебеш Хәлимәсе.

5. Үсемлек исемнәренә таянып бирелгән кушаматлар: Әкәле Ахуны, Кукы Шамиле, Кузак Зиннәте.

6. Күченеп кайту яки яшәү урыны буенча кушаматлар: Казах Эльмирасы, Кубы Кыямы, Атау Әминәсе, Кашан Гөлсинәсе, Сахалин Раузасы.

7. Эш урынын исәптә тотып бирелгән кушаматлар: Мулла Габдулласы, Тимерче Гали, Лесник Равиле, Боцман Равиле, Кибетче Алсу, Токарь Мансуры.

8. Әлеге төркемнәрнең берсенә дә кагылмаган, бирелгән мәгънәсе аңлашылмаган кушаматлар: Әпри, Әлбә, Тырыс, Апуй, Кәчкә, Паджа, Кәли, Үпәй.

Авыл һәм шәһәр, борынгы һәм хәзерге заман кушаматлары арасындагы охшаш яки үзгә якларын билгеләү максатыннан, сораштыру уздырырга булдым. Әлеге чарада барлык X сыйныф укучылары катнашты. Сораштырудан чыгып түбәндәге нәтиҗәгә килдем: 120-гә якын укучының 40 %-ы кушаматка ия, ә авыл халкында бу күрсәткеч – 90%.

Әлеге кушаматлар авыл җирлегендәге һәм борынгы кушаматларга бөтенләй ошамаган диярлек. Алар арасында Ауф, Ботяра, Дезик, Хакин, Эмгыр, Герунди кебек мәгънәсе буенча бик үк аңлаешлы булмаганнары шактый.

Шунысын әйтеп үтәргә кирәк, исем, фамилиягә бәйле кушаматлар шактый: Ларионова – ларик, Медведев – медведь, Брюханова – Хрюханова, Сарян – Сархан, Ивойлов – Иволга. Тышкы кыяфәт яки холык буенча: Черный, Выскачка, Верный, Усатый.

Авыл яки шәһәр, яшь яки өлкән, бай яки ярлы булуларына карамастан, кушамат бирү күренеше беркемне дә читләтеп үтми.

Һәр авылның үткәне һәм киләчәге, матур гореф-гадәтләре, үзенә генә хас йолалары бар. Авылның исә үзенчәлекле, ләкин бик гади булган тырыш халкы бар. Һәр халыкның нәселдән-нәселгә ияреп килгән кызыклы, үзгә кушаматлары бар. Авыл халкы әлеге кушаматларга үпкәләми, чөнки ул аңа инде күнеккән, гадәти хәл буларак кабул итә. Әлеге кушаматлар кешене кыерсыту яки рәнҗетү максатыннан, усал ният белән бирелми. Кушаматлар кешеләрне бер-берсеннән аеру өчен кулланыла. Яшәсен авыл! Яшәсен кушаматлар! Алар бит безнең ата-бабаларыбыздан калган матур гадәт!

**Әдәбият**

1. Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан, I том. – Казан, 2001. – 26 б.
2. Кәримов Т. Гасырлар кичкән авыл. – Казан, 1999. – 192 б.
3. Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. – Казан, 1990. – 378 б.

## РУС ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА БӘХЕТСЕЗ НИКАХ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Хантимирова Р., Кукмара р-ны, К.Ф. Шакиров ис. Зур Сәрдек гимназиясе, XI сыйныф*

*Җит. – Шагабиева Й.Ә.*

Ата-бабаларыбыз элек-электән үк башка милләт вәкилләре белән дус-тату яшәгәннәр. Бу – илдә тынычлык хөкем сөрсен өчен кирәк булган. Алар бер-берсенең телен өйрәнгәннәр, бәйрәмнәренә йөрешкәннәр һәм, әлбәттә, башка милләтләрне хөрмәт иткәннәр. Бүгенге көндә дә без һәрдаим башка милләт вәкилләре белән аралашып

яшибез. Аларның гореф-гадәтләрен күзәтәбез, бәйрәмнәрендә катнашабыз. Илебезнең сәясәте дә безне һәрвакыт толерантлы булырга өнди. Әмма безнең татар халкы башка милләтләр никадәр дус, тату булырга тырышса да, бу дуслыкның чиге билгеләнгән. Ата-бабаларыбыз башка милләт кызлары белән бергә гаилә коруны, кан кушылуны бер дә өнәмәгәннәр. Кызганыч, бүгенге көндә күп кенә татар егетләре үзләренә гомерлек яр итеп башка милләт сылуларын сайлыйлар. Аларның шушы бер адымнары аркасында күп кенә гореф-гадәтләр, йолалар, иң мөһиме, ислам динендә, саф татарча сөйләшә торган балаларыбыз юкка чыга.

Катнаш никахлар сугыштан соңгы елларда бик активлашып китә, бүгенге көндә дә ул актуальлеген югалтмый. Танылган драматургыбыз Туфан Миңнуллин иҗатында әлеге проблема шактый кызыклы сурәтләнә. Ул милләтләр дуслыгы аша дин һәм тел мәсьәләсен генә күтәреп калмый, ә аннан соң булган фаҗигаләрне дә яктырта. Мәсәлән, “Илгизәр+Вера” драматик пьесасында бер авылда ике милләт – татар һәм руслар – яшәеше сурәтләнә. Татарлар да, руслар да бик дус яшиләр, бер-берсенең телләрен беләләр, бәйрәмнәрдә, хәтта туйларда да бергә бәйрәм итәләр. Көннәрдән бер көнне ике милләт яшьләре Илгизәр һәм Вера кавышырга булалар. Күп еллар дәвамында күршеләр булып яшәсәләр дә, бик яхшы мөнәсәбәттә булсалар да, яшьләрнең никахына ике як әти-әнисе дә каршы чыгалар. Чөнки элеккедән килгән йола буенча, ике дин әһеле кавышу – зур фаҗигагә китерәчәк Бу сүзләрне бигрәк тә ачынып-ачынып Нурхәмәт карт әйтә. Һәм чыннан да зур фаҗига килеп тә чыга. Иң беренче чиратта, рус килененнән туган бала шунда ук Иванга әйләнә. Яшь баланың муенына тәре асыла. Моны күргән татар әбисе хушын җуя. Нәтиҗәдә, ике буын арасындагы бәйләнеш, дини нормалар өзелә. Гомер-гомергә тыныч, матур яшәгән милләтләр дуслыгын кыз белән егетнең кушылуы җимерә. Моны укучыга аңлату өчен автор әсәрдә өянке символын кертә. Йөзьяшәр өянке нәкъ менә шушы милләт арасындагы дуслыкка нокта куйгач ава да инде. Өянкенең авуы күршеләр өчен зур җимерүләргә китерсә, авыл халкы өчен, гомумән, фаҗигагә әверелә. Димәк, автор, милләтләр үзара дус һәм тату яшәргә тиешләр, әмма аларның гаилә булып кушылулары, ике милләт өчен дә фаҗига булып тора дип белдерергә тели.

Шушындый ук мисалны Туфан Миңнуллинның “Төш” пьесасында да күрергә мөмкин. Әлеге пьесада ничә еллар буе күршедә аралашып яшәгән рус кызы Елена һәм татар егете Камил кавышалар. Камил шәһәрдә торганлыктан, гәрчә әбисе Фәүзия белән генә яшәсә дә, бик әйбәт рус телендә сөйләшә. Елена һәм әбисе Анна Егоровна шулай ук рус булуларына карамастан, саф татарча сөйләшәләр. Әлеге ике гаилә

гомер буе килешеп яшәгән күршеләр. Бер-берсе белән татар телендә сөйләшәләр, ике телне дә хөрмәт итәләр. Әмма Елена белән әбисе үзләре генә калганда, беркайчан да татар телендә сөйләшмиләр. Дин мәсьәләсенә килгәндә дә шушы ук хәл кабатлана, әбиләр бер-берсен үзләренең дини бәйрәмнәре белән котлыйлар, кунакка йөрешәләр, күчтәнәчләр бирешәләр. Балалык чорыннан ук бергә булган Елена белән Камил үсеп-буй җиткәч, бер-берсен бик яраталар һәм гөнаһ кылып булса да, бер-берсе белән кавышалар. Ике яктан әбиләр башта беркадәр каршы булалар, әмма яшьләрнең араларына киртә булып басмыйлар, сөйләшеп-аңлашканнан соң үз фатихаларын бирәләр.

Елена белән Камил тормышларының беренче көннәрендә бик бәхетле яшиләр. Бер-берсен хөрмәт итәләр, әмма тора-бара, яшьләрнең мәхәббәт уты сүрелә, берсе артыннан берсе күп сандагы аңлашылмаучанлыклар килеп чыга башлый. Елена, гомумән, дөрес түгел юлга, секталарга кереп китә. Нәтиҗәдә, гомер буе дус яшәгән ике милләт әһеле бер-берсен күрә алмас дәрәҗәгә җитәләр. Әлбәттә, бу фаҗиганең асылында никахсыз кылган гөнаһ ята. Әмма, нәкъ югарыдагы “Илгизәр + Вера” пьесасындагы кебек ике милләтнең гаилә корып яши башлавы халыклар арсындагы дуслыкның җимерелүенә китерә.

Катнаш никахлар темасын минем рус әдәбияты мисалларыннан да эзләп карыйсым килде. Ләкин күп кенә сандагы эзләнүләрдән соң, рус халкына катнаш никах темасы түгел, ә тигезсез никах проблемасы актуаль дигән нәтиҗәләргә килдем. Рус әдәбиятның бөек классикларының күбесе әлеге теманы яктырткан. Мәсәлән, А.С. Пушкинның “Евгений Онегин” шигъри романында ярлыланган дворян кызы Татьяна һәм бай князь Н. өйләнешәләр. Әмма аларның никахлары бәхетле булмый, байлык кына кызның күңеленә үтеп керә алмый. Шушындый ук мисалны без Н.В. Гогольның “Тарас Бульба” әсәрендә дә очрата алабыз. Андрий байлыкны һәм мәхәббәтне үз Ватаны алдында булган бурычыннан өстен куеп, көндәш як короленең кызы Панночкага өйләнә. Ләкин икесе ике милләттән һәм икесе ике дәрәҗәдә булганлыктан, аларның да бәхетләре булмый. Андрийның этисе үзе үк улын үтерә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә, драматург Туфан Миңнуллин үзенең әсәрләрендә ике милләт вәкилен бергә бәхетле гаилә корып тора торган итеп тасвирламый. Милләтләрнең кушылуын ул җәмгыять һәм милләт өчен фаҗига итеп сурәтли. Төрле милләт балаларының кушылуы ике милләт халкы өчен дә зур фаҗига, чөнки милләтләр кушылса, тел дә, дин дә юкка чыга. Аларның бер-берсен хөрмәтләп

яшәгәндә генә сакланып кала дип әйтергә тели. Ә рус язучылары исә, яшьләрне үзләренең тиң ярларына өйләнергә өндиләр.

**Әдәбият**

1. Закирҗанов Ә.М. Хәзерге татар драматургиясенең актуаль мәсьәләләре: Уку-укыту әсбабы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2010. – 76 б.
2. Миңнуллин Т. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2008. – 479 б.

## УПОТРЕБЛЕНИЕ СЛОВ-ПАРАЗИТОВ В РЕЧИ УЧАЩИХСЯ

*Харисов Т., Республика Башкортостан, Абзелиловский р-н, МБОУ СОШ д.Рахметово, X класс*
*Рук. – Ахмадеева Г.Р.*

Одной из важнейших проблем современного общества является проблема культуры речи. Ни для кого не секрет, что в последнее время наш язык претерпевает огромные изменения. Сегодня, все чаще в речи современных школьников стали «проскальзывать» лишние слова, так называемые слова-паразиты. Слова, которые изменили манеру говорения не в лучшую сторону. В литературе встречаются разные термины: «лишние слова», «пустые частицы», «слова-сорняки». В лингвистике они получили название слов- паразитов.

ля начала необходимо разобраться в том, что такое слово-паразит? Оно не несёт в себе никакой полезной информации, создавая речевую избыточность. Его можно сравнить с мусором, препятствующим пониманию основной сути того или иного разговора. Понятно, что, обсуждая за столом в кругу семьи прошедший день, проблема не кажется такой уж и важной. Тем не менее, коварство слов-паразитов заключается в их незаметности, и они могут проникать в нашу речь, в том числе, во время ответственных событий. По мнению специалистов, их наличие даёт собеседнику понять личность говорящего, уверен ли он в себе, способен ли сдержать свои обещания. Прежде, чем избавляться от речевого мусора, нужно определить, в чём он заключается, а именно, найти само слово-паразит.

Слова-паразиты – это слова или словосочетания, вносимые в речь, но не несущие никакой смысловой нагрузки. Такое явление наблюдается в связи с недостаточной речевой культурой говорящего или в связи с тем, что говорящий затрудняется в выборе слова, не решается определённо высказать мысль. В качестве слов-паразитов чаще всего выступают: *прикинь, это самое, ну, типа, не вопрос, как бы, без проблем, короче, в принципе, по-любому, практически, так сказать, в общем*.

Есть целый ряд терминов, определяющих слова-паразиты: «незнаменательная лексика», «лишние слова» (О.Б.Сиротина), «вставные элементы» (Т.А.Ладыженская), «слова-заменители»

(Е.А.Земская). Самое распространённое определение слов-паразитов, данное филологами – слова и звуки, засоряющие устную речь. [1: 9]

Большинство лингвистов считают, что «слова-сорняки» используются из-за бедности словарного запаса, а сейчас на эти слова в обществе возникает «мода», поэтому их используют практически все люди. Иногда «слова-паразиты» используются для того, чтобы вспомнить что-то или потянуть время.

Существуют также звуки-паразиты. Многие люди имеют привычку, подбирая нужное слово, тянуть «э-э-э», «а-а-а» или «м-м-м». Эта привычка обычно очень раздражает слушателей [3: 54]

Чистота речи – отсутствие в ней лишних слов, слов-сорняков, слов-паразитов, которые становятся таковыми из-за частого и неуместного их употребления. Проблема эта возникла не случайно, а в связи с тем, что за последние два-три десятилетия культура русской речи населения страны катастрофически падает. Нарушение в речи литературных норм, бедность лексического запаса и грамматического строя речи, употребление грубо-просторечных, жаргонных, вульгарных, нецензурных слов, слов-паразитов и слов-сорняков, ненужных иноязычных слов и т.д. стало обычным явлением даже в речи образованной части населения, не говоря уже о «простом» народе. Не свободны от речевых ошибок и небрежностей радио- и телепередачи, спектакли в театрах, культурно-массовые мероприятия в клубах и т.д. Подобная картина чревата опасными последствиями: если не остановить этот процесс, то в конечном итоге это может привести к смерти языка. Останавливать процесс падения культуры речи нужно начинать в школе. С этой целью нужно создать в школе культ грамотной речи (в школе должна звучать только грамотная речь), воспитать у каждого ученика нетерпимость к любым речевым ошибкам; вести беспощадную борьбу с употреблением вульгарных, нецензурных, ругательских, грубых, жаргонных слов, слов-«сорняков»; культивировать активное употребление формул русского речевого этикета; ввести режим высокой речевой культуры и т.д. [2: 117].

Таким образом, слова-паразиты засоряют речь говорящего, затрудняют её понимание, отвлекают внимание от содержания высказывания. Как компьютерные вирусы разрушают операционную систему, так и слова-паразиты портят наш язык. Чаще всего слова-паразиты используются учащимися из-за скудности словарного запаса. Иногда на эти слова возникает мода, поэтому их могут использовать и ученики, не имеющие проблем с речью. Я уверен, если каждый из нас задумается над этой проблемой, то успех обеспечен. И пусть как призыв звучат слова великого русского писателя И.С. Тургенева:

«Берегите чистоту языка, как святыню. Русский язык так богат и гибок, что нам нечего брать у тех, кто беднее нас».

Есть только один путь заставить человека говорить грамотно – научить его любить свой язык.

**Литература**

1. Дараган Ю.В. Функции слов-«паразитов» в русской спонтанной речи. – М, 1996. – 142 с.

2. Левонтина И.Б. «О словах-паразитах» // Русский язык в школе. – 2004. – №15. – С. 68-70.

## ПРОБЛЕМЫ ПЕРЕДАЧИ КУЛЬТУРНЫХ ОСОБЕННОСТЕЙ ПРИ ПЕРЕВОДЕ СТИХОТВОРЕНИЙ РЕНАТА ХАРИСА НА АНГЛИЙСКИЙ ЯЗЫК

*Хасянова Д., Буинский р-н, МБОУ «СОШ им. Р.З. Сагдеева», X класс*

*Рук. – Ягудина Г.З.*

«Я считаю: если стихи переводятся на английский, немецкий, китайский, японский, они должны звучать хорошо именно по-английски, по-немецки, по-китайски, по-японски». Эти слова принадлежат народному поэту Ренату Харису. Заново создать стихотворение средствами другого языка означает создать такое произведение, которое было бы максимально похоже на оригинал. Произведения, созданные Ренатом Харисом, вызывают живые эмоции: чувство гордости за свою страну, свою малую родину, свой народ. Очень важно, чтобы такие же эмоции могли испытывать и зарубежные читатели, знакомясь с творчеством автора через переводы. Нами выдвинута гипотеза: теряют ли изначальный смысл художественно-выразительные средства при переводе на другой язык?

Итак, перевод – это своеобразный ключ для межъязыкового общения, познания культуры и языка других народов. При переводе татарского литературного произведения на английский язык надо учитывать не просто необходимость перевода, а его качество. Оба языка неродственны генетически и разноструктурны. Поэтому значение имеет не только конкретный переводимый текст, но и лингвистика, история, культура, быт данного произведения. На английский язык стихи Рената Хариса переведены известным поэтом, переводчиком Равилем Бухараевым. На русский язык – Лилией Газизовой. Чтобы понять, удалось ли Равилю Бухараеву как переводчику заново создать стихотворение средствами английского языка, чтобы оно было максимально похоже на оригинал на татарском языке и чтобы понять, достоверно ли передана информация с одного иностранного языка (татарского) на другой (английский), не искажая

ее смысл, рассмотрим примеры из нашего "Словаря языковых средств выразительности" по мотивам стихов Рената Хариса.

В переводах сохранены и точно переданы на английский язык:

**анафора** *They are harmed by wind, harmed by sun, harmed by settling dust.*

**антитеза** You cannot get to paradise by a ladder.
You cannot get to hell through a pit.

**гипербола** The poet is crushed by his plenty of poems.

**инверсия** The abode of soul is ruined.

**контекстуальные синонимы** It is only among men
that I play, laugh, sing and chat.
It is among deaf-mute trees and rocks that I enjoy
the beauty of silence, relaying secrets to them.

**метафора** In the conifers, silence abides.

**метонимия** Your life always moves forward.

**олицетворение** In the leafy trees, noisy ovations live,
In the conifers, silence abides.

**риторический вопрос** And you ask, why is it,
that my soil is in constant pain?

**синекдоха** The Tatar just bathed in daylight.

**сравнение** A cloud…like a white cow

**эпитет** Oh, summers of life!

Таким образом, проанализировав несколько стихотворений Р.Хариса на трех языках, можно сделать следующие выводы:

1. Переводчику Р. Бухараеву в своих переводах удалось передать не только слово и идею поэта Рената Хариса, но и колорит культурной жизни татарского народа.

3. Переводы стихов Р. Хариса на английский язык звучат «ярко», «не скучно». Англоговорящие читатели без особого труда смогут понять мысль поэта – автора стихов.

4. В некоторых переводах не сохраняется рифма, но правильно подобранные языковые средства выразительности делают стихотворение доступным для понимания основной идеи автора.

5. Языковые средства выразительности в переводах сохраняются, но не во всех стихах. Это можно объяснить тем, что в английском языке нет точных эквивалентов этих выражений. Поэтому переводчик использует кальку.

6. В переводе на английский и русский языки «языковые краски», созданные поэтом Р. Харисом, немного тусклее. Оригинал «звучит» ярче и острее.

«Невозможно научить поэта создавать метафоры, это – знак таланта», – сказал когда-то Аристотель. Ренат Харис, действительно, талантливый поэт. Его талант – это его слово, с присущим только ему разнообразием языковых средств. И если вы хотите открыть для себя немного другого Рената Хариса, прочтите его произведения на английском языке. И вы поймете, насколько выразительны языковые средства выразительности в его стихах и как искренне они звучат в переводах. А наш «Словарь языковых средств» поможет вам в этом.

**Литература**


1. Сәйфуллина Ф.С., Закирҗанов Ә.М., Минһаҗева Л.И. Татарча-русча-инглизчә әдәбият белеме сүзлекчәсе. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2014. – 160 б.
2. Харис Р. Сайланма әсәрләр. 6 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.


## ЯКТАШ ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ ИҖАТЫНДА КЕЧЕ ВАТАН ОБРАЗЫ


*Хәйретдинова С., Буа р-ны, МБГББУ "Түбән Наратбаш ТГБМ", X сыйныф*

*Җит. – Шәрәфетдинова Л.Г.*


Табигать турында сүз алып барганда, аны берничек тә Кеше галиҗәнапләреннән башка күз алдына китереп булмый. Якташ шагыйрьләребез Ренат Харис һәм Гөлнур Айзетуллова шигырьләрен укыганда, бу картина тулаем күз алдына килә, шуның өчен аларның әсәрләрен бу темага туры китереп ачу бик уңышлы булыр дип уйладык. Алдыбызда түбәндәге бурычлар тора: туган җирнең якынлыгын, гүзәллеген аңлый белү хисләрен камилләштерү; туган якның күренекле шәхесләре турында белемнәрне тирәнәйтү; татар халкының мәдәни-тарихи мирасын, туган як әдипләрен өйрәнүгә кызыксыну уяту.

Хәзерге көндә укучыларга таныш булмаган күп кенә шагыйрьләр бар. Укучылар аларның кайберләренең телен, иҗатын класстан тыш уку дәресләрендә, әдәби түгәрәкләрдә өйрәнәләр. Якташ шагыйрәбез булган Ренат Харис һәм Гөлнур ханым Айзетуллова шигырьләренең телен татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә өйрәнү – туган як, туган туфрак кебек төшенчәләр белән якыннан таныштыру өчен кирәк.

Кеше һәм табигать, аларның үзара мөнәсәбәте дә – Р.Харис иҗатындагы төп темаларның берсе. Табигать образы аша кеше кичерешләрен тасвирлауга багышланган шигырьләр Р.Харис иҗатында аз түгел: «Яфракларың гәрәбә...», «Коела яшел яфрак», «Җир – чәчәк», – дигәч...», «Яктылык төшә», «Өянке» һ.б. Табигатьтә җәмгыять өчен, кешеләр өчен гыйбрәтле хәлләрне күп таба әдип. Еш кына андый шигырьләрнең төп идеясен, асыл мәгънәсен символик характердагы шигъри образ аша бирергә тырыша. Ул укучыга әйтер яңа сүзе булмаганга күрә алай эшләми, киресенчә, аның әйтер сүзе артык күп,

ләкин ул укучыларның үз фантазиясенә дә урын калдырырга омтыла: хөкем, нәтиҗә чыгару укучының үзенә кала

Ренат Харис шигырьләрен укыган вакытта, якыннарына багышланганнары гел реаль вакыйгалардан гына торыр кебек, ләкин тора-бара шартлылык көчәя, хыялда гына туа алырлык хәлләр күренә. Монда табигать күренешләре зур әһәмияткә ия, чөнки төп герой – лирик герой – табигать баласы. Туганнан алып бүгенгесе көнгә кадәр ул табигать белән бәйле, табигый инстинктлар колы. Ул шуннан илһам ала, андагы бай төсләргә соклана.

Аларда табигый моң ага, йөрәккә якын алганыңны сизми дә каласың. Ул алар аша Ватан төшенчәсен ача, аның якынлыгын ачып бирә.“Өянке”гә һөҗүм, җәрәхәт ясала тора. Һәркем аны үз кирәгенә файдаланырга тырыша. Ләкин агач әрсез, бирешми. Җирдә нәселен, токымын дәвам итә. Аңардагы яшәүчәнлек, әрсезлек кешеләргә дә өлге булырлык. Бу символиканы алдынгы идеяләрнең үлемсезлегенә дә, тарихта күпне күргән халыкларга дә кайтарып калдырырга мөмкин. Әсәрдә сүз яшәү көченең, тормышның мәңгелек процесс булуы, халыкның һәм аерым кешенең ныклыгы һәм чыдамлыгы турында бара. Анда яшәүгә, тормышка омтылыштан да көчлерәк хис юк, ул үлемнән, вәхшилектән өстен дигән фикер уздырыла.

Ренат Харис әсәрләренең лирик герое җирнең иминлеге, халыкның бердәмлеге хакына яши, табигатьнең матурлыгын күреп соклана һәм ул матурлыкның, хәтта бүгенге хәтәр шартларда да, мәңге дәвам итәчәгенә зур өметләр баглый.

Шагыйрь шигырьләре – чынлап та тормыш күренешләренең олы мәгънәсен ачучы әсәрләр. Бу иҗат дөньясында фикер һәрвакыт тирәнгә, фәлсәфи катламнарга кереп китә, кеше гомере, аның рухи яшәеше проблемаларына барып чыга. Шагыйрь иҗатының поэзия өчен төп кыйммәте дә шунда: ул бүгенге шигъри сүзнең көчен арттыруга зур өлеш кертә.

Гөлнур Хәлил кызы сүз сәнгате остасы буларак, гел әзер формалар белән генә эшләми, сурәтләү чараларын үзгәртә. Аның шигырьләрен тикшергәндә, без шул үзенчәлек белән очраштык.

Чагыштыру формасы ягыннан да үзенчәлекле. Аларда күбрәк бәйлекләр катнаша: бигрәк тә, гүя, әйтерсең лә, төсле, шикелле, кебек бәйлек, теркәгеч, теркәгеч сүзләр куллана. Чагыштыру өчен аның шулкадәр күп предметларга игътибар итүе дә сокландыра.

Без мәдәниләшүнең югары биеклегенә күтәрелдек. Инде кеше табигатьтән файдаланып кына кала алмый, ул аның яклаучысы, яңадан тууда, күтәрелүдә булышчысы да булырга тиеш.Бүген кеше табигатькә

бәйле дип әйтү генә дөрес булмас иде,чөнки табигатьнең язмышын кеше дә хәл итә,ул экологик тотрыклыкны саклап калырга бурычлы.

Якташ шагыйрьләребез Ренат ага Харис һәм Гөлнур Айзетуллова иҗатларында кече Ватаныбыз образын ачыклау максатыннан, түбәндәге нәтиҗәләрне ясый алабыз: вакыт, табигать, кеше Ренат Харис иҗатында кичереш үсешен үти; шагыйрьләр иҗатында табигать сурәте метафорик күзаллау аша тасвирлана; табигать шәхеснең холкын, рухи дөньясын чагылдыра; Кеше һәм Табигать бердәм булганда гына, яшәү дәвам итәр; әсәрләренең лирик герое җирнең иминлеге, халыкның бердәмлеге хакына яши, табигатьнең матурлыгын күреп соклана.

Йомгак ясап әйткәндә, шигырьләре – заман әсәрләре, бүгенге көннең мөһим мәсьәләләрен күтәргән гыйбрәтле тормыш бизәкләре. Безгә тагын шунысы ачык: алар һәрвакыт бөтен җаны-тәне белән үзенең укучылары язмышы өчен янып яши, аларның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, яшәештә булган начар гадәтләр турында искәртә; телебез, гореф-гадәтләребезне саклау һәм үстерү өчен тырышалар.

Татар шигъриятендә бу ике шагыйрь тирән эз калдыралар. Алар үзенчәлекле, кабатланмас шәхес булулары, җанга үтеп керерлек әсәрләр язулары белән кадерле. Татар милли әдәбияты фондын баетуга зур өлеш керткән иҗатларының гомере мәңгелек булыр, күңел дөньясы белән укучы арасындагы шигъри элемтә өзелмәс дип ышанасы килә.

**Әдәбият**

1. Айзетуллова Г. Өч мизгел. – Буа, 2012. – 76 б.
2. Харис Р. Замана эзләре: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 256 б.
3. Харис Р. Хәбәр: шигырьләр, җырлар, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 368 б.
4. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе. – Казан: Мәгариф, 2000. – 352 б.

## ФӘНИС ЯРУЛЛИН ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ОБРАЗЛАРНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

*Хәлиуллина Д., Казан ш., 121 нче лицей, X сыйныф*
*Җит. – Вәлиуллина Р.Х, Миннуллина А.И.*

Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Фәнис Яруллин шигырьләр генә язып калмый, ул прозаик һәм драматург та, әкиятләр остасы һәм ялкынлы публицист та. Әдип нинди генә юнәлештә эшләмәсен, аның дөньяга, яшәешкә үзенә генә хас фәлсәфи карашы, җәмгыяткә бара торган үзгәрешләргә үз мөнәсәбәте бар. Фәнис Яруллинның иҗатындагы уңай сыйфатларның берсе – язылачак әсәр геройлары кичерешен үз җаны аша уздырып, теге яки бу вакыйгаларга бәя биргәндә тормышта тупланган бай тәҗрибәсеннән һәм ачы язмыш сабакларыннан файдаланып, шулар аша тормыш агышына объектив бәя бирә белүен әйтергә кирәктер.

Аның хикәяләрендә фикер тыгызлыгы, сюжет төзеклеге, телнең чарланган булуы сизелеп кенә калмый, киресенчә әхлаклык, мәрхәмәт һәм шәфкатьлелек кебек төшенчәләрне укучы күңелгә җиткерүдә төп вазыйфаны үти. Ә ул, әлбәттә, язучының осталыгына барып тоташа.

Әдәби тәнкыйтьтә куренекле язучының иҗаты нәкъ менә шушы яссылыкта өйрәнгән фәнни хезмәтнең булмавы куелган темабызның актуальлеген билгели.

Әлеге фәнни эшебездә без Фәнис Яруллинны хикәя язу остасы буларак образларның бирелешен тикшерүне максат итеп куйдык.

Фәнис Яруллин иҗатында халык традицияләре, әхлак проблемалары җанны тетрәндерерлек вакыйгалар эчендә сүрәтләнә. Автор хикәяләрендә хәзерге заманның характерлы проблемаларына әйләнеп баручы әхлаксызлык, халкыбызда булган матур традицияләрнең – кешелеклелек, ата-ананы зурлау, үз гаебеңне тану кебек матур сыйфатларның югала баруы өчен борчыла. Олыны-олы, кечене-кече итеп карау, авыр чакта бер-береңә ярдәмләшү безнең халкыбызны үзәге нык булган милләт итүдә зур роль уйнаган сыйфатларның берсе. Күп кенә күркәм гадәтләребез онытыла яки башка халыкларның традицияләре белән катнашып, татар халкындагы кыйммәтле сыйфатлар башлангыч чордагы сафлыгын югалта бара. Кешеләрдә хөсетлек, бер-берсеннән көнләшү кебек яман сыqфатлар өстtнлек ала башлады.

Фәнис Яруллин үз хикәяләрендә бу хәятның төрле-төрле халәтләрен һәм мизгелләрен гәүдәләндерә. Әсәрләрендә сурәтләнгәннәрне авторның гадәти күз белән генә түгел, бәлки күңел күзе белән күрүе сизелеп тора. Нәтиҗәдә, ул без тормыш ыгы-зыгысында үз мәшәкать – борчуларыбызга чумып ничектер гамьсезрәк үтеп китә торган көндәлек бик гадәти хәлләргә һәм вакыйгаларга тукталып карарга, аларга сөенергә, борчылырга һәм, гомумән, бу фани дөньяда гамьле булып яшәргә өйрәтә. Баксаң, беренче карашка бертөрлерәк һәм дикъкатьне әллә ни җәлеп итми торган көндәлек яшәешебезнең асылда һәркайсы мәгънәле һәм игътибарга лаеклы вакыйгаларга, күренешләргә һәм язмышларга бай булганын күрсәтә язучы һәм безне тирә-юнебезгә, көндәлек очрашып йөри торган кешеләргә игътибарлырак булырга өнди.

Фәнис Яруллин хикәяләрендә хатын-кыз образы аерым урын алып тора. Ул аларны яратып, иң нечкә кичерешләрен төшенеп тасвирлый.

Хатын-кызны әдип төрле ситуацияләрдә ача. Юмористик әсәрләрендә алар хәйләкәр, тапкыр; тормыш-көнкүреш әсәрләрендә – акыллы, эшчән, сабыр; романтик әсәрләрендә хисчән, саф, ниндидер

биеклеккә омтылучы итеп тасвирлана; кайвакыт бераз идеаллаштыруга да урын бирелә.

Фәнис Яруллин әсәрләрендә хатын-кыз тормышында чор китереп чыгарган мәсьәләләр кузгатыла һәм шуңа кагылышлы әһәмиятле идеяләр күтәрелә. Ул идея герой тарафыннан әйтелгән афоризм булырдай сүзләр белән ныгытыла, һәм Фәнис Яруллин хатын-кызларның тормыштагы кыйбласын билгели.

"Сандугач баласы" хикәясендәге Әнсәрия, үз анасы ташлап киткән авыру малайның йөрәгенә зур сабырлык белән юл сала һәм "Әни" исемен яулый алган хатын, улын: "Яхшылыкны барлык җан иясе дә аңлый. Менә күрерсең, киләсе елга безнең бакчага бер генә кош ояламас әле", – дип юата.

"Бөек сер" хикәясенең героинясы – үсмер кыз Ләйсән фәлсәфәсе үзе матурлык: "Үзенә, киләчәк бәхетенә ышанмаган кеше – сукыр кеше. Андыйлар хакыйкатьне капшап кына табалар. Ә моңа күпме вакыт үтә, хәтта гомере җитмәскә мөмкин", – ди ул бер урында. "Зур мәхәббәт кешегә тормыш кебек бер генә бирелә, аны югалтмаска, гел үстерергә кирәк", – дигән сүзләрне дә шушы героиня әйтә. Шул рәвешле автор яшь героинясы авызыннан укучысына бәхетле булуның бик мөһим бер ысулын җиткерә.

Ф.Яруллин үзенең хикәяләрендә кызыклы гына стилистик алымнар куллана. Аларга бигрәк тә тавышларны төсләр белән бирү, әсәрләрендә эстетик зәвыкка, гаделлеккә игътибар итү, тышкы күренешләр белән артык мавыкмыйча, психологик моментлар аша кичерешләрне ачу, иҗатына мистика алымнары кертеп җибәрү һәм шуларны реаль җирлектән аермыйча типиклаштыру торган саен авторның иҗатында киңрәк урын ала. Мондый эзләнүләре һәм табышлары белән Фәнис Яруллин, гомумән, татар хикәясе үсешенә дә зур өлеш кертә.

**Әдәбият**


3. Өченче этап бер төшенчәне икенче төшенчә белән чагыштыруны, чагыштыру нәтиҗәсендә бер-берсен тулыландыруны күздә тота.

Һичшиксез, теоретик төшенчә формалаштыруның нигезенә дидактик принциплар салынырга тиеш. Алар материалны сайлап алуда, барлык формаларны, метод һәм алымнарны куллануда, максатларга ирешүдә орентир булып торалар.

Әдәби-теоретик төшенчәләр формалаштыру, márбөтен система буларак, авыр һәм күп вакыт таләп итүче процесс, ул үз эченә системалы һәм этаплап үзләштерүне, фәнни төшенчәләрне әдәби әсәрне өйрәнү барышында куллануны ала. Шуңа күрә дә теоретик төшенчәләрне өйрәнүдә гамәли якка игътибарны күбрәк юнәлтергә кирәк.

Мәктәпләрдә нәзари төшенчәләрне өйрәтүгә багышланган хезмәтләр төрле елларда басылып чыккан, шуңа да карамастан, әлеге хезмәтләр актуальлеген югалтмаганнар. Алар белән таныш булу һәм гамәлдә куллану, укытучыга дәресне югары дәрәҗәдә оештырырга мөмкинчелек бирә. Үз заманында бөек язучы һәм педагог С.Я. Маршак моның турында шундый фикер әйткән: “...сәнгать әсәрен өйрәнгән вакытта, ләззәтне югалтмыйча, үз дәресен әсәрләрне гади укудан башлап, җитди анализга кадәр үстерә алган укытучы гына бәхетле” [4: 1]. Әлеге фикер белән килешмичә булмый, чөнки дәрескә куелган максатка ирешкәндә генә укытучы кәнәгатьләнү таба ала.

Уку предметы буларак әдәбиятның урыны һәм роле аның үзенчәлекләреннән чыгып билгеләнә. Шуңа күрә дә мәктәптәге әдәби белем программага кертелгән, өйрәнелергә тиешле әдәби әсәр исемлегеннән генә тормый. Программадагы әдәби әсәрләрнең санын арттыру гына да әдәбият белеменең асылын өйрәнергә ярдәм була алмый. Шулай итеп әдәби белем бирүнең төп бурычы формалаша: “укучыларга нигез, сәнгатькә мөнәсәбәтне, тел байлыгын, әдәбиятка мәхәббәтне арттырырга сәләтле күренешләр турында белем бирү яисә аларны өйрәнүгә башлангыч белемнәрне бирү” [3: 73].

Әдәби әсәрне һәм әдәби төшенчәне янәшә куеп карый алмау әсәрне аңлауда кыенлыклар тудыра. Бу укучыларның әдәбиятка мөнәсәбәтләре үзгәрүнең, китап укымый башлауның бер сәбәбе дә булып тора. Шуңа күрә укучылар әдәбият дәресләреннән ләззәт алмыйлар һәм тәм тапмыйлар. Әйтелгәннәрдән чыгып, нәзари төшенчәләрне өйрәтүдә өч төп методик принципны аерып чыгарырга була:

1. Теге яки бу төшенчәне өйрәнү конкрет бер әсәргә туры килергә, төшенчәне барлык яктан да ачып бирерлек булырга тиеш;

2. Төшенчәләрне өйрәнгәндә дәвамчанлык принцибы сакланырга тиеш;

3. Яңа төшенчәләрне үзләштерә барган саен, алда өйрәнелгәннәрне кабатлый барырга кирәк [1: 55].

Әдәби төшенчәләрне өйрәнү теориясендә күзгә иң бәрелеп тора торган кимчелек – әлеге төшенчәләрнең билгеле бер логик эзлеклелектә, гомумиләштереп бирелмәве. Шуңа күрә аларны үзләштерү билгеле бер кыенлыклар тудыра. Бу пунктны истә тотып, С.Я. Маршак әдәби төшенчәләрне семантик билгеләреннән чыгып, "төркемнәргә берләштереп өйрәтүне" тәкъдим итә. Аның фикеренчә, мәсәлән, "архаизм" төшенчәсен "неологизм", "диалогны" "монолог" төшенчәсе белән карау уңышлырак [2: 87-88].

Бүгенге көн әдәбият белемендә өч проблемалы цикл аерылып күрсәтелә:

1. Язучының чынбарлыкны гәүдәләндерү үзенчәлекләрен өйрәнү;

2. Әдәби әсәрнең структурасын өйрәнү;

3. Әдәби процессларны өйрәнү [1: 79].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк. Әдәбият белемендә һәм мәктәп практикасында теоретик төшенчәләргә системалы анализ үткәрү кирәк дигән фикер елдан-ел ныгый. Әлеге мәсьәлә күп кенә методист-галимнәр тарафыннан өйрәнелә (А.С. Бутмин, М.Б. Храпченко). Аларның тикшеренүләре бер фикергә алып килә: төп максат – әдәби әсәрнең бөтен аспектлары да бертигез кабул ителүгә этәрү. Мәсәлән, сюжет һәм композициядә укучылар дәвер чынбарлыгын һәм автор фикерен күрә белергә тиешләр. Киләчәктә бу юнәлештә эзләнүләрне көйчәйтү мөһим.

**Әдәбият**

1. Буслакова Т.П. Современная русская литература: тенденции последнего десятилетия. – М.: Высшая школа, 2008. – 450 с.

2. Курдюмова Т.Ф. Проблемы преподавания литературы в средней школе / Под ред. Т.Ф. Курдюмовой. – М.: Просвещение, 1985. – 490 с.

3. Лотфи Г.Ф., Сайкин Ш.Р. Әдәби уку методикасы: V-VII классларда әдәбият укытучылар өчен кулланма. – Казан: Тат. книг. издат, 1956. – 110 с.

## ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СӨЙЛӘМ СИТУАЦИЯСЕН БУЛДЫРУ

*Ибраһимова Э., КФУ, V курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Галиуллина Г.Р.*

Сөйләм теле кешелек җәмгыятендә гаять әһәмиятле роль уйный. Аның төп вазифасы – кешеләрнең көндәлек аралашуын тәэмин итү. Кодификацияләнгән әдәби телдән аермалы буларак, ул барлыккка килүе һәм кулланылышы ягыннан беренчел санала, шунлыктан телдә

барлыкка килгән һәртөрле үзгәреш һәм яңалык, беренче чиратта, сөйләм телендә урын ала [1: 28-29]. Сөйләм теле ул импровизация белән характерлана торган тел формасы, ул алдан әзерләнмәгәнлек, спонтанлык кебек күренешләр белән тыгыз бәйләнгән.

Бүгенге көндә мәктәпләрдә татар телен өйрәнү берничә юнәлештә алып барыла. Элегрәк коммуникатив якын килү идеяләре, телне аралашу чарасы буларак өйрәнү рус балаларына татар телен өйрәтүдә өстенлек итсә, бүген галимнәр туган телне өйрәтүдә дә коммуникатив якын килүне дөрес саныйлар һәм аның үзенчәлеген лингвистик һәм коммуникатив компетенцияне бер үк вакытта формалаштыруда күрәләр. Аралашу компетенцияләрен формалаштыру нәтиҗәләре рәтендә Р.К. Сәгъдиева, Р.М. Гарәпшина, Г.И. Хәйруллина түбәндәгене дә атый: “урта сыйныф укучыларына хас булган кызыксыну даирәсенә, психологик һәм төрле аралашу ситуацияләренә бәйле рәвештә туган телдә аралаша белү” [4: 6]. Аңлашылганча, туган тел дәресләрендә төрле сөйләм ситуацияләренә нигезләнү программа буенча каралган.

Сөйләм ситуацияләренең классификациясе бүгенгәчә төгәл эшләнмәгән. Хәзерге методистлар сөйләм ситуацияләренең берничә тибын аералар. Мисал өчен, Е.И. Пассов һәм А.М. Стояновский ситуация типларын коммуникантлар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр төреннән чыгып аералар [3: 18-22]. Әлеге галимнәр фикеренчә, теләсә кайсы ситуациянең төп компоненты булып үзара мөнәсәбәтләр тора. Лингвистлар фикеренчә, беренче төр ситуацияләрдә коммуникантларның аралашу характерына һәм алар алдында торган коммуникатив бурычларга бәйле төстә, үзара мөнәсәбәтләрне социаль статус билгели.

Дәреслекләрдә аралашу ситуацияләренә караган сөйләм теле лексикасын өйрәнү үзенчәлекләрен ачыклау өчен, эшебездә рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә белем алучыларга атап төзелгән дәреслекләр анализланды. Без Е.И. Пассов һәм А.М. Стояновский тәкъдим иткән сөйләм ситуацияләренең классификациясенә нигезләнеп биремнәрне сайладык. Р.К. Сәгъдиева авторлыгындагы дәреслекләрдә бирем түбәндәгедән гыйбарәт: “Укы, партадашыңа текст белән бәйле сораулар бир, ә ул җавап бирсен. Рольләрегезне алмашырга онытмагыз”. Сирәгрәк очракта аерым сүзләрнең рус теленә тәрҗемәсе бирелә, бу сүзләр арасында гади сөйләм лексикасы да урын ала.

Аралашу ситуацияләрендә кулланыла торган сөйләм лексикасы буенча әңгәмә яки сораштыру эшләре оештырылуы аерым очракларда гына теркәлде. Мәсәлән, алтынчы сыйныфта исемнәрнең килеш белән төрләнешен өйрәнгәндә, турыдан-туры темага да караган, аралашу ситуациясен дә үзәккә алган Рөстәм Галиуллинның тексты тәкъдим

ителә. Безнең эшебез кысаларында исә түбәндәге сорауның бирелеше кыйммәткә ия: “*Йокы чүлмәге* сүзен сез ничек аңлыйсыз?” [5: 23]. Укучылар сүзнең фразеологик берәмлек булуын танийлар, мәгънәсен аңлаталар. Тәкъдим ителгән ситуация турында сөйләшергә мөмкин: ни өчен укытучы шушы сүзне куллана? Көтелгән нәтиҗә якынча түбәндәгедән гыйбарәт: биредә без социаль статуска бәйле аралашу ситуациясен күзәтәбез. Аралашу укытучы һәм укучы арасында бара, укытучы биредә белем, тәрбия бирүче, ә укучы тәэсир итү объекты буларак чыгыш ясый.

Эшебездә Ф.Ф. Харисов редакциясендәге дәреслекләр дә тикшерелде. Тугызынчы сыйныф дәреслегендә мондый бирем тәкъдим ителә: “Син татарча яхшы сөйләшәсеңме?” дигән темага диалог төзегез [2: 71]. Укытучы аралашу ситуациясен түбәндәгечә формалаштыра ала: “Без һәрберебез татар телен яратып, дәресләргә әзерләнеп йөрибез. Сез, үсеп килүче буын, телнең киләчәген билгеләүчеләр. Шул хакта уйланып, диалог төзегез”. Диалог төзүне рольле уен рәвешендә дә тәкъдим итәргә була. Бу очракта укучыларның берсе – зыялы, милли җанлы татар яше, икенче укучы – нинди дә булса башка роль башкаручы (әйтик, беренче сыйныфка баручы бала һ.б.).

Уңышлы биремнәрдән шулай ук алтынчы сыйныфтагы 353 нче күнегүне атарга була. Укучыларга юмористик хикәяне укырга кушыла, калын хәрефләр белән бирелгән фразеологизмнарның мәгънәләрен аңлатырга тәкъдим ителә [5: 152]. Бу очракта өзектәге геройны тасвирлауда, аның сөйләм портретына беркадәр тукталырга була. Тискәре коннотацияләргә яисә түбән стильгә хас үзенчәлекләргә ия булган берәмлекләрнең артык еш кулланылышы аның башкаларга карата да мөнәсәбәте, әхлакый сыйфатлары турында да әйтә. Укытучы мондый бирем тәкъдим итә ала: сезнеңчә, хикәя герое максатка ирешәме, фотобәйгедә бүләк ала аламы? Укучылар, көтелгәнчә, түбән әхлаклы, башкаларга өстен карауучыларның гадәттә уңышка ирешмәвен искә алып, тискәре җавап бирәләр. Шул рәвешле дәреснең тәрбияви әһәмияте дә арта.

Күренгәнчә, төрле галимнәр тарафыннан сөйләм ситуацияләренең бүленеше төрлечә булса да, ахыр чиктә, алар бер-берсен тулыландырып торалар һәм берникадәр дәрәҗәдә кабатлыйлар да. Безнең карашыбызча, Е.И. Пассов һәм А.М. Стояновский тарафыннан ситуацияләрнең дүрт тибын аерып чыгару өчен алынган нигез – үзара мөнәсәбәтләр типлары, үзара тыгыз бәйләнгәннәр һәм практикада ситуацияне теге яки бу типка кертеп карауда кыенлыклар барлыкка килә. Шуны ассызыклап китик: сөйләм ситуацияләрен уку-укытуда, тел өйрәнүдә куллану чагыштырмача күптән түгел киң таралыш ала.

Иң элек ул нигездә чит телләрне өйрәнүдә кулланылса, бүген галимнәр туган телне өйрәнүдә дә коммуникатив якын килүнең, аралашу компетенцияләре формалашуының әһәмиятен ассызыклыйлар.

**Әдәбият**


1. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар сөйләм телендә лексик интерференция күренеше // Tatarica. – 2018. – 22-35 б.
2. Мирзаһитов Р.Х. Татар теле. 9 сыйныф: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 190 б.
3. Пассов Е.И., Стояновский А.М. Ситуация речевого общения как методическая категория // Иностранные языки. – 1989. – С. 18 – 22.
4. Сәгъдиева Р.К., Гарәпшина Р.М., Хәйруллина Г.И. Рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен татар теленнән программа (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5 – 9 сыйныфлар. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2017. – 35 б.
5. Сәгъдиева Р.К. Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 6 нчы сыйныф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017. – 159 б.


## ОТНОШЕНИЕ К СЧАСТЬЮ В РУССКИХ ПОСЛОВИЦАХ И ПОГОВОРКАХ


*Инь Цайюнь, КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Исламова Э.А.*


В лингвистических исследованиях на современном этапе наблюдается повышенный интерес к человеку, его духовной жизни, нравственным ценностям, осознается необходимость глубокого изучения эмоций и чувств человека в культуре и языке. Счастье является одной из глобальных, бесспорных для любого человека нравственных ценностей, это конечная цель деятельности любого человека. В иерархии ценностей счастье стоит на самой вершине пирамиды. Рассмотрение русских пословиц и поговорок о счастье позволяет проникнуть в специфику восприятия мира, отражения культуры и национальных черт характера русского народа.

Ценности как стержневой концепт паремии исследуют в своих трудах Л.Б. Савенкова, Л.К. Байрамова, Т.Г. Бочина, Т.Е. Владимирова и др.

Источниками нашего исследования являются сборник “Пословицы русского народа” В.И. Даля и “Словарь русских пословиц и поговорок” В.П. Жукова.

Любое индивидуальное представление о счастливой жизни, насколько бы своеобразным оно ни было, не свободно от социальных влияний, накладывающих существенный отпечаток на всю систему ценностных ориентаций личности.

Счастье взаимодействует с внешним миром, заключенным в мире природы, культуры и социума, характеризуется историко-культурной

традицией.

Традиционное отношение к счастью, представление о нем находят отражение в русских пословицах и поговорках.

1) В русской культуре счастье эфемерно, изменчиво и его трудно удержать: *Счастье сквозь пальцы проскочило* [1: 512]. *Легко найти счастье, а потерять и того легче* [1: 512]. *Легче счастье найти, чем удержать* [1: 395]. *Счастье с неба не падает* [1: 512]. *Счастье на дороге не валяется* [1: 512].

2) Ценность счастья у русского народа противоречива: русские жаждут счастья, но в то же время считают, что счастье – это «везение» и «случайность», это иллюстрирует наличие счастья у людей с отрицательными чертами. Этот взгляд на счастье выражен, например, в таких пословицах: *Дурак спит, а счастье у него в головах стоит* [1: 98]. *Наше счастье – решето дырявое* [1: 221]. *Со счастьем хорошо и по грибы ходить* [1: 509].

3) В русском национальном сознании счастье считается ненадёжным, непредсказуемым и слепым, и в мире нет "формулы счастья", не существует стандартного способа обрести счастье. Счастье совсем не зависит от самого человека. *Счастье не лошадь: не везет по прямой дорожке* [1: 513]. *Счастье – вешнее вёдро* [1: 513]. *Счастье легко на помине не бывает* [1: 513]. *Счастье, что волк: обманет, да в лес уйдет* [1: 513]. *Счастье в руки не поймаешь;* [1: 513]. *Счастье – вольная пташка: где захотела, там и села* [1: 513].

4) Русские считают, что счастье недостижимо, и наиболее часто связывают его с риском неблагоприятного развития событий, счастье – своеобразное "предостережение", оно может таить в себе опасность; надо быть осторожным и в счастье, и в несчастье. *Счастью не верь, а беды не пугайся* [1: 513]. *Счастье не батрак: за вихор не притянешь* [1: 513]. *Счастье не кляп: в руки не возьмешь* [1: 513]. *Счастье не корова: не выдоить* [1: 513]. *Счастье не конь: хомута не наденешь* [1: 513]. *Счастье пытать, лишь деньги терять* [1: 513]. *Счастье искать – от него бежать* [1: 513].

5) С изменением социальной идеологии люди начали верить, что они не рождаются счастливыми, богатыми или бедными, все равны перед счастьем, и труд может создать счастье: *Счастье не дворянство, не родом ведется* [1: 513]. *Счастье не ищут, а делают* [1: 513]. *Где труд, там и счастье* [1: 77]. *Счастье не живет без хлопот* [1: 513]. *Наше счастье в наших руках* [1: 221]. *Счастье и труд рядом живут* [1: 513].

Эти пословицы проявляют активное отношение к счастью, связанное с убеждением, что счастья необходимо добиваться

собственными усилиями.

Итак, россияне традиционно считают, что счастье – это дар судьбы, которую нельзя принудить. Невозможно найти счастье намеренно.

Ценности не статичны, а постоянно меняются с изменениями окружающей социальной среды и имеют разные проявления в разное время.

В середине XX в. во всем мире произошла научно-техническая революция, которая оказала большое влияние и на культуру, и экономику, и на мышление человека. Раньше деньги обычно рассматривались как источник боли и даже зла. Тогда люди думали, что *счастье на деньги не купишь.* Для современных людей деньги являются важным фактором, влияющим на формирование счастья. Появляются новые выражения, например, *Не имей сто друзей, а имей сто рублей* [2: 265]. *Не имей сто рублей, а имей миллион* [2: 265]. *Счастье не в деньгах, а в их количестве* [2: 381]. Пословицы каждой эпохи отражают социальные обычаи и ценности своего времени.

Таким образом, представления о счастье являются одними из ключевых в русской национальной картине мира.

**Литература**

1. Даль В.И. Пословицы русского народа: сборник. – М.: Русский яз. Медиа, 1957. – 814 с.

2. Жуков В.П. Словарь русских пословиц и поговорок: около 1200 пословиц и поговорок. – М.: Рус. яз., 1991. – 534 с.

## РИФАТ СӘЛАХНЫҢ ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЧАГЫШТЫРУЛАР

*Исмәгыйлев И., Буа ветеринария техникумы, I курс студенты*

*Фән. җит. – Исмәгыйлева Г.Т.*

Рифат Сәлах – алгы сафта баручы яңа, яшь буын шагыйрьләрнең берсе. Аның шигырьләрендә мәхәббәт тә, тирән фәлсәфә дә, милләтебез язмышы өчен борчылу да бар. Бүгенге көн яңа татар әдәбияты күгендә Рифат Сәлах дигән шагыйрьнең үз йолдызы кабынды.Якташымның шигърият диңгезендә лаеклы урыны бар.

Шагыйрьнең бер генә шигыре дә укучыны битараф калдырмый, күңел кылларын тибрәндерә, күңелне дулкынландыра, кыбырсыта. Рифатның милли темага кагылышлы шигырьләрендә татар тарихы һәм аны барлау, бүгенге вазгыять һәм милләтнең киләчәге турында уйлану ачык тоемлана. Ул борчыла, үз халкын горур, көчле, ирекле итеп күрергә тели.

Шагыйрьнең шигырьләре метафораларга, стилистик фигураларга, кабатлауларга бай.

Тропларның иң гади һәм киң таралган төрләренең берсе – чагыштырулар. Рифат Сәлах иҗатында алар бик күп.

Мисалга түбәндәге юлларны китерә алабыз:

*Алларымда / Истәлегең тора – / Соңгы ядкяр – тәүге китабың. / Сурәтеңне / Яңа бөреләнгән / Ак каеннар белән бутадым* (“Саташу”).

*Дөньяда сүзләр генә җитмәс, / Әйтеп бирер өчен күңелдәген.*

*Төнге күктә йолдыз дигән идем – / Чыклы иртә икән иреннәрең* (“Тәүге адашу”).

*Алдагы троп шигъри юлларның тәэсир көчен арттыра.*

*Ашың булса әгәр, / Башың булса, / Күкләреңдә аең бер калкыр.*

*Үзебез дә илсез-җирсез килеш / Таш өстендә үскән куактыр!* (“Таш өстендә үскән куаклар”).

Шагыйрь хисләрне сурәтләгәндә дә чагыштырулардан оста файдалана.

*Күз яшеңне яшермә син, яме, / Күренәсе инде күренгән.*

*Кочак-кочак кызыл гөлчәчәкләр Ташып чыккан чагы күңелдән* (“Гөлчәчәкләр”).

“Кыйгач кашым” шигыре Рифат Сәлах иҗатында чагыштыруларның шактый күп булуын раслый, алар сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төзеклек, үтемлелек өсти.

*Карлыгачтай кыйгач синең кашың, / Ә күзләрең – көзге төннең үзе.*

*Сабырсыз дип гаеп такма, җаным, / Күңелкәем инде күпме түзде?*

*Төнге җилдәй озын толымнарың!.. / Кем үрелде аңа, кемнәр кисте?*

*Сабырсыз дип гаеп такма, җаным, / Көтеп торалмадым айлы кичне.*

*Күңел дөньяң диңгез сыман синең, /Язмышың да шундый: дулкын-дулкын.*

Сурәтләнә торган объектына туры китереп шагыйрь чагыштыруларның яңадан-яңаларын иҗат итә.

*Тәрәзәң төбендә карашың... / Син дә мин атлыйбыз янәшә.*

*Офыклар – ул безнең тәрәзә, Үзенә чәчәкле җәй дәшә...* (“Тәрәзәңдә нинди моң?”)

*Баткан кояш яктысында / Чагыла гүя йөзең.*

*Бит очларың әйтерсең лә / Кызарып пешкән йөзем* (“Кызарып пешкән йөзем”).

*Син дә күңелем түрендә / Сары яфрак сыман.*

*Ничек котылырмын икән / Көзләр арасыннан* (“Көзге элегия”).

Алдагы мисаллар Рифат Сәлах иҗатында чагыштыруларның шактый күп булуын раслый, алар сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төзеклек, үтемлелек өсти.

“Казан егетләре”, “Райян”, “Рәхәт Лукум” төркемнәре башкарган кайбер җырлар да аның сүзләренә язылган. Дус-ишләре арасында

гармун тартырга хирыс егетнең зур сәхнәләргә менмәгән, үзе көйгә салган җырлары да байтак әле. Бик талантлы бит ул. Кайчандыр «Шәрык» клубы кичәләренә йөргән кызлар, аның гармун тартып, җыр сузуларын әле дә сагынып искә ала. 25 яше тулганчы ук, хаҗга да барып кайта. Әдәбиятка һәм күңелләргә үзәк өзгеч мәхәббәт сагышыннан торган иҗаты белән килеп керә. Бүгенге көндә балаларга багышланган шигырьләре дә байтак. Үзе дә өч кыз этисе.

Саф, эчкерсез шигъри тәлгәшләр. Аларны укыгач, ничектер үзең дә караңгы вазгыятьне онытып, дөньяга, кешеләргә мәхәббәт белән, Рифат Сәлах күзләре аша карый башлыйсың. Яшьләр арасында иң моңлы, иң дини, иң романтик шагыйрь кем дип сорасалар, һич тартынмыйча, Рифат Сәлах исемен атар идем.

## БЕЛЕМ АЛУ-БИРҮ ЛЕКСИК СИСТЕМАСЫНДА "ӨЙРӘНҮ" ФИГЫЛЕ

*Ихсанов И., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Халиуллина Н.У.*

Белем бирү, тапшыру процессы шәхеснең интеллектуаль үсешенә хезмәт итә, аңа җәмгыятьтә нәтиҗәле эшчәнлек алып баруга әзерлек бирә. Әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәр безнең аңыбызга механик рәвештә турыдан-туры килеп керми. Кеше белемнәрне чынбарлыкны актив танып-белү процессында эзләп таба.

Кеше күп информацияне уйлау, аңлау, хәтерләү, белү процессында үзенең акылы, уй-фикерләре, тормыш тәҗрибәсе, дөньяга карашы аша үткәрә. Белем – теориягә нигезләнгән гомуми иҗтимагый-тарихи тәҗрибә, кешенең чынбарлыкны танып-белүнең нәтиҗәсе. Белем төрле дәрәҗәдәге дөреслеккә ия була ала. Танып-белү – белемне кабул итүгә һәм эшкәртүгә юнәлтелгән актив эшчәнлекнең төрле күренеше [3: 296].

Татар телендә *аңлату, агарту, белгертү, күрсәтү, өйрәтү, төшендерү, үгетләү* лексик берәмлекләр белем бирү, тапшыру белән бәйле мәгънәләрне үз эченә алганнар.

Хәзерге татар әдәби телендә *өйрәтү* менталь фигыле берничә мәгънәдә кулланыла [4: 698]. Беренчедән, берәр эшне башкарырга, үтәргә, эшләргә күнекмә бирүне белдерә. Мәсәлән, *Ул егетне рояльдә уйнарга иң элек мин өйрәттем* (Ф. Бурнаш). Икенчедән, берәр төрле һөнәргә, белгечлеккә ия булырга, аны үзләштерергә ярдәм итү; шул һөнәр, белгечлек күнекмәләрен бирүне аңлата. Мәсәлән, *Безне монда күп кенә һөнәргә өйрәттеләр. Мин итек тегәргә өйрәндем* (А. Шамов). Өченчедән, нинди дә булса белем бирү; нәрсәне дә булса аңлатуны белдерә: *Костя аңа рус теленең грамматикасын, имла кагыйдәләрен өйрәтте, диктант яздырды* (Г. Әпсәләмов). Дүртенчедән, үзләштерергә, өйрәнергә ярдәм итү, булышуны аңлата.

Борынгы төрки телендәге *ög* рус телендәге “разум, мысль” мәгънәсенә туры килә. Мәсәлән, *ne edgü turur bü kišikä ög-ä.* – Как хорош для этого человека разум (“Кутадгу билиг”). – Ничек изге (яхшы мәгънәсендә) торыр бу кешегә өйрәнү (аң, акыл мәгънәсенә) [2: 378]. Шулай ук, түбәндәге борынгы **ög* тамыры белән бәйле сүзләр хәзерге татар теле материалы белән чагыштырма яссылыкта китерелә:

1) *ögä* мудрый, мудрец*: ögi bolsa ötrü ataγu ögä.* – Если есть разум, [человека] следует назвать мудрым (“Кутадгу билиг”).

2) *ögälä* называть, считать мудрецом*: ol anï ögälädi.* – Он называл его мудрецом [МК, I, 310]. – Ул аны өйрәнгән (акыллыланган мәгънәсендә) санады.

3) *ögälik* мудрость*: qajuqa ögälik tegir ög bulur.* – Иного осеняет мудрость, и он обретает разум (“Кутадгу билиг”).

4) *ög bilig* парн. разум и знание*: qulaqï saq ersä ögi bilgi keŋ.* – Если будет внимательным, разум и знание будут обширными (“Кутадгу билиг”). – Сак (игътибарлы мәгънәсендә) булса, өйрәнү (~акыл), белем киң булыр.

5) *ög köŋül ačïl* проясняться (об уме): *turup čïqtï sevnü qapuγqa külä / ögi köŋli ačlip jarudï jula.* – Он поднялся и вышел, радуясь и улыбаясь, / его ум просветлел, и факелы осветили дорогу (“Кутадгу билиг”). – Торып чыкты, сөенеп, көлеп, өйрәнүе (~акылы, күңеле) ачылды, юлын яктыртты.

Р.Г. Әхмәтьянов фикеренчә, **ög* фигыле гомумтөрки телендә “акыл бирү, өйрәтү” мәгънәсен аңлата. *Үгет* “наставление”, *үги* “неродной, сводный”, үксез “сирота”, үкенү, өйрәнү берәмлекләре *ög* тамырыннан ясалган һәм тарихи күзлектән гомоген саналалар [1: 222]. Татар телендә *үгетләү* фигыле берәүне изге ният, уңай теләк белән яхшы эшләргә өндәү яки начар эшләрдән кайтырга димләү, киңәш бирүне аңлата: *[Әни], мәптеккә зуррак булгач йөрерсең, әнкәң әйткәнне тыңла, быелга мәзин абыстаена гына йөреп тор дип, мине бик озак үгетләде* (М. Гали). Төрки телләрдә **ög* тамыры укыту белән бәйле төшенчәләрне белдерәләр. Татар телендә дә бу тамыр кайбер очракларда саклана: *өйрәнчек* – мәктәпкәчә яшьтәге, укырга төшәргә әзерләнүче бала.

Мәгънә төзелеше буенча караганда, *өйрәтү* лексемасының *укыту* фигыле белән уртак семалары бар. *Укыту* ул – дәрес өйрәтү, укытучылык итү. Шулай ук “укырга мөмкинлек бирү, материаль тәэмин итеп тору” да шушы берәмлек белән белдерелә: *кызын гимназиядә укытты*. Күчерелмә мәгънәдә килгәндә, *укыту* – кемне дә булса берәр хәлне, тиешсез эшләрне яңадан кабатламаслык итеп җәзалау, сабак бирү [4]. Фонетик төзелеше буенча караганда да,

*өйрәтү ~ укыту* сүзләре арасында тарихи закончалыклы аваз күчешләрен күрәбез: *g/к > й: **bag* > *бәй.* Димәк, белем алу һәм белем бирү белән бәйле лексик берәмлекләр системасында *өйрәнү, уйлау, аңлау, уку* лексемалары арасында тарихи бәйләнеш күрәбез, ягъни аларны гомоген тамырлар дип әйтергә була.

Хәзерге татар әдәби телендә *аңлату, агарту, белгертү, күрсәтү, өйрәтү, укыту, үгетләү* менталь фигыльләре белем бирү процессы белән турыдан-туры бәйле һәм төшендерү, аңлаешлы итү, гыйлем бирү, аң-белемле итү, җиткерү, сиздерү, билгеле итү һ.б. белем тапшыру белән бәйле мәгънәләрне аңлаталар.

**Әдәбият**


1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан, 2001. – 272 б.
2. Немов Р.С. Психологический словарь. – М.: ВЛАДОС, 2007. – 245 с.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Т.I-III. – Казан, I – 1977. – 476 б; II – 1979. – 726 б.; III – 1981. – 832 б.


## “ХАТЫН-КЫЗ” КОМПОНЕНТЛЫ МӘКАЛЬЛӘРНЕҢ СЕМАНТИК ТӨРКЕМНӘРЕ


*Кадыйрова Г., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалетдинова Г.Ф.*


Хәзерге вакытта кешене тел картинасында өйрәнү гендер үзенчәлекләрен чагылдыра торган тел характеристикасын исәпкә алып, лингвистиканың төрле өлкәләреннән белгечләр игътибарын җәлеп итә. Шулай итеп, Г. Брандт билгеләү буенча гендер – ир кешене хатын кыздан рухи аермасы – сөйләм, үз-үзеңне тоту, шәхси үзенчәлекләр җыелмасыннан гыйбарәт [1: 169]. А.В. Кирилина һәм М.В. Томская гендерны «шәхси сыйфатларны һәм аның биологик җенесе нигезендә үз-үзеңне тоту нормаларын тасвирлауга бәйле социаль конструкт» буларак карый. Әйтергә кирәк, төрле тел мәдәниятләрендә гендер стереотипларының турыдан-туры эчтәлеге тел структуралары ярдәмендә, безнең очракта билгеле бер дәрәҗәдә бәя бирә торган мәкальләр һәм әйтемнәрдә күрсәтелә.

“Хатын-кыз” мәдәнияты җәмгыятьтә гомумкешелекнең әхлак кыйммәтләрен, гаиләне, нәселне, тормышның үзен саклау серләрен тапшыручы, күчерүче бөек дөнья. Аны тәрбиясенә, белеменә бәйсез рәвештә һәр хатын-кыз да үзендә йөртә, ул универсаль сыйфат санала. Менә шул дөнья хатын-кызга теләсә-кайсы өйгә керергә, анда тормышны кабызып җибәрергә мөмкинлек бирә.

Мәкаль-әйтемнәр ярдәмендә мәдәниятта хатын-кызның тоткан урыны, һәм хатын-кызга булган мөнәсәбәт, фикер, аларга хас булган характер үзенчәлеге ачыклана. Без әлеге эшебездә татар халык

мәкальләрендә хатын-кызларга хас сыйфат, характер үзенчәлекләренең бирелешен тикшердек.

1. Хатын-кызның тормыштагы рольләренә бәйле рәвештә:

Н. Исәнбәтнең хезмәтендә килен лексемасы кергән мәкальләр шактый очрады. Аларда киленгә карата ике төрле мөнәсәбәт чыгыла. Бер яктан караганда, килен ярдәмче һәм таянырлык яхшы сыйфатларын мактый. Әмма без киленгә тискәре мөнәсәбәт чагылган мәкальләрне дә күрә алабыз. (*Яхшы килен – килен, яман килен – үлем.)*

Тормышта бәхетле булу өчен хатыннан уңу кирәк дигән мәгънәдә килгән мәкальләр күп. (*Атың начар булса да, хатының яхшы булсын.)*

Мәкальләрдә ана кешене хөрмәт итү, кадерләү, олылау, ярату, җылылык таратучы, изгелек теләүче кебек һәм башка матур сыйфатлар яктыртыла. *(Кояш янында – җылылык, ана янында – изгелек.)*

2. Хатын-кызның характерына бәйле.

Татар халык мәкальләрендә хатын кызның холкын, сыйфатларын, характер үзенчәлекләрен билгеләгән мәкальләр бик күп. Мәкальләрдә хатын-кызларның иң беренче урында намусын саклап калырга (*Би белеген бирер, кыз намусын бирмәс),* тыйнак булырга тиешлеге *(Хатын-кызны бизәктән дә бигрәк адәп-нәзакәт бизи)* әйтелә. Кайбер мәкальләрдә кызларның туры сүзлелеге, күз яше белән алдалавы, ышанычсыз булулары турында да мәкальләр очрады: *Хатын-кыз көче – күз яшендә.*

3. Мәкальләрдә хатын-кыз һәм ир-атның рольләре.

Хатын-кыз белән беррәттән ир-егет образы чагыштырылып карала. Ир-егет образы белән чагыштыру, хатын-кызның гаиләдәге урынын билгеләр өчен кирәк. Ир-ат ат, баш, табучы һ.б сүзләр белән килгәндә, хатын-кыз арба, муен, туздыручы кебек сүзләр белән килә. Бу исә, хатын-кызның һәрвакыт икенче урында торуын күрсәтә. Ягъни, гаиләдә, йортта баш кеше – ир. Шуны аңлатыр өчен дә, күп мәкальләр ир-ат образы белән бирелә: *Ир – ат, хатын – арба.* Элек-электән үк хатын-кызлар өйне чиста тоту, ашарга пешерү, кер юу белән шөгыльләнгән. (*Ир-ат булса, йорт-җирен макта; хатын-кыз булса, аш-суын макта.)* Хатын-кыз белән ир-егет образлары бер мәкальдә килгәндә, күбесенчә, хатын-кызга хас сыйфатлар алга чыгарыла. Кайбервакыт хатын-кызларның ирләргә караганда көчлерәк булуы турында, хатын-кызларның хәйләкәрлеге турында мәкальләр очрый. Шулай ук, хатынның нинди булуы ирдән тора дигән мәгънәдәге мәкальләр дә бар. (*Ир күрке – хатын, хатын күрке – ир.)*

4. Мәкальләрдә хатын-кызның йорттагы урыны бирелеше.

Хатын-кыз элек-электән үк гаилә учагын саклаучы, йорт тотучы, балалар тәрбияләүче буларак саналган. Гаиләдә ирләр авыр физик

эшне башкарсалар, хатын-кызлар өй җыештыру, кер юу, ризык әзерләү, эрләү, туку, чигү, бала карау эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Аларның хуҗабикә буларак роле гаять зур булу сәбәпле, көндәлек тормышларын көйләүче тулы бер кагыйдәләр системасы яшәгән. Хатын-кыз гаилә учагын саклау йөген үз җилкәсендә тарткан. Һәм һәр өйдә хатын-кыз булу зур бәхеткә саналган. (*Ипи тәме тоз белән, өйнең яме кыз белән.; Кыз бала – өй зиннәте.)*

Әлеге төркемләүдән чыгып, без, хатын-кызга төрде мөнәсәбәт булганын күрәбез. Мисаллардан күренгәнчә, хатын-кыз хәйләкәр, аңа ышанычсыз итеп тасвирланса да, ул – йортның яме, өйнең зиннәте, гаилә учагын саклап тотучы. Шул ук вакытта, татар хатыны уңган, киңәш бирерлек акыллы итеп, ата-ананы, аеруча ирне ихтирам итә торган образ буларак гәүдәләнә.

**Әдәбият**


1. Брандт Г.А. Природа женщин как проблема теории феминизма: историко-философский анализ. – Екатеринбург: изд-во Урал. гос. ун-та, 2000. – 50 с.
2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясенең нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 220 б.
3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр, 1959. – Т. 1. – 913 б. Т. 2. – 1963. – 959 б. Т. 3. – 1967. – 1013 б.
4. Мугтасимова Г.Р. Татар халык мәкальләре лексикасы. – Казан, 2005. – 190 б.
5. Юсупова Ә.Ш., Нәбиуллина Г.Ә., Денмөхәммәтова Э.Н., Мөгътәсимова Г.Р. Татар паремияләренең теле. – Казан: Ихлас, 2010. – 320 б.


## АЙГҮЛ КЕМЕЛБАЕВА ШЫҒАРМАСЫНДАҒЫ ТІЛДІК ҚОЛДАНЫС ЕРЕКШЕЛІКТЕРІ


*Каиржанова Н., Махамбет Өтемісұлы атындағы Батыс Қазақстан педагогикалық университеті, II курс магистранты*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. док., проф. Хасанов Ғ.Қ.*


Жаңа сөздер қоғамдағы сұраныс пен қажеттіліктен туындайтыны белгілі. Демек, ана тіліміздің өз мүмкіндігіне ғана сүйеніп қоймай, басқа да тілдік көздерді бүгінгі таңда пайдалануда. Мысалы-қолжазба[3: 156]; Айгүл Кемелбаеваның "Соңғы жолбарыс" атты екінші бөліміндеалабөтен қолжазба, қастерлі қолжазба сөздері қолданылған [2: 95]; Бұл арқылы автордың қай заманда, қай ғасырда өмір сүріп жатқандығын және сол кездегі жаңа сөздер легін біле аламыз. Совет үкіметі тараған тұстағы бұл оқиғада сөздік қорда орыс тіліндегі сөздердің аударылмай-ақ молынан қолданылғанын көреміз. Алайда, оларды кірме я термин, неологизмдер деп ажыратуға болады. Ал "қолжазба" сөзі сол кездегі жаңа сөз болып табылады.

Синонимдік теңеулерде алдыңғы қатарда тұратын қасиет-оның көркемдік және бейнелілік құдіреті, эмоционалды-экспрессивті әсерінің күші. Соған орай олардың семантикалық қызметі де сан алуан

[3: 249]; Құдайберген Жұбанов синонимдік теңеулерді бірнеше түрге бөлген. Соның ішінде сын-сапа, түр-түсті анықтайтын теңеулер жазушы әңгімелерінен көп байқауға болады. Мысалы, *Москвама титтей өкпе емес, таудай ризашылығымды арқалап, сағынып бара жатамын.* Титтей мен таудай, өкпе мен ризашылық бір-біріне антоним болып келеді. Ал титтей мен таудай мағынасы жағынан қарама-қарсы сөздер кішкентай және үлкен сөздерінің орнына қолданылып тұр [2: 78]; Осы синонимдік қатардың алдыңғы қатарда тұратын қасиет-оның көркемдік және бейнелілік құдіреті, эмоционалдық-экспрессивті әсерінің күші. Соған орай олардың семантикалық қызметі де сан алуан. [3: 249]; Қазіргі таңда терминдер, тіпті, қала атаулары да кірме сөздер ретінде аударылса да, жазушы кейбір сөздерді сол кезді қолданысына сай өзгертпей, дөп беруді жөн көреді. Мысалы: *Көп ұзамай Домодедовадағы аэропортта отырғанымды, туған елдің дәмі тартып, көкке көтерілердің алдында бес жыл бауыр басқан ұямды, ардақты Москвамды қимай аттанатынымды ойлауға көштім...*[2: 77]; Жалпы, қазіргі таңда Москва – Мәскеу, аэропорт – әуежай деп білеміз. “Әуежай” сөзі – жаңа сөз әрі жеке-дара дербес лексика-грамматикалық мағыналары бар біріккен сөз болып табылады. Бұл туралы Шерубай Құрманбайұлы былай дейді: Егер термин жасалып, қолданылып жүрген болса, оны алмастыру- ол белгілейтін таңбаланушыны “қайта атау” болып табылады [4: 126]; кірме сөздер тек орыс тілінен енбеді. Қазақ тіл біліміндегі сын-сапаны білдіретін синонимдік теңеулер қатарында “таза” сөзін мұнтаздай мүсіндей, айнадай секілді сөздер алмастырса, Айгүл Кемелбаеваның авторлық таңдауында “өзен суындай” сөз қолданысын көре аламыз[3: 249]; *Ол да ағып жатқан өзен суындай тұрлаусыз, мөлдір һәм таза. Оны идея күйінде дер кезінде жазып үлгермесең бітті, бұл фәнидегі қас-қағым сәттің көркемдігі ұшпалы, ол қайталанбайды*[2: 90]; Сонымен қатар алдың сөйлемде тұрлаусыз сөзі қолданылса, кейінгі тұрған ұшпалы сөзі синоним болып, бір сөздің келесі сөйлемде қайталанбауына мүмкіндік беріп тұр. Сол секілді «көбейіп» сөзінің орнына сөйлемде синонимдік қатар қолданылып тұрған қаулап, шүпірлеп өсіп-өніп сөздерді әрі көркемдік-бейнелілік мән беріп тұр. *Артынан Нұржан бәйбіше аналық қазға бастырған жұмыртқадан шошақбас, шұбар тауықтар көкке шыққан өрімдей дүр етіп қаулап, өсіп-өніп, шүпірлеп кетті*[2:100];

Жазушының еңбегінде термин сөздер жиі ұшырасады. ***Полиграфия*** *саласының ең мықты мамандарымен қатар әрбір қазақ ертегісінің иллюстрациясын салғызу үшін бас-басына бөлек суретші табар едім.Әріптері баспа қарпімен, әрі* ***каллиграфиялық*** *сұлулықпен*

*мұқият жазылған еді*[2: 95]; **Полиграфия, каллиграфия**-бұл сөздердегі графияның грек тіліндегі мағынасы – "жазу", ал "поли" – "көп" деген ұғымды білдіреді [4: 110]; Бұл әдебиеттану бағытында қолданылатын терминдер. Осы секілді әдебиет және тіл білімі саласында бірнеше терминдер тізбегін көрсетсек: сюжет, проза, идея, цензор, деталь, эпизод, автор, повесім, поэтика, эпиграф, энциклопедия, эстетика, алфавит, риторик-логик, мистика. Техникаға байланысты термин сөздер: интернет, компьютер. Қазіргі таңда осы келтірілген сөздердің көпшілігі қазақ тіліне аударылып, неологизм ретінде қолданылып жүр. Мысалы, интернет – ғаламтор, алфавит – әліппе.

Автордың тілдік ерекшеліктерінің бірі-синоним сөздердің, әсіресе, синонимдік теңеулердің сирек кездесетін, я өзінің авторлық теңеулері шығармаларында көптен-көп кездеседі: *Өйткені жолбарыс өзінің бір аталасы сілеусіндей қағілез, тағы бір алыс туысы қабыландай сылаң хайуан емес* [2: 109]; *Аш қасқырдай бұратылып, аш мысықтай мияулаған ауыр күндер өтпеске ұқсайды*[2: 13]; *Былайғы тілшілікте жаңғалақ, икемсіз, құлықсыз, ұмытшақ, ақымақ басым қолжазбама қазығын айналған аттай қаламыммен байланып, мүлде маталып, арбалып қалдым.....; Күндізді түнге, қараңғыны жарыққа аунатып, ғаламды нұрға орайтын бір құдайдың дарытуымен қолжазбама көктемде қайтқан құстай қайырыла беретінмін* [2: 98]; алдыңғы сөйлемде келтірілген синонимдік қатар бойынша Ә. Болғанбаев бойынша талдасақ: «Синонимдер сөздердің жалпы мағыналық бірлестігіне қарай топтастырылады». Яғни бір ғана ақиқат шындықты көрсетіп, бір ғана ұғымды білдіретіндіктен олар синоним болып табылады [1: 49]; Мұнда жеке-дара тұрғанда бір-біріне синоним болмайтын сөздер суреткер қаламының құрметімен бір-біріне жақындасып, ұқсас суреттер жалпы теңеулік конструкцияның бейнелілік күшін, көркемдік қасиетін, эмоционалды-экспрессивтік саласын күшейте түседі [3: 246].

**Әдебиет**

1. Болғанбаев Ә. Қазақ тіліндегі синонимдер. – Алматы, 1970. – 101 б
2. Кемелбаева А. Мұнара. – Алматы, 2003. – 163 б.
3. Жұбанов Қ. Жұбанов және қазақ тіл білімі: Ғылыми мақалалар жинағы. – Алматы: Арыс баспасы, 1999. – 376 б.
4. Құрманбайұлы Ш. «Терминтану»: Оқу құралы. – Алматы: Атлас баспасы, 2001. – 244 б.

## АРХЕТИПЫ И СИМВОЛЫ КАК КУЛЬТУРНЫЙ КОД В ЛИТЕРАТУРЕ

*Каримова Г., БГПУ им. М. Акмуллы, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Халиуллина А.Г.*

Архетип и символ рассматриваются в ряду таких известных категорий, как миф, обряд, ритуал, фольклор. Вспомним всем

известные фольклорно-языковые символы: *калина* – любовь; *белый* – хороший, праздничный и т.д. При этом гораздо сложнее и на когнитивном и на речевом уровне отличить символ от архетипа.

Первоначально сформировавшись в философии, психологии и науке о мифе, понятие "архетип" стало "завоевывать свои позиции в литературоведении, культурологии, социологии, политологии, религиоведении и пр." [3: 7]. Понятие "а**рхетип"** ввел швейцарский психиатр, основоположник аналитической психологии – **К.Г. Юнг. Архетип** (др. греч. "архе" – начало, принцип и "типос" – образ, отпечаток, форма, идея) – понятие, восходящее к философской традиции поздней античности. Также, К.Г. Юнг предполагал, что **архетипические образы и идеи** часто отражаются в сновидениях, а также нередко встречаются в культуре в виде символов, используемых в живописи, литературе, религии. В особенности он подчеркивал, что символы, характерные для разных культур, часто обнаруживают поразительное сходство, потому что они восходят к общим для всего человечества архетипам.

К.Г. Юнг расширял и уточнял понятие архетипа в течение всей своей жизни. Он описал множество архетипов, дав им условные и весьма своеобразные, но точные названия: Самость, Персона, Тень, Анима, Анимус, Мать, Ребенок, Солнце, Старый Мудрец, Герой, Бог, Смерть [5: 83]. Например, Анима – это бессознательная женская сторона личности мужчины. Символы ее – Женщина, Дева Мария, Мона Лиза. Рассмотрим архетип Матери. Она сосредоточена на счастье других людей, рождена, чтобы рожать детей, любить их, воспитывать. Классический архетип Великой Матери довольно часто встречается, ему присущи жертвенность, альтруизм, принцип "не себе, а другим".

Обратимся к символам. Символ предполагает много значений. К.Г. Юнг в своей теории выделял два вида символов: индивидуальные и коллективные. Чаще всего данные символы проявляются в снах и фантазиях человека. Коллективные символы – это символические способы выражения и образы, представляющие понятия, которые человек не может чётко определить и полностью осознать. В своей статье "Подход к бессознательному. Значение снов" К.Г. Юнг раскрывает понятие символа: "…это термин, имя или изображение, которые могут быть известны в повседневной жизни, но обладают специфическим добавочным значением к своему обычному смыслу" [5: 64]. Символ имеет глубокий смысл, который невозможно раскрыть до конца. Например, вода, гора, птица, змея, дорога.

Символические образы широко используются в литературных произведениях. Правильное толкование символов способствует

глубокому и верному прочтению художественных текстов. Непонимание символической природы образов, напротив, может привести к грубым ошибкам в истолковании текста, к искажению авторского замысла. Символы всегда расширяют смысловую перспективу произведения, позволяют читателю на основе авторских “подсказок” выстроить цепь ассоциаций, связывающую различные явления жизни. Они позволяют увидеть представления людей о своей жизни, мире и в силу своего предвосхищения конструировать субъективную и социальную реальность.

Символ играет большую роль в возникновении и существовании архетипа. К.Г. Юнг различает два типа символов: природный и культурный. В связи с первым, происходящим от бессознательного содержания психики, можно говорить об огромном разнообразии вариаций основных архетипичных образов. Природные символы можно проследить по их архаичным корням – идеям и образам, найденным в древних записях и первобытных обществах. “Культурные символы когда-то использовались для выражения “вечных истин”, а некоторые религии используют их и сегодня” [5: 84]. Такие символы претерпели множество трансформаций, подверглись сознательному развитию и, таким образом, стали коллективными образами.

К.Г. Юнг отмечал сложность исследования и важность архетипов, поскольку они имеют значительное воздействие, влияние. По мнению Юнга, архетип – это фигура, повторяющаяся на протяжении истории везде, где свободно действует творческая фантазия. Нет ни одного важного образа, существенной идеи и воззрения без их исторических прообразов, все они восходят к тем или иным архетипическим проформам.

Таким образом, если рассмотреть соотношение архетипа и символа, необходимо уточнить, что по отношению к архетипу символ вторичен. Символ является крайней степенью осознанности и переработанности архетипа, его предметным воплощением.

Особо важную роль архетипы и символы приобретают в текстах метафорического и символического содержания – в мифах, сказках и символической поэзии, где в силу неисчерпаемого семантического потенциала речевые знаки, десигнаты которых включают символические значения, отсылающие к архетипам, становятся ключевыми символами, определяющими смысловую глубину, объем и аксиологическое содержание иллокутивного и перлокутивного измерений когнитивно-семиотической модели – текстовой матрицы. Сама текстовая матрица таких текстов может выстраиваться на основе

матрицы архетипической ситуации, скрытой в коллективном бессознательном, общем для всего человечества.

**Литература**

1. Алиференко Н. Ф. Лингвокультурология: ценностно-смысловое пространство языка: Учебное пособие. 3-е издание. – М., 2010. – 198 с.

2. Большакова А. Ю. Литературный архетип// Литературная учеба. – 2001. – №6. – С. 171.

3. Фаустов А. А. Архетип Поэтика: словарь актуальных терминов и понятий. – М.: Издательство Кулагиной; Intrada, 2008. – 358 с.

4. Юнг К. Г. Архетип и символ. – М.: Ренессанс, 1991. – 298 с.

5. Юнг К. Г. Человек и его символы. СПб.: Б.С.К, 1996. – 64 с.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ “ШАТЛЫК” КОНЦЕПТЫ

*Карипова И., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Хәлиуллина Н.У.*

Тел галимнәрен һәрвакыт милли телнең барлыкка килү, яшәеш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү мәсьәләсе кызыксындырып килә, чөнки телнең функциональ структурасы, әлеге структураның татар телендә сөйләшүчеләрнең аралашу мөмкинлекләре телнең байлыгын һәм яшәеш потенциалын билгели.

Күп галимнәр, психология фәненең үсеш тарихында, кешенең яшәешендә һәм тормышында, кичерешләрнең мөһим һәм зур роль уйнавына басым ясаганнар. Р. Декарт раславынча, кешелекнең иң мөһим тәэсир итү көче һәм теләге эмоцияләрдән гыйбарәт, алар кешенең җанын һәм тәнен тормышка дәртләндерәләр, дөньяга кайтаралар.

Төрле хис-кичерешләр чагылдыра торган сүзләр заманча фәнни әдәбиятта “эмотив лексика” буларак билгеле. Эмотив лексика тормышыбызның аерылгысыз өлеше булып тора, чөнки без һәрвакыт аралашканда, уйлануларда яки килеп туган тормыш хәлләрендә сыналган төрле эмоцияләргә дучар булабыз: без шатлыктан, моңнан көәбез, яратабыз һәм яратмыйбыз.

Эмоцияләрне өйрәнүнең тарихына килгәндә, аларның асылын бик күп төрле философик һәм логик позицияләрдән караганнар, физиология, психология, әдәбият белеме һ.б. тарафыннан тәкъдим ителгән мәгълүматлар нигезендә якын килгәннәр. Эмоцияләр тормыш өчен мөһим күп кенә функцияләрне үтиләр: адаптив (эчке һәм тышкы тирәлектәге үзгәрешләрне искәртә), чагылдыру-бәяләү, яисә аксиологик “субъектның үзенчә булган яисә булырга мөмкин төрле хәлләргә шәхси бәя бирү, эшчәнлегенә һәм аларның килеп чыгуына” [4: 77-78], юнәлдерүче, синтезлаучы, уятучы, “эвристик” һ.б.

Шатлык, ләззәт, бәхет – һәр кеше теләгән, һәрберебез шуңа омтылган әйбер. Барысы да бәхетле булырга ярата һәм үз

тормышларында мөмкин кадәр күбрәк шатлык хисен тудырырга омтыла. Хәер, бу максатка ирешү өчен һәр кешенең үз юлы да бар.

Дөньяның лингвистик картинасында “шатлык” – иң мөһим мәдәни төшенчәләрнең берсе. Шатлык – кешенең рухи гармониясе, ул ләззәт, теләк, игелек, тынычлык белән бәйле. “Шатлык” төшенчәсе “яхшы”, “мәхәббәт”, “иман”, “өмет”, “хакыйкать”, “бәхет” төшенчәләре белән тыгыз бәйләнгән.

Татар телендә “шатлык” төшенчәсенең синонимы: куану, ә каршы торган лексема – кайгы.

*Шатлык* ул – кешедә үзенең мөмкинлекләрен, теләкләрен тулысынча тормышка ашыру нәтиҗәсендә, шулай ук үз эченә уянуны, кызыксынуны, активацияне, нинди дә булса эшнең нәтиҗәсе белән канәгатьлек кичерү, комфортны да үз эченә керткән, ләззәт алу халәте, тирә-юньдәгеләр тарафыннан үзеңне яхшы хис итү, үз-үзеңдә ышаныч һәм тынычлык, шулай ук тормышның авырлыкларын җиңеп чыгуга ышаныч та ул. Шатлык кешенең халәтенә уңай тәэсир итә, когнитивтан психосоциальгә кадәр, барлык биологик һәм социаль функцияләрен башкара, шәхес белән тирә-юнь арасында тыгыз элемтә булдыруга ярдәм итә.

*Шатлык* – тулы канәгатьлек хисе; күңел күтәренкелеге, куаныч; тормыштан, үз хәленнән риза булу хисе.

Кэррол Э. Изард, дифференциаль эмоцияләр теориясен булдыручыларның берсе, эмоцияләр эволюциясе турында күп санлы эксперименталь мәгълүматларны анализлап, баланың шатлык хисләре үсеше процессы кызыксыну хисләрен үстерү процессына караганда бераз башкача бара, дип яза. Ата-аналар баланы шатлыкка “өйрәтә” алмый, алар баланы күңел ача һәм кызыктыра, шатлык хисләре уяна торган уеннарга җәлеп итә ала. Әти-әниләр шатлыклары белән уртаклашырга тиеш, бу эмоцияне кичерергә мөмкинлек бирә, әмма ахыр чиктә кеше үзе өчен шатлык хисен ачарга тиеш – шул чакта гына ул аның тормыш стиленең бер өлеше булачак. Шатлык хисләрен кичерү ул индивидуаль һәм генетик факторлар белән бәйле.

Шатлыклы кичерешләр кеше организмы өчен бик файдалы. Без шатлык хисен кичерәбез икән, организмыбызның барлык системалары җиңел һәм иркен эшли башлый, акыл һәм тән тынып кала, һәм бу чагыштырмача физиологик тынычлык бирә.

Хис-тойгыларны тапшыру өчен кешенең экспрессив дип аталган күп кенә чаралары бар. Бу – мимика, пантомика, күзләр чагылышы, характер хәрәкәте. Ә безнең сүз интонацияләрнең нечкәлекләренә тулы, үзгәрүчән ритм, экстралингвистика чаралары – сулау, көлү, һ. б. белән бәйләнгән.

Теге яки бу телдә эмотив берәмлекләрне (бу очракта фигыльләрне) тикшерү сөйләшүченең милли характер үзенчәлекләрен, дөньяга карашын, шуларның телдә чагылышан ачык күрсәтә ала. Шуңа күрә татар телендә бу өлкәгә караган лексик катламны өйрәнү бүгенге көндә перспективалы санала.

**Әдәбият**


1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Т.I-III. – Казан, I – 1977. – 476 с; II – 1979. – 726 б.; III – 1981. – 832 б.
2. Изард К.Э. Психология эмоций. – СПб.: Питер, 2003. – 464 б.
3. Калимуллина Л.А. История эмотивной лексики и фразеологии русского языка. – Уфа: Восточный университет, – 2004. – 120 с.
4. Леонтьев А.А. Основы психолингвистики: Учебник. 3-е изд. – М.: Смысл; СПб.: Лань, –2003. – 287 с.
5. Рейковский Я. Исследование выражения эмоций. – М.: Прогресс, 1979. – 392 с.


## ПОЯВЛЕНИЕ И ФУНКЦИОНИРОВАНИЕ ТЮРКСКИХ ЗАИМСТВОВАНИЙ В РУССКОМ ЯЗЫКЕ


*Кароматуллаева Ж., БухГУ, студент IV курса*

*Науч. рук. – ст. преп. Исаева Г.А.*


Проникновение элементов тюркских языков в русскую речь и в русский язык чрезвычайно многообразно, но до сих пор оно ещё недостаточно полно вскрыто, особенно в отношении грамматики, лексики и фразеологии. Мало исследований, касающихся воздействия тюркской фонетической и грамматической структуры на фонетику и грамматику некоторых диалектов русского языка. “Мало изучены тюркские заимствования в русском словообразовании (ср., например, тюркские модели в образовании некоторых так называемых парных слов) и фразеологии (ср. например, кальки с тюркских речений типа давай пойдём, давай посидим)” [1]. Н.А. Баскаков считает кальками, образованными на базе тюркских аналитических конструкций, такие разговорные формы, как он бросил пить, пошёл колобродить, пошла писать губерния, пошёл пьянствовать [1].

Изучение тюркизмов в русском языке и, шире, в славянских языках проводится в нескольких аспектах. Это выделение лексико-семантических и тематических групп заимствований, их периодизация, анализ особенностей семантического развития и функционирования в языке, а также частоты употребления, выявление морфологической структуры, этимологии. Ученые установили ряд признаков, которые могут служить критериями освоения русским языком заимствованных слов:

1) употребление слов в произведениях переводной и оригинальной художественной литературы, в периодике, в научных трудах без перевода;

2) заимствование слов в их первоначальной форме по причине отсутствия в русском языке соответствующего эквивалента, смысл которого может быть передан только описательно;

3) освоение слов русским языком с некоторыми фонетическими изменениями;

4) оформление их элементами русского словообразования и словоизменения.

Как пишет А. В. Калинин, большая часть слов тюркского происхождения заимствована во время татарского нашествия (XIII-XIV вв.), некоторые проникли раньше. Среди тюркских заимствований отмечены названия одежды и её частей: тулуп, сарафан, башлык, чулок, армяк, колпак; коневодческая лексика: лошадь, табун, аркан, буланый; хозяйственная лексика: амбар, сарай, утюг, сундук, войлок, чемодан, бадья, чугун, очаг, наждак; названия кушаний, продуктов: изюм, балык, шашлык, баклажан, лапша; слова, использующиеся в товарно-денежных отношениях: деньги, аршин, безмен, товар [3].

Кул һәм аякларның эшсезлеге физик көчсезлекне, тән үлемен белдерә: *Аяк-кул бәйләнү, Аяксыз кулсыз булу, Аяк-кулларың сызлаусыз булсын.* Ике аяклы, ике куллы булу нормаль кешене белдерә.

Аяк сүзе кергән фразеологизмнар кешенең интеллектуаль үсеш дәрәҗәсен, характерының төрле якларын да ача:

– Аңгыра кеше: *Ике аяклы ишәк.*

– Надан: *Аягыннан алып селексәң дә, бер хәреф (әлиф) төшмәс.*

– Бушка күп йөрүче: *Каеш аяк.*

– Яңа хәбәрләрне белеп торучы: *Ике аяклы гәзит.*

– Хайванга тиң кеше: *Ике аяклы бүре (хайван, эт).*

– Икейөзле, ялагай: *Алдан аяк ялый, арттан үкчә тешли.*

– Гаепне кешедә күрүче, вакчыл кеше: *Аягына таш тисә, миннән күрер.*

– Иренеп атлаучы, үшән кеше: *Ал аягын атлаганчы, арткы аягын эт ашый.*

– Әрсез: *Аягыннан элек таягы керә.*

– Күп йөрүче, оста телле кеше: *Каеш аяк, тасма тел.*

– Иренчәк, ялкау: *Кайсы аягын алдан басарга белми, Аягын санап атлый.*

– Әдәпле, тәртипле: *Аяк очына гына карап йөри.*

– Үткен, кыю: *Елан аягын кискән.*

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне белдергәндә дә фразеологик әйтелмәләр составында аяк сүзе катнаша. *Сүзне аяк астына егу, Сүзне аяк астына салу (салып таптау)* – үтенечне, сорауны үтәмәүне, *Сүзе аяк астында калмау* – сүз үтәлүне, *Икенче аяк басмаслык итеп* – куып, сөреп чыгару, араны өзүне, *Ике аягын (ботын) бер кунычка (итеккә) тыгу* – төрмәгә яптыруны белдерә.

Аяк соматизмы төрле философик категорияләрне аңлатуда да актив кулланыла. Мәсәлән, вакыт төшенчәсен төрле яклап *Аяк асты шил булгач, Кеше аягы басыла төшкәч* (кич, кешеләр йөрми башлагач), *Бер аягын алганчы икенчесен эт (корт) ашый* (әкрен), *Бер аягым монда, икенчесе тегендә* (бик тиз) фразеологизмнары күрсәтәләр. *Кеше аяк асты, Аяк юлы өзелми* – кеше күп йөрегән урынны, *Кеше аяк басмаган, Адәм аягы басмаган* әйтелмәләре кеше булмаган кыргый җирне, *Аяк баскысыз, Аяк басар урын юк, Аяк тыккысыз* – бик тыгыз араны белдерәләр. *Аягы тарткан якка* – билгесез якка юнәлүне күрсәтә.

*Аягы чокырда* берәмлеге бик карт, ә *Аягына сыер (бозау) басмаган* – яшь, тәҗрибәсез кешегә төбәп әйтүне аңлаталар.

Безнең тарафтан аяк сүзе кергән 174 фразеологик әйтелмәгә күзәтү ясалды [1].

Димәк, фразеологик берәмлекләрнең мотивацион нигезләрен тикшерү образлы чыганаклар өлкәсен өйрәнүгә кайтып кала. Бу очракта гәүдә өлешләре шундый чыганаклар ролен уйныйлар. Тотрыклы сүзтезмәләрнең тышкы һәм эчке үзенчәлекләре аларның компонентларының семантикасы һәм грамматик төзелеше, дөнья реалияләрен мәгънәви интерпретацияләү (символ буларак карау) белән бәйле.

**Әдәбият**

1. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге / Н. Исәнбәт; ред. В.Х. Хаков. – Ике томда. I том. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1989. – 495 б.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А-В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 284 с.

## РЕНАТ ХАРИС ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ ГАВРИИЛ ДЕРЖАВИН ӘСӘРЛӘРЕ

*Миндубаева С., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кириллова З.Н.*

Татар мәдәнияте тарихында беренче булып Гавриил Державин әсәрләрен дә татар теленә Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис

тәрҗемә итте. 2016 елда Г. Державин әсәрләренең татар теленә тәрҗемәләре “Кизләү” исемле җыентык рәвешендә дөнья күрде. Державин әсәрләре бүгенге рус укучысына да аңлашылмаган рус сүзләренә һәм башка төрле үзенчәлекләргә бай. Болар барысы да әсәрләрнең төп эчтәлегендә мөһим урын алып торалар. Тәрҗемә иткәндә шулар һичшиксез сакланып калырга тиешләр, ә моңа башка тел нигезендә, бигрәк тә татар телендә ирешү – бик тә катлаулы эш.

Белгәнебезчә, поэтик тәрҗемә бик зур тырышлык сорый. Р. Харис Г. Державин шигырьләрен тәрҗемә иткәндә сүзгә-сүз тәрҗемәне максат итеп куймый. Аның өчен төп нөсхәнең поэтик фикерен укучыга җиткерү һәм шул ук вакытта әсәрнең ритмын саклап калу мөһим. Шуның өчен ул төп нөсхәнең лексик-грамматик үзенчәлекләрен тәрҗемә теле өчен хас тәңгәллекләр белән алыштыра, шуның нәтиҗәсендә адекват тәрҗемәгә ирешә. Г. Державин әсәрләренең Р. Харис тарафыннан татар теленә тәрҗемәләрендә үзенчәлекле очракларны карап үтик.

“Признание” әсәрендә Г. Державин укучы белән турыдан-туры аралашу атмосферасын барлыкка китерә. Моның өчен ул гади сөйләм лексикасын куллана. Әлбәттә, бу лексик чараны тәрҗемә итү, төп нөсхәнең эмоциональлеген саклап калу тәрҗемәче өчен авырлык тудыра. *“Если где вельможам властным. // Смел я правду* ***брякнуть в слух****”*[1: 34] тәрҗемәдә *“Әгәр түрәләр* ***колагын*** *//* ***ярсам*** *дөреслек белән”* [2: 98] дип бирелгән. Гади сөйләм лексикасы булган *брякнуть в слух* сүзтезмәсен тәрҗемә итү өчен, Р. Харис гади сөйләм телендә еш кулланыла торган *колагын ярсам* тотрыклы сүзтезмәсен файдалана.

Г. Державин иҗатында метафоралар да әһәмияткә ия, алар эмоциональ-поэтик сөйләм барлыкка китерәләр һәм мәгънәне тулырак ачуга ярдәм итәләр. Бу лексик сурәтләү чараларының тәрҗемәдә бирелеше шулай ук үзенчәлекле. “Памятник” шигыре һәм аның тәрҗемәсе “Һәйкәл” шигырь юлларында метфораларга игътибар итик.*“И* ***времени полет*** *его не сокрушит”* [1: 30] тәрҗемәсе – *“****Вакыт агышы*** *да һәлак итмәс аны, тиеп”* [2: 62]. Әлеге юлларда *времени полет* метафорасы *вакыт агышы* дип тәрҗемә ителгән. Сүзгә-сүз тәрҗемә ысулын кулланып тәрҗемә иткәндә времени полет – *вакыт очышы* була. Әлбәттә, мондый очракта мәгънәви бәйләнеш тә, образлылык та югала. Димәк, бу ысулны куллану уңышлы түгел. Шуның өчен тәрҗемәче тәрҗемә телендә булган әзер сурәтләү чарасы кулланган.

“Задумчивость” шигыре һәм аның “Уйчанлык” дип аталган тәрҗемәсендә эпитетлар бирелешенә игътибар итик. “*Задумчиво один* ***широкими шагами****”* [1: 15] *“Уйчанланып, ялгыз,* ***киң-киң атлап****”* [2:

84] *Широкими шагами* эпитеты *киң-киң атлап* дип тәрҗемә ителгән. Сүзгә-сүз тәрҗемәсе *киң адымнар белән* булыр иде. Сурәтләү чарасының аерым компонентлар тәрҗемәдә үзгәртелгән. Бу тәрҗемәдә рифманы саклап калуга ярдәм итә, тәрҗемә телен тагын да бизәкләндерә.

*“**Как искры сыплются, стремятся**, // Так солнцы от тебя родятся”* [1: 5] – *“**Чәчри очкын, берсен берсе куа-куа** // Һәм кояшлар, **шулай** чәчрәп, Синнән туа”.* [2: 19]. Бу очракта төп нөсхәдә бирелгән чагыштыру тәрҗемә теленә сурәтләү чарасы итеп тәрҗемә ителмәгән. Бу шигырьнең формасын саклап калу өчен эшләнгән. *Очкын чәчрәгән, берсен берсе куган кебек* дип тәрҗемә иткән вакытта рифмага зыян килер иде һәм тәрҗемәнең эстетик матурлыгы югалыр иде.

Тәрҗемә барышында Р. Харис калькалаштыру алымына да мөрәҗәгать итә. Әлеге ысулны куллану саклык сорый, чөнки нәтиҗә һәрвакытта да уңышлы булмаска мөмкин. *“Храня обычаи, обряды, // **Не донкишотствуешь** собой”* [1: 98] юллары тәрҗемәдә *“Саклыйсың гореф-гадәтне – һич **донкишотланмыйсың**”* [2: 27] дип бирелгән. Әлеге очракта тәрҗемәче морфемаларны кисәкләп тәрҗемә иткән, нәтиҗәдә төп нөсхәнең лексик һәм грамматик мәгънәсен тәрҗемәдә саклап калуга ирешкән. Бу берәмлек ярымкалька булып санала, чөнки сүзнең нигезе тәрҗемәдә бирелми, бары тик кушымчалар гына тәрҗемә ителә.

“Лебедь” шигыреннән *“Но будто некая **цевница**, // с небес раздамся в голосах”* [1: 304] юллары, тәрҗемәдә*“**тылсымлы көй** булдып яңгырармын // Киек казның энҗе юлыннан”* [2: 122] дип бирелгән. Цевница – тынлы милли музыка коралы. Кабул итүне җиңеләйтү максатыннан, тәрҗемәдә бу төшенчә логик аңлашылган сүзтезмә белән алыштырыла. Биредә без тәрҗемәнең модуляцияләү ысулын күрәбез. Бу очракта тәрҗемә телендә төп нөсхә берәмлегенең эквиваленты бирелми, әлеге берәмлек мәгънәсе логик аңлашылган төшенчә белән алыштырыла.

Тәрҗемә телендә тәңгәллек булмаган очракта, тәрҗемәче өчен антонимик тәрҗемә ысулын куллана белү мөһим. Әмма антонимик тәрҗемә кайвакыт турыдан-туры тәрҗемә итү мөмкинлеге булганда да кулланыла ала. *“**Но нет пустынь таких**, ни дебрей мрачных, дальных, // Куда любовь моя в мечтах моих печальных // **Не приходила бы беседовать** со мной”* [1: 343] – *“**Ләкин кайда да табыла урын** - // сөеклем минем, минем күз нурым // **сөйләшә минем белән** хыялда”* [2: 84]. Төп нөсхәдә лексик мәгънә инкарь формасында килгән, ләкин тәрҗемәдә әлеге берәмлекләр раслау формасында бирелә. Бу очракта

тәрҗемәче стилистик күзаллауларына таяна, чөнки тәрҗемәдә текстның “табигый” яңгыравы зур әһәмияткә ия.

Рус әдәбиятының шундый күренекле әсәрләрен татар укучыларына җиткерү – тәрҗемәче өчен бик җаваплы һәм мактаулы эш. Монда, бер яктан, гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле әсәрләрнең тәрҗемәсен чагылдыра алган татар теленең көче, сүз байлыгы зур әһәмияткә ия, икенче яктан, тәрҗемәченең дә осталыгы ачык чагыла.

**Әдәбият**

1. Державин Г.Р. Стихотворения [Вступительная статья, подготовка и общая редакция Д.Д. Благого, примечания В.А. Западова]. – Ленинград: Советский писатель, 1957. – 469 с.

2. Державин Г.Р. Кизләү: Одалар, шигырьләр / Г.Р. Державин [русчадан Ренат Харис тәрҗ.]. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016. – 159 б.

## ЧУВАШ ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНЕҢ РУХИ МӘДӘНИЯТЕ ЛЕКСИКАСЫ

*Миннубаева Ф., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Саттарова М.Р.*

Соңгы дистә елларда чуваш һәм татар галимнәре тарафыннан озак вакыт дәвамында чувашлар һәм татарлар, аларның матди һәм рухи мәдәниятенә үзара мәдәни йогынты ясаулары турында эзләнүләр алып барыла. Безнең тикшерүнең максаты – бу телләрнең уртак һәм аермалы якларын табу, лексик яктан рухи мәдәнияттагы охшашлыкларны эзләү.

Рухи мәдәният кешеләр эшчәнлегенең нәтиҗәсе, тик куллар белән ясалган түгел, ә акыл белән. Кагыйдә буларак, аңа идеология, әхлак, рухи аралашу, сәнгать иҗаты һәм дин керә. Рухи мәдәният матди эшчәнлекнең идеаль ягы буларак үсә.

Беренче чиратта, безне бу телләрнең рухи мәдәниятнең бер тармагы булган – мифологиясе җәлеп итте. Бездәге Шүрәле, Су анасы, өй ияләре чуваш халкында бармы? Булса аларны ничек атыйлар? Төс-кыяфәткә алар безнекеләр кебекме? Шушы сорауларга җавап табар өчен ике халыкның да кайбер мифологик затларын карап китәргә булдык.

Татар мифологиясенең бер өлешен көндәлек тормыш белән бәйләнгән персонажлар хакындагы хикәятләр тәшкил итә. Әлеге хезмәттә аеруча характерлы персонажларга кыскача гына тукталып үтү белән чикләнәбез. Шундыйлардан беренче урында бездә киң таралган Шүрәле тора.

Шүрәле – татар һәм гомум төрки мифологиясе персонажы, урманда яши торган, күбесенчә явыз рух. Татар әдәбиятында ул Габдулла Тукайның «Шүрәле» поэмасы аша киң билгеле. Ул йонлач тәнле, маңгаенда мөгезе булган, кул бармаклары бик озын, ир кеше кыяфәтендәге урман заты. Озын бармаклары белән ул кешеләрне

кытыкларга ярата, әгәр кеше берәр хәйлә юлы белән котыла алмаса, кытыкланып, көлүдән үләргә дә мөмкин.

Чуваш мифологиясендә Арзури (безнеңчә Шүрәле) урман байлыкларын, җәнлекләрне һәм кошларны саклаучы. Мәсәлән, ул крестьянның йортына кадәр кайтканын саклап бара, аның белмәсендә утын кисәргә җыенган, кешене исеме белән чакыра, авыру җибәрә, янгын чакыра. Ул урманда яши икән, авылда барлыкка килми, чөнки этләрдән курка, аны явыз урман Рухы дип саныйлар. Башкача, ул урман хуҗасы дип атала, ул урманны саклый һәм еш кына ябалак булып кычкыра ала. Аның икенче исеме дә очрый – Казан һәм Көнбатыш Себер татарларының Урман иясе (урман хуҗасы) белән охшаш Варман турасы (урман хуҗасы). Чувашлар аудагы уңыш, тормыш иминлеге аның белән бәйле дип уйлаган.

Аерым гына мифологиясен алсак, лексик атамалары төрле, ә мәгънәләре охшаш яки бер үк булуын ачыкладык.

Су анасын без шулай ук Тукай әкиятләре аша истә калдырдык. Бу зат безнең күзалдында куркыныч, озын ак чәчле, алтын тараклы яше билгесез ханым. Ул су астында яши, бары чәчләрен тарар өчен генә ярга чыга. Шул вакытта ул кешеләр белән бәйләнешкә керергә мөмкин. Тик Су анасына зыян салмавың хәерле. Ул җир иясе түгел, шуңа күрә гайре табигый көчкә ия булырга мөмкин.

Чуваш мифологиясендә Су анасы Вудаш белән тәңгәл. Ул яртылаш кеше, яртылаш балык булып санала. Тормышлары гади кешеләрнеке кебек, аларның гаиләләре дә бар, ләкин су астында яшиләр. Төшке аштан соңгы вакытта кешеләргә суда коенырга ярамый, чөнки бу вакытта Вудашлар коена, кояшлы көннәрдә алар ярга чыгып, матур кыз кыяфәтенә керәләр, озын кара чәчләрен алтын тарак белән тарыйлар. Кешеләргә Вудашларны күрергә ярамый, күргән очракта алар су төбенә алып төшеп китәләр. Әгәр Вудаш үзен күргән егеткә гашыйк булса, сөйгәненә җиргә акча ташый дигән сүзләр дә йөри.

Абзар иясе – ишегалдында яки сулыкта яшәүче рух. Төннәрен абзар кеше яки берәр хайван кыяфәтендә күренә. Кайбер йорт хайваннарын ул ярата һәм ашата, ә башкаларны – эзәрлекли. Абзар иясе еш кына өй иясе белән охшатыла.

Албастылар – төрки һәм күрше халыкларда куркыныч хатын- кыз образы. Албасты – рус “ведьма”сының татардагы тиңдәше. Гадәттә, аны озын чәчле, өч күзле һәм куркыныч тырнаклы ямьсез хатын-кыз рәвешендә тәкъдим итәләр. Албасты кечкенә балаларны яратмый. Ул балаларның үзләре генә калуын көтеп тора, аларны имезә һәм ахырда бала үлә. Чуваш халкында да бу мифик образ бар.

Бичура – татар әкиятләренең һәм мифларының, өйдәге мифик

җанлылыгы. Ул кечкенә буйлы, башына өрпәк бәйләп йөрүче түбән зат, мунчаларда яисә өй базларында яши дип уйланылган.

Дию пәрие – татар мифологиясендә иң түбән рухларның берсе. Алар җир асты киңлекләрендә яки диңгез төбендә яши. Алар бик оялчан: кешеләр арасында бик күренеп йөрмиләр. Бары тик иң кыюлары гына мәхәббәт хакына кеше кыяфәтен кабул итә: өйләнәләр яки кияүгә чыгалар. Бу образны чуваш халкында очратмадык.

Болардан кала татарда да, чувашта да күп төрле мифологик җан ияләре бар. Чуваш теленең мифологик затларына Албасты, Әрҗери, Вубар, Вите Хуси, Вудаш, Ийе, Ирих, Келе, Эсрель, Хәрле щыр кебек атамаларны кертеп карап була. Ә татарда тагын Иблис, Җен, Пәри, Шайтан кебек популяр мифологик затлар бар. Аларның байтагы безгә ислам, нигездә Коръән мифологиясе аша кергән. Димәк, аларны ислам мифологиясе белән бәйләп өйрәнү зарур.

Шулай итеп, татар һәм чуваш халыкларында мифологик затларның төрле лексик берәмлекләр белән аталса да, эчтәлеге ягыннан уртаклыклар булуы аларның кардәшлеге, ә бәлки территориаль яктан бер җирлектә яшәү белән бәйле булырга мөмкин дигән фикергә килдек.

**Әдәбият**

1. Денисов П. В. Религиозные верования чуваш (историко-этнографические очерки). – Чебоксары: Чувашское государственное издательство, 1959. – 408 с.

2. Нурмухаметова Р.С. Лексика материальной и духовной культуры татарского языка// Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. – № 1 (23). – Казань, 2011. – С. 165-169.

3. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2002. – 335 б.

## ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУДА ИНТЕРАКТИВ МЕТОДЛАР КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Мифтахова Э., М. Акмулла ис.БДПУ, III курс студенты*

*Фән.җит. – филол. фән. канд., доц. Халиуллина А.Г.*

Татар теле укыту методикасы, мәгариф өлкәсендәге үзгәрешләргә, үсеп килүче буынның психологик үзенчәлекләренә, гомумән, бөтендөнья күләмендә бара торган үзгәрешләр (глобальләшү, мәгълүматлаштырылу, интегральләшү һәм башкалар) белән бәйле рәвештә яңа эзләнүләр, тикшеренүләрне таләп итә. Нәтиҗәдә үткәндәге иң күркәм методик традицияләр, хәзерге заман шартларына яраклаштырылып, яңа методик үзенчәлекләр белән гармоник кушылып, укытучы тарафыннан кулланырга тиеш була. Шундый методик традицияләрнең берсе – укытуның интерактив методлары [4: 64].

1) Беренчедән, интерактив методлар һәм дәрес белән кызыксыну арасында тыгыз бәйләнеш бар, чөнки интерактив методларның резервлары уникаль, бай, төрле. Интерактив методлар эшчәнлек төрен

алыштыру да, эмоциональ күтәренкелек тә, колоритлы образлылык та, ассоциативлык та, аңлаешлылык, гадилек тә. Интерактив укытуның уңышлы булуы шунда: мондый методлар укучыларны битараф калдырмый, башка сүзләр белән әйткәндә, аларда кызыксыну тудыра [1: 22]. Билгеле булганча, кызыксынусыз үзләштерелгән белемнәр, кешенең актив казанышына әйләнми, ә куллануга яраксыз йөк булып тора.

2) Икенчедән, татар теле дәресләрендә интерактив методлар методик, психологик, физиологик һәм яшь үзенчәлекләре ноктасыннан кирәкле материал. Интерактив методларны дәресләрдә, укучылар белән индивидуаль эштә, бердәм дәүләт имтиханнарына әзерлек вакытында, сәләтле балалар белән эштә кулланырга мөмкин.

3) Өченчедән, интерактив методлар балаларда кызыксыну тудырырга гына сәләтле түгел, ә яңа материалны үзенең «дөрес булмаган», «фәнни булмаган», гадиләштерелгән ысуллары белән тәкъдим итүе белән, ирексездән укучыларны кагыйдәнең, теманың асылын аңлауга китерә, һәм моның нәтиҗәсе буларак, аны гамәлдә куллануны җиңеләйтә.

Гамәлдәге татар теле дәреслекләрендә урын алган интерактив методларның кулланылышы уңай бәяләнүгә лаек, шулай ук безнең үзебездә дә кайбер тәкъдимнәр туды. Билгеле булганча, коронавирус эпидемиясе таралу сәбәпле белем бирү йортлары, шул исәптән мәктәпләр дистант укуга күчәргә мәҗбүр булды. Пандемия шартлары мондый укытуның уңышлы якларын да, төзәтелергә тиешле кимчелекләрен дә күрсәтте. Тулаем дистант укыту булмаган, материалның бер өлеше оффлайн форматта, бер өлеше онлайн-форматта укытылуга нигезләнгән «Әйләнгән класс» (русча атамасы перевернутый класс) моделе буенча эшләү алымнары гамәлгә кертелә башлады [2: 7]. Татар теле дәресләрендә мондый модель әлегәчә киң таралыш тапмый, әмма әзер электрон белем бирү ресурслары, видеодәресләр булган очракта, укытучы бу өлкәдә дә тәҗрибә туплый ала. Шунысы да бар, видеодәрес – интерактив методларның берсе [5: 132]. Хәзерге вакытта «YouTube» кебек платформаларда «Исем» сүз төркеменә караган берничә минутлык (күбрәк – бер-ике минут) видеодәресләр бар. Аларны укучыларга тәкъдим итү үзен аклый. Әмма мондый дәресләрнең уңай яклары булган кебек, тискәре яклары да бар. Уңай якларга тукталыйк. Видеодәресләр кыска, кайбер очракта алар анимация рәвешендә корылган, дәресне уйлап чыгарылган персонаж, мәсәлән, *Алия алып бара.*

Видеодәресләрдә төп мәгълүмат кыска рәвештә атала, матур итеп бизәлү бәрабәренә ул укучыларның күңеленә кереп кала.

Әмма әйтелгән үзенчәлекләр шушы ук вакытта кимчелекләр дә булып тора. Мондый дәресләр тема буенча төпле, төрле яклы мәгълүмат бирми, күнекмәләр формалаштырмый, бары тема белән танышу яисә үткәннәрне искә төшерү функциясен генә башкаралар. Әмма дистант укытуда да укучы видеодәресләрне пассив тыңлаучы булырга тиеш түгел. Тема буенча биремнәр башкарылырга тиеш. Без «Исем» темасын өйрәнүдә видеодәрескә сылтама бирү белән чикләнмәскә, өстәмә биремнәр дә тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Видеодәресләрдән тыш, укытучылар тарафыннан төзелгән уен-бирем китерергә дә була. Замана балалары телефон, смартфоннан еш файдаланалар. Бу үзенчәлекне уенда да файдаланырга була. Укытучы укучыларга сыйныфташларының берничә предметын фотога төшерергә тәкъдим итә. Әгәр бу предмет күзгә күренеп тормаса, уен кызыграк, нәтиҗәлерәк үтәчәк.

Шул рәвешле уен дәреслектә бирелгән материалны кызыклырак рәвештә тәкъдим итә. Нәтиҗәдә укучылар бирелгән теманы тиз үзләштерәләр һәм белемнәрен гамәлдә файдаланып карыйлар [3: 121].

Дәреслектәге эш өстәмә биремнәр белән үрелеп барганда гына, уңышка ирешеп була. Бу очракта укучыларны яңа эш алымнары белән җәлеп итү мөмкинлеге дә ачыла. Укытучылар тарафыннан тәкъдим ителгән һәм дәреслекләрдә урын алмаган видеодәрес үрнәге, смартфоннар белән уен кебек интерактив методлар шундыйлар рәтеннән.

Интерактив методларны һәм алымнарны куллану укучыларның интеллектуаль активлыгын һәм дәресләрнең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә. Интерактив алымнар һәм укыту алымнары белемнең ныклыгын, иҗат һәм фантазиясен, команда рухын, үз-үзеңне күрсәтү иреген һәм уку процессында катнашучыларга бер-береңне хөрмәт итүне тәэмин итә.

**Литература**

1. Агеева И.А., Лысенкова И.А., Борченко Е.С. Интерактивные методы, формы и средства обучения. – Бишкек: КРСУ, 2017. – 84 с.

2. Арустамян Д.В., Дроздова Е.А. Использование интерактивных методов обучения в учебном процессе // Евразийский союз ученых. – 2018. – № 7-4(52). – С. 7-8.

3. Блинов А.О., Благирева Е.Н. Интерактивные методы в образовательном процессе: учебное пособие. – М.: ИД «Научная библиотека», 2014. – 150 с.

4. Ибрагимова Е.М. О формах и методах интерактивного обучения в высшей школе // Дидактика профессиональной школы. – Казань: Институт педагогики и психологии профессионального образования, 2013. – С. 62-68.

5. Малыхин С.А. Преимущества и недостатки видеоуроков в образовательном процессе школы//Проблемы технологического образования в школе и вузе: сборник статей по вопросам технологического образования/Под редакцией З.А. Литовой.–Курск: Курский государственный университет, 2010. – С. 131-134.

# ОСОБЕННОСТИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ФОЛЬКЛОРНОГО МАТЕРИАЛА НА УРОКАХ РУССКОГО ЯЗЫКА В НАЧАЛЬНОЙ ШКОЛЕ

*Молдук Н., ТюмГУ, студент III курса*

*Науч. рук. – док. филол. наук, проф. Файзуллина Г.Ч.*

На современном этапе развития общества с каждым годом стремительно возрастают требования к системе образования. Основными задачами школы на сегодняшний день являются обеспечение обучающихся необходимыми научными знаниями, практическими умениями и навыками, а также помощь в осмыслении накопленных общественных ценностей и традиций. В связи с этим становится актуальной проблема приобщения учащихся к культурным ценностям своего народа в процессе получения знаний.

Важным направлением современной методики обучения и воспитания является культуроведческий аспект, «представляющий собой совокупность теоретических положений, практических наработок, экспериментальных исследований, позволяющих учителю приобщить учащихся к культуре народа, помочь им воспринять, эмоционально пережить и присвоить базовые ценности национального и общечеловеческого характера» [2].

Реализация такого аспекта возможна путем использования на уроках русского языка устного народного творчества. В широком смысле фольклор – это духовная культура того или иного народа, представленная в форме словесных текстов, музыки, народного театра, декоративно-прикладного творчества [5].

В период обучения в начальной школе уместно использование такого вида устного народного творчества, как детский фольклор. По функции все произведения детского фольклора можно разделить на две группы:

1) произведения, связанные с игровыми действиями (жеребьевки, считалки, игровые приговорки и припевки);

2) произведения, которые занимают детей своим словесным содержанием и исполняются независимо от игровых действий (песни, прибаутки, небылицы, скороговорки, частоговорки).

Кроме того возможна классификация фольклорных жанров в зависимости от объема произведения: 1) большие фольклорные жанры (сказки, былины, легенды, народный театр, исторические песни); 2) малые фольклорные жанры (пословицы, поговорки, загадки, частушки, скороговорки, чистоговорки, частоговорки).

Фольклор является представлением величайшей ценности литературного языка, отображением культурного наследия нашей Родины. Устное народное творчество придает литературному языку точность, выразительность [1].

Современная методика обучения постоянно развивается: появляются новые формы уроков, методы и приемы обучения, которые привлекают учащихся своим содержанием, формой проведения, способствуют формированию мотивации учения и более прочному закреплению знаний. На сегодняшний день – это коллективно-творческие дела, проблемное обучение, кейс-метод, игровые технологии и др.

Особенностью заданий, с применением образцов устного народного творчества, является их универсальность. Например, возможно использование детского фольклора на уроке-путешествии (закрепления знаний), в ходе которого дети в формате групповой работы, путешествуя по стране «Орфография», выполняют задания на повторение орфографических правил, работая с различными произведениями устного народного творчества. Нами было подготовлено несколько заданий для проведения урока русского языка в данном формате. Задания составлены для 3 класса в соответствии с образовательной программой «Перспектива» по учебнику «Русский язык. 3 класс. Часть 1» под редакцией Л.Ф. Климановой, Т.В. Бабушкиной по теме «Девять правил орфографии» (урок рефлексии) [3].

*Задание 1. Прочитайте предложения. Вспомните правило «Прописная буква в именах собственных» и выберите из скобок нужную букву. (В предложенном задании учащиеся работают с фрагментом сказки «Иван-царевич и серый волк»). Жил-был царь Б(б)ерендей у него было три сына, младшего звали И(и)ваном. И был у Ц(ц)аря сад великолепный; росла в том саду Я(я)блоня с золотыми Я(я)блоками [4].*

*Задание 2. Прочитайте пословицы. Исправьте ошибки, опираясь на правило «Проверяемые парные по звонкости-глухости согласные в корне слова». Друк познается в беде. Без труда не вынешь и рыпку из пруда. Семь рас отмерь, один отрежь. Где трут там и радость [4].*

*Задание 3. Прочитайте загадки. Отгадайте их. Заполните пропуски, объясняя написание правилом «Правописание буквосочетаний жи-щи, ча-ща, чу-щу. чк, чн. нч, щн, рщ». Ползун ползёт, Иголоч_ки несёт (ёж_к). Не ш_т, не кроен, А на ниточ_ке сборен (ч_лок). Словно белые пуш_нки С неба падают ... (снеж_нки) [4].*

Предложенные задания можно представить как в печатном формате, так и в формате мультимедийной презентации для одновременного выполнения всеми группами. Преимуществом современных уроков с использованием образцов устного народного творчества является то, что ближе знакомятся с устным народным творчеством, что формирует их познавательный интерес к изучению

родной культуры, народных традиций, происходит формирование патриотических чувств.

Таким образом, мы предполагаем, что в результате активного использования произведений устного народного творчества на уроках русского языка в начальной школе с использованием современных приемов и методов обучения у учащихся увеличатся воспитательные и познавательные возможности, расширится кругозор, а также ребенок приобщится к культурным ценностям своего народа в процессе получения знаний.

**Литература**


1. Белоусова А.Н. Использование устного народного творчества на уроках русского языка. – М., 2011. – 5 с. [Электронный ресурс]. URL: https://clck.ru/dYfvg, (дата обращения: 24.01.2022)

2. Новикова Л.И. Культуроведческий аспект обучения русскому языку в 5-9-х классах как средство постижения учащимися национальной культуры: Дис. д-ра пед. наук. – М., 2005. – 515 с.

3. Русский язык. 3 класс. Учеб. для общеобразоват. организаций с прил. на электрон. носителе. В 2 ч. Ч. 1/ Л.Ф. Климанова, Т.В. Бабушкина: Рос. акад. наук. Рос. акад. образования, изд-во «Просвещение». – М.: Просвещение, 2014. – С. 39.

3. Сборник произведений устного народного творчества: для детей мл. шк. возраста // сост. Е. Р. Абражей, Ф. В. Сушко. – Минск: Беларусь, 2014. – 223 с.

4.Фольклор. Культура РФ. [Электронный ресурс]. URL: www.culture.ru/s/slovo-dnya/folklor/ (дата обращения 24.01.2022).


## ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕН АКТИВЛАШТЫРУ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР


*Мөбәрәкшина З., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кузьмина Х.Х.*


Фразеологизмнар сөйләмне җанландырып җибәрүдә шактый зур роль уйный. Шуңа күрә әлеге теманы өйрәткәндә, аңа шактый җитди карау таләп ителә. Әмма методистлар фикеренчә, тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәтүдә хәл ителәсе мәсьәләләр кала бирә. Аларның сәбәпләре (мәгънәсен аңламаганлыктан, фразеологизмнарны урынсыз куллану; тотрыклы сүзтезмәләргә башка сүзләр кыстыру; фразеологизмнарны дөрес булмаган стильләрдә файдалану) төрле була ала. Тема аңлатылганнан соң, ул күнегүләр системасы ярдәмендә ныгытыла. Димәк, мәктәп дәреслекләрендә тәкъдим ителгән күнегүләр дә теләсә нинди теманы, шул исәптән, фразеологизмнарны өйрәнүдә дә зур әһәмияткә ия. Шуңа бәйле рәвештә, без хәзерге вакытта гамәлдә булган мәктәп дәреслекләрендә «Фразеологизмнар» темасын өйрәтүгә юнәлтелгән күнегүләр системасына анализ ясадык.

М.М. Шәкүрова һәм Л.М. Гыйниятуллиналар авторлыгындагы “Туган (татар) телдә төп гомуми белем бирү оешмаларының 5-9 сыйныфлары өчен “Туган (татар) тел” предметыннан үрнәк

программа” [2] буенча фразеологизмнар 5 сыйныфта өйрәнелә. Мәктәп программасы буенча, укучы сөйләмдәге фразеологизмнарны танырга, аларның мәгънәләрен ачыкларга өйрәнә [2: 32]. 5 сыйныф укучыларында фразеологизмнарның мәгънәләрен ачыклый белү, аларны сөйләмдә дөрес итеп куллана белү күнекмәләре формалаштырыла. Шулай ук бала фразеологик сүзлекләр белән дә эш итү серләренә төшенә.

Дәресләрдә фразеологик сүзлекләр куллануга тулырак тукталыйк. Бүгенге көндә сүзлекләр гаять әһәмиятле һәм кыйммәтле истәлекләрдән санала. Сүзлек – ул сүзләр исемлеге. Анда сүзләргә аңлатма бирелә, мәгънәләре ачыклана, әлеге сүзләрнең нинди предмет яки күренешләрне белдерүләре аңлатыла, сүзләрнең әйтелешенә, язылышына, килеп чыгышына һ. б. басым ясала. Укучы “фразеологизм” төшенчәсенең билгеләмәсе белән таныша; фразеологизмнарның сөйләмдә ни дәрәҗәдә кулланылуына төшенә; фразеологик сүзлек белән таныша; әдәби әсәрләрдә кулланылган фразеологизмнарның язучының үткен коралы булуына инана. Дәресләрдә фразеологик сүзлекләргә мөрәҗәгать итү укучының сөйләмен үстерүдә дә шактый зур роль уйный.

Р.Х. Мирзаһитов, М.М Шәкүрова, Н.Х. Мусаяпова авторлыгында рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының 9 сыйныф укучылары өчен каралган “Татар теле” (2015) дәреслегендә фразеологизмнар темасын ныгыту өчен берничә күнегү бирелүен күрдек. Ул “5-9 сыйныфта үткәннәрне кабатлау” бүлегенең “Лексикология” бүлекчәсе эчендә тәкъдим ителә. 205 нче күнегүнең биреме түбәндәгечә: “*Фразеологизмнарны татар теленнән – рус теленә, рус теленнән татар теленә тәрҗемәсен табыгыз*” [1: 173]. Күреп торуыбызча, әлеге күнегүне дөрес итеп башкару өчен, укучы рус телен дә, татар телен дә камил белергә тиеш. Рус мәктәбендә укучы татар баласы рус һәм татар телләрен чагыштырма планда өйрәнсә, отышлы санала.

Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К. Һадиева һәм Г.В. Һадиевалар тарафыннан төзелгән, татар телен туган тел буларак өйрәнүче 5 сыйныф укучылары өчен каралган “Татар теле” дәреслегенә тукталыйк. 270 күнегүнең биреме түбәндәгечә: “*Фразеологизмнарны укы, мәгънәләрен табып әйт. Аларны кайчан кулланалар?*” [3: 118]. Без югарыда анализлаган дәреслекләрдә мондый биремле күнегүләр очрамады. Әлеге күнегүнең биремендәге түбәндәге сорау укучыларны уйланырга мәҗбүр итә: “*Аларны кайчан кулланалар?*”.

Чираттагы күнегү: “*Бирелгән фразеологизмнарның капма-каршы мәгънәдә булуын дәлиллә. Бирелгән рәсем кайсы сүзтезмәгә туры килә?*” [3: 118]. Әлеге күнегү шактый үзенчәлекле булуы белән

аерылып тора, чөнки биредә уңай һәм тискәре мәгънәгә ия булган фразеологизмнар тәкъдим ителә. Димәк, укучы фразеологизмнарны чагыштырма планда өйрәнә дигән сүз. Тагын бер яңалык шунда: анда бердәнбер рәсем бирелә, укучылар әлеге рәсемнең кайсы фразеологизм эчтәлегенә туры килүен ачыкларга тиеш була. Ягъни әлеге бирем логик фикер йөртү сәләтен дә үстерә дип әйтергә мөмкин. Укучы фразеологизмнар белән җөмләләр дә төзеп язарга тиеш була.

Әлеге дәреслекнең соңгы өлешендә "Фразеологизмнар сүзлекчәсе" тәкъдим ителә. Бу – уку әсбабының отышлы һәм уңышлы ягы. Моңа кадәр анализлаган дәреслекләрдә без мондый сүзлекчәләр очратмадык. Әлеге сүзлекчә укучыга "Фразеологизмнар" темасын гына түгел, башка темаларны үзләштергәндә дә, иншалар, изложениеләр язганда да, иҗади биремнәр башкарганда да ярдәмгә килә ала.

Шулай итеп, без гамәлдә булган татар теле дәреслекләрендә "Фразеологизмнар" темасын өйрәнгәндә нинди күнегүләр кулланылуына анализ ясадык. Гомумән алганда, дәреслекләрдә әлеге теманы үзләштерүгә юнәлтелгән күнегүләр системасы шактый бай һәм үзенчәлекле. Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К. Һадиева һәм Г.В. Һадиевалар тарафыннан төзелгән, татар телен туган тел буларак өйрәнүче 5 сыйныф укучылары өчен каралган "Татар теле" дәреслегенә фразеологизмнар белән бәйле күнегүләрнең шактый күп кертелүен күрдек. Шунысын да искәртергә кирәк: фразеологизмнар темасын ачу максаты белән әлеге дәреслектә тәкъдим ителгән күнегүләр бик үзенчәлекле. Без мондый төр күнегүләрне башка дәреслекләрдә очратмадык. Бу – дәреслекнең отышлы ягы булып тора.

**Литература**

1. Мирзаһитов Р.Х., Шәкүрова М.М., Мусаяпова Н.Х. Татар теле. 9 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 190 б.

2. Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М. Туган (татар) телдә төп гомуми белем бирү оешмаларының 5-9 сыйныфлары өчен "Туган (татар) тел" предметыннан үрнәк программа. – Казан: 2020. – 78 б.

3. Шәмсетдинова Р.Р., Һадиева Г.К., Һадиева Г.В. Татар теле: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар) 5 с-ф. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2017. – 175 б.

## ИНТЕРНЕТ ЧЕЛТӘРЛӘРНЕҢ ТЕЛГӘ ЙОГЫНТЫСЫ

*Муртазина Э., М. Акмулла ис. БДПУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Хәлиуллина А.Г.*

Хәзерге заман тенденцияләренең берсе булып заманча технологияләрне, «цифрлы коммуникация»не үстерү тора. Кыска вакыт эчендә интернет безнең тормышыбызга тирән үтеп керде, кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләрен диярлек яулап алды. Хәзерге дөньяда

ул профессионал тармакка гына түгел, ә кешенең аралашу даирәсен оештыруга, соңгы вакытта исә уку-укыту өлкәсенә, һөнәри хезмәтне читтән торып башкару мөмкин булган очракларда, төрле оешма, фирмаларның эшен оештыру төренә дә әйләнде. «Цифрлы коммуникация» яки «цифрлы аралашу» термины дигәндә – СМС, «Твиттер», «WhatsApp» һ.б. шуның кебек виртуаль каналлар аша аралашу аңлашыла.

Рәсми мәгълүмәтләргә караганда, 2020 елдан 2021 елга кадәр Россия Федерациясендә интернет кулланучылар саны 6 млн га арткан (5,1%), ә интернетның үтеп керү дәрәҗәсе 85% тәшкил итә. Статистика буенча кешеләр уртача көн саен 7 сәгать 52 минут интернетта үткәрә [3].

Шушы исәптән сүзлекнең табигый чагылышлары белән беррәттән, заманча мәгълүмат җәмгыятен аңлау өчен хас булган яңа сүзләр барлыкка килүгә һәм таралуга ярдәм итә торган шартлар формалаша. Бу шартларга, иң беренчедән, глобализация кебек процессны кертергә мөмкин. Глобализация хәзерге заман җәмгыятенең барлык өлкәләренә – сәясәтчеләргә, икътисадка, мәдәнияткә һәм сәнгатькә, социаль тормышка, массакүләм мәгълүмат чараларына, фәнгә кагылган каршылыклы процесс [1]. Тулысынчарак әйткәндә, глобализация дигәндә без җәмгыятьнең стандартлаштырылган ихтыяҗлары һәм аларны канәгатьләндерү ысуллары булган яңа тибына, иҗтимагый эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә даими рәвештә төрле үзгәрешләргә җайлаша торган яңа типка күчүне билгелибез. Бу процессның бер чагылышы итеп сөйләмдә чит телдән кергән сүзләрне куллануны әйтергә мөмкин. Сүзләрне үзләштерү бер халыкның мәдәниятенең икенчесенең мәдәниятенә, сүздә куллануның социаль үзенчәлекләренә, туган телдә алынма сүз эквиваленты яки төшенчәнең юклыгына бәйле. Күп очракта алар әлегә кадәр татар сүзлегендә булмаган төшенчәләрне билгеләргә алынган – яңа технологияләр, телефон, компьютер, ялган интеллект, интернет челтәрләрдә кулланган терминнар өчен. Мондый очракта алынма сүз әлеге төшенчә өчен «бердәнбер» булырга мөмкин. Мәсәлән, *байт, браузер, файл, ноутбук, саммит, допинг, скетч, бампер, катер* һ.б. Алга таба бу сүзләрнең кайберләрендә синонимнар (*скетч* [англ. sketch] – каралама, кечкенә пьеса; *катер* [англ. cutter] – зур булмаган судно) барлыкка килергә мөмкин.

Бу җәмгыять тормышындагы кардиналь үзгәрешләрләргә бар өлкәдәге кешеләр дә, бигрәк тә яшь буын, дучар. Мәктәп укучылары һәм студентлар даирәсендә, массакүләм мәгълүмат чараларында, профессиональ һәм көнкүреш аралашуда, шулай ук сәяси даирәдә грамоталылык һәм сөйләм культурасының кискен кимүе күзәтелә. Билгеле булганча, тел – ул шәхесне формалаштыручы корал. Кеше

тумыштан ук гаиләсендә туган тел белән һәм аңа салынган, нәселләр буе килгән мәдәният белән тәрбияләнә. Тел кешелек дөньясы белән бергә үсә. В. Гумбольдт беренчеләрдән булып телнең җәмгыятьтә генә формалаша алуын билгели [2: 356]. Ләкин соңгы елларда туган телнең кыйммәте кимүе күзәтелә. Әгәр дә безнең әби-бабаларыбыз катлаулы текстлар төзеп, хат аша аралашкан булсалар, кичләрен оныкларына әкиятләр сөйләп, җырлар җырлап туган тел матурлыгын, халык акылын, милли фикерләү үзенчәлеген яшь буынга тапшырырга омтылсалар, хәзерге буын яшьләре үз тормышын кыска язышулар, хәбәр алышулар белән мөмкин кадәр тизләтә, гадиләштерә. Интернетның телгә нинди үзгәреш керткәнен без яңа технологияләрнең йогынтысыннан күрә алабыз. Чит илдән килгән барлык технологияләр, инновацияләр өчен безнең илдә яңа сүзләр эзләнми. Рус белгечләре оригиналь атамалар куллана. Һәм күп кенә чит сүзләр безнең татар телебезгә дә рус теле аша үтеп керә. Бу халыклар арасындагы сәүдә, фәнни, мәдәни элемтәләр өчен кирәкле тел үсеше процессы белән аңлатыла.

Шушы тел өчен һәлакәтле процессларга карамастан, без заман белән бергә атлауны дәвам итәбез һәм җәмгыятьтәге барлык мөмкинлекләрне кулланырга тырышабыз. Мәсәлән, татар теленең интернет челтәрендә кулланылышы мәсьәләсен тикшерү барышында Татнетны үстерү фонды тарафыннан 2010 елдан оештырылып килгән «Белем җәүһәрләре» Дөньякүләм интернет-проектлар бәйгесе мәгълүмәтләренә нигезләнергә мөмкин. «Белем җәүһәрләре» бәйгесенең максаты итеп интернет челтәрләрдә фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә җәүһәр дип саналырлык татар телендә ясалган интернет-ресурсларны эзләп табу һәм аларны популярлаштыру билгеләнә.

Җиңүчеләр исемлегендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының шәхси сайтлары, газета-журналлар, иҗтимагый оешмалар, язучылар иҗатына багышланган интернет чаралары да бар. Күпчелек язмалар әдәби телдә бирелә, рәсми стиль кануннарын саклап язылганнары да байтак. Алар, билгеле, татар телен үстерүгә, халыкның рухи-мәдәни тормышын саклауга һәм баетуга үз өлешен кертәләр.

Шулай итеп, интернет аерым коммуникатив мохит буларак, кешеләр арасындагы аралашуның яңа ысулларын, сөйләм тәртибенең стереотипларын, тел яшәешенең яңа формаларын алып килә. Әммә зур тизлек белән алга барган җәмгыять шартларында яңа аралашу чаралары, ысуллары кулланмау мөмкин түгел, ләкин безгә үз телебезнең байлыгын, халкыбызның тарихын, холык-килбәтен киләсе буыннар өчен сакларга, туган телебездә аралаша белергә һичшиксез кирәк.

**Литература**

1. Большой словарь иностранных слов. [Электронный ресурс]. URL: https://gufo.me/dict/foreign_words (дата обращения 21.01.2022)
2. Гумбольдт В. Язык и философия культуры. – М.: Прогресс, 1985. – 379 с.
3. Интернет и соцсети в России в 2021 году – вся статистика. [Электронный ресурс]. URL: https://www.web-canape.ru/business/internet-i-socseti-v-rossii-v-2021-godu-vsya-statistika/ (дата обращения 06.02.2022)

## РОДНОЙ ЯЗЫК – МОЕ БОГАТСТВО

*Мухаметьянова Э., БГПУ им. М. Акмуллы, магистрант II курса*
*Науч. рук. – док. филол. наук, проф. Насипов И.С.*

В настоящее время стала очевидной необходимость духовного оздоровления человека, без чего Отечество не только не способно прогрессивно развиваться, но и исторически обречено. В социокультурной ситуации необходима система образования, которая, опираясь на национальные традиции народа, обеспечит высокие нравственные качества учащихся.

Обращение к глубинным корням национальной культуры – наш этический долг перед потомками, для которых мы должны бережно сохранять бесценное наследие прошлого, чтобы можно было его изучать и творчески развивать.

Педагогами школы накоплен богатый опыт воспитания достойных, добропорядочных людей. Самым надёжным стержнем учебно-воспитательного процесса должна быть идея воспитания учащихся на традициях и обычаях национальной культуры, на истории земли башкирской, судьбах наших земляков, прошлом и будущем нашей Родины.

Детям нужно открывать светлое и отрадное. Им нужны честность и мужество, чтобы укрепилась вера в человека, чтобы радовалось сердце на его величие. Воспитывать ребёнка в таком духе помогают традиции и обычаи его народа. Сначала мы стали разрабатывать тему, связанную с историей села. Встречались с аксакалами села, побеседовали, изучали архивные документы, книгу А. Салимова «На земле Дюртюлинской». С историей села поинтересовались жители близлежащих деревень, например, из Саитово Кушнаренковского района. Оказалось, их предки были выходцами из нашего села. Так появились первые исследовательские работы «История села», «Топонимика нашей местности», «Сегодняшнее, прошлое улицы Калинина».

Неоценимую роль в изучении истории села играет книга односельчанина, поэта и прозаика, автора 5 книг, подполковника в отставке, проживщего в Екатеринбурге Гани Зарифа. Собирали о его творчестве, о семье Зариповых богатый материал, который используется учителями в проведении классных часов и вечеров.

Ученики школы занимаются исследовательской работой по этно-культурному направлению, по сохранению и бережное отношение к традициям своего народа, с которыми не раз выступали на конференциях районного масштаба. Так и передаётся красота – из рук в руки, так хранится народное богатство, в этом сила нашей земли. Ведь от того, как мы относимся к родной старине, зависит, быть или не быть отечественной культуре.

Специфика уроков родного языка и литературы такова, что мы на уроках занимаемся больше воспитанием, чем обучением. Герои татарских народных сказок и легенд воплощали в себе возвышенную нравственную программу, которую народ стремился осуществить в процессе воспитания новых поколений. В интеграции физического и духовного развития личности такие сказки, как «Луна и Солнце», «Старик и ленивый джигит», «Батыр», «Камыр-батыр», «Четыре друга», «Козел и Баран», «Человек и Кошка», «Соловей» и др. являются бесценными.

Нельзя недооценивать роль пословиц в интеграции духовного развития личности. Через пословицы школьники получают первичные знания о здоровье, движении, природе и их взаимосвязи. В фольклоре русского народа пословица и поговорка трактуется так: «Поговорка – цветочек, а пословица – ягодка», а у татар: «Әйтем – сүзнең бизәге, мәкаль – сүзнең җиләге».

Воспитание и обучение существует в народе столько же веков, сколько существует сам народ. Каждый народ стремится донести в будущее, как метко сказал Г. Баширов, «свою самую яркую звезду», самое дорогое духовное богатство – веками накопленную мудрость. Родные слова, родные песни – это самые яркие звезды татарского народа, его самое дорогое духовное богатство. Красота слов, песен и игр создает интересную гармонию в татарской системе эстетического воспитания, представляющую собой вклад татарского народа в общечеловеческую эстетику и педагогику.

Большим подспорьем в деле нравственного воспитания служит народная педагогика. Такие качества, как гостеприимство, уважение к старшим, любовь к другим и родной земле, взаимопомощь, доброжелательное отношение к другим народам, трудолюбие татары считали определяющим в характере своего народа, своего рода нравственно-моральными устоями. Это отразилось в песнях и пословицах: «опирайся не на силу руки, а на доброе сердце», «Если будешь уважать старших, то будут и уважать и тебя». «Дитя пусть воспитывает тот, кто родил», – гласит народная мудрость. Роль семейного воспитания не может быть переоценена. Об этом говорит и

народное изречение: «Если уж молоко матери не пошло ему в прок, то коровье – и подавно» (“Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс”). Действительно, сейчас и во времена наших предков было и есть незыблемое правило: родители полностью отвечают за то, как воспитываются дети, кем они становятся в жизни. Народный воспитательный опыт исходит из того, что старшие должны быть примером и образцом для детей, только тогда они смогут стать хорошими людьми. Для детей родительский авторитет непререкаем. Пример родителей – самый мощный ориентир в поведении детей. Дети воспринимают и положительные и отрицательные черты отца и матери: «Куда переднее колесо, туда и заднее», «Родители трудолюбивы, и дети не ленивы». Воспитание любви к родному языку, народному творчеству, национальной культуре – дело сложное и важное. Именно уроки языка, литературы, внеклассная деятельность помогает найти пути для решения этой насущной задачи. Поэтому большое внимание в своей педагогической деятельности уделяю сохранению национальных традиций и духовно – нравственной культуры. И пусть каждый урок даёт детям лишь какую-то часть необходимой информации, постепенно складывается целостная картина. И если мы сохраним богатство традиций, культуры – то главным образом мы сохраним наш язык.

**Литература**

1. Бабанский Ю.К. Педагогика: Курс лекций. – М.: Просвещение, 1988. – 354 с.

2. Жалалиев Ш.Ш. Основы национального воспитания. На татарском языке. (Учебное пособие). – Казан: Магариф, 2003. – 150 стр.

3. Каримуллин А.К. Тел – милләтнең сакчысы. – Казан: Татар кит. нәшр., 1997. – 256 б.

4. Хаматгалиева Г. Халык педагогикасы – тәрбия чыганагы // Мәгариф. – 2004. – №12. –Б. 21.

## КОНЦЕПТЫ «ОСЕНЬ», «ВЕСНА» В УЗБЕКСКОЙ ЯЗЫКОВОЙ КАРТИНЕ МИРА

*Мухаммедова Б., БухГУ, магистрант I курса*

*Науч. рук. – ст. преп. Носиров О.Т.*

В современных узбекских словарях значения времен года имеют как сходства, так и различия: это наблюдается не только в отношении зимы лета, но и в оформлении дефиниций весны и осени. Так, например, в Ўзбек тилининг изоҳли луғати под редакцией Э.М. Маъруфова определение весны дано следующим образом: 1. «Тўрт фаслнинг биринчиси, қишдан кейинги, ёздан олдинги фасл; кўклам» 2. *кўчма* Ҳам нарсанинг, масалан, умрнинг, ҳаётнинг гулгун, яшнаган чоғлари ва шундай чоғлар рамзи [4: 91]. Данное определение акцентирует внимание на:

1) последовательности времен года (весна следует за зимой и предшествует лету); 2) на традиционно-историческом восприятии весны как первого среди сезонов (тўрт фаслнинг биринчиси). В отличие от принятого современного календарного порядка, словарь называет первым сезоном не зиму, а весну, т.е. празднования весеннего праздника встречи нового года – Навруза. Такой порядок следования времен года отразился в узбекском фольклоре в виде пословице **Йилнинг яхши келиши баҳордан маълум** – Наступающий год известен с весны. 3) на дополнительном, метафорическом значении весны в параллели со всеми лучшими аспектами человеческой жизни: молодости, и т.д.

Изданный в 2006-2008 годах, Ўзбек тилининг изоҳли луғати под редакцией Э.М. Мадвалиева [5:195-196], в отличие от ЎТИЛ 1981-го года, дает более широкую дефиницию весны, указывая не только названия календарных месяцев весны (март, апрель и май), но и большее, по сравнению с ЎТИЛ 1981, количество прямых и переносных значений. Кроме того, указано значение слова весна (Баҳор) как узбекского женского имени собственного: *1. «Йилдаги тўрт фаслнинг бири, қишдан кейинги, ёздан олдинги фасл; кўклам (йилниг март, апрель, май ойларига тўғри келади)». 2. Кўкламга мансуб, хос; яшил, ям-яшил. 3. кўчма Умрнинг маълум қисми, муддати, ёши. 4. кўчма Қувонч, шодлик, бахт. 5. кўчма Севги, муҳаббат; умид. 6. кўчма Севгили маъшуқа, гўзал ёр. 7. Баҳор (хотин-қизлар исми).*

Вынос в скобки названий календарных месяцев весны целесообразен, поскольку авторы стремятся наиболее точно отразить календарные характеристики сезона, в отличие от ЎТИЛ 1981, который подчеркивает, что весенние климатические особенности Узбекистана не совпадают с календарными весенними месяцами григорианского календаря в других климатических зонах, и других странах Евразии. Переносные значения, данные в словаре под редакцией Э.М. Мадвалиева [5: 195-196], дополняют переносные значения, данные в ЎТИЛ, 1981, усиливая акцентуацию на значении весны, как лучшего, наиболее яркого и радостного среди периодов человеческой жизни.

В обоих словарях при определении весны дано слово «кўклам» - синоним «баҳор». Словарь под редакцией Э.М. Мадвалиева дает следующее определение данному слову: **Йилнинг қиш билан ёз оралиғидаги фасли; баҳор** [5: 451]. Хотя в смысловом отношении формулировка определении совпадает (период времени года между зимой и летом), однако, в отличие от определения к «баҳор», в этом определении отсутствуют названия календарных месяцев и переносные

значения. Отметим, что синоним наблюдается в словаре только для слова баҳор, для осени, зимы и лета синонимы отсутствуют. Кўклам встречается в узбекском языке менее активно, в качестве более возвышенного, поэтического слова. Как, например, в заголовке репортажа Национального агентства новостей Узбекистана от 20.02.2013**:** «Андижонда **кўклам** нафаси». Слово использовано только в заголовке, в дальнейшем тексте использовано слово баҳор: ***Баҳор*** қуёшининг илиқ тафти сезилиб қолган шу кунларда барча жойларда бўлгани каби Андижон шаҳрида ҳам ободонлаштириш, кўкаламзорлаштириш ишлари тобора қизғин паллага кирмоқда.

В отличие от весны (а также лета и зимы), дефиниция осени в ЎТИЛ 2006 полностью совпадает с ЎТИЛ 1981-го года. Сравним: *1. Ёз билан қиш ўртасидаги фасл. 2. кўчма Даврнинг, мас. киши ҳаётининг умрнинг оҳирги дамлари [4:402]. 1. Ёз билан қиш ўртасидаги фасл. 2. кўчма Даврнинг, мас. киши ҳаётининг умрнинг оҳирги дамлари [5: 420].*

Акцентирование на перечислении названий осенних месяцев (т.е. сентябрь, октябрь, ноябрь), в ЎТИЛ 2007, в отличие от словарной статьи «весна» или «зима», отсутствует. Отметим также, тот факт, что уточнение в виде перечисления названий календарных месяцев, в словаре под редакцией Э.М. Мадвалиева присутствует только в дефинициях зимы и весны, но отсутствует для лета и осени, хотя целесообразнее было бы дать такое уточнение для каждого из времен года.

Таким образом, определение осени в ЎТИЛ под редакцией Э.М. Маъруфова и в ЎТИЛ под редакцией Э.М. Мадвалиева совпадают, тогда как к определению весны, составители словарей подошли с различных точек зрения. Это отражает концептуальные характеристики весны в центральноазиатском регионе в целом, и в Узбекистане в частности. Традиция празднования зимой не была свойственна восточным культурам до первой четверти XX-го столетия, и, несмотря на это в Узбекистане и ряде других стран центральноазиатского региона параллельно сохранилась традиция празднования нового года 21-го марта, в день весеннего равноденствия и наступления нового солнечного цикла. Данный факт и служит ответом, почему не зима, осень или лето, а именно весна пополнила ряд женских имен в узбекском языке.

**Литература:**

1. Болалар учун тез айтишлар (матн): тез айтишлар / тўплаб, нашрга тайёрловчи: И.Аввалбоева. – Тошкент: Юрист-медиа маркази, 2019. – 112 б.

2. Камышева С.Ю., Эшпулатова А.А. Языковая репрезентация концепта «весна» в русской лингвокультуре с позиции носителя таджикского языка // Международная

студенческая научно-практическая конференция «В мире русского языка и русской культуры» (Москва, 27 апреля 2017 г.): Сборник тезисов / Отв. ред.: С.Г. Персиянова, И.А. Орехова. – М., 2017. – С. 63-67.

3. Ўзбек тилининг изоҳли луғати: Икки томли, 60000 сўз ва бирикма / С.Ф. Акабиров, Т.А. Аликулов, С.З. Зуфаров ва бошқ.; Э.М. Маъруфов таҳрири остида. – М.: Русский язык, 1981. – 2-чи том. – С. 91, 402.

4. Ўзбек тилининг изоҳли луғати: 80000 дан ортиқ сўз ва сўз бирикмаси. Ж.2./ Таҳрир ҳайъати: Т. Мирзаев (раҳбар) ва бошқ.; ЎзР ФА Тил ва адабиёт ин-ти. – Т.: «Ўзбекистон миллий энциклопедияси» Давлат илмий нашриёти, 2007. – С. 195-196, 420,451.

## А.П. ЧЕХОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МЕДИЦИНА ЛЕКСИКАСЫН ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Назырова А., РУДН, IV курс студенты*

*Фән. җит. – пед. фән. канд., доц. Арзуманова Р. А.*

Танылган рус язучысы А.П. Чехов әсәрләрендә медицина өлкәсенә караган терминнар, төшенчәләр, күренешләр, атамалар бик еш күзәтеләләр. Бу үзенчәлек Антон Павлович Чеховның үз вакытында медицина юнәлешендә белем алуы белән аңлатыла. Мәгълүм булганча, әдип табиб буларак түгел, ә язучы буларак танылу ала. А. Чехов әсәрләре дөньяның күп телләренә, шул исәптән татар теленә дә тәрҗемә ителә. Татар теленә аның әсәрләрен И. Гази, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Шамуков, А. Камский, С. Әдһәмова, Г. Бикбулат, К. Басыйров кебек сүз осталары тәрҗемә итә. Матур әдәбият әсәрләренә караган тәрҗемә материалларының үзенчәлеген образлылык тәшкил итә. Әдәби әсәр лексик-фразеологик һәм синтаксик сурәтләү чараларына ия, шуңа күрә аның тәрҗемәсенә карата таләпләр үзенчәлекле: аңа тел элементларының катлаулырак һәм күп төрлерәк категорияләре белән эш итәргә туры килә. Матур әдәбият әсәрләре телендә теге яки бу өлкәгә караган терминнар әнә шундый катлаулы тел элементларыннан саналалар. Моны А. Чехов әсәрләрен, аерым алганда алардагы медицина өлкәсенә караган лексиканы тәрҗемә итү мисалында күзәтергә мөмкин.

А. Чехов әсәрләрендә медицина терминнары һәм әлеге өлкәгә караган атамалар нигездә табибларның эш көннәре һәм тормышларыннан аерым эпизодларны тасвирлаганда, авыруларны дәвалау барышында табиб хәрәкәтләрен, операцияләрне сурәтләгәндә кулланылганнар. Алар әдәби геройларның сөйләмендә дә еш күз күзәтеләләр. Тикшеренү эшебезнең нигезен тәшкил иткән фактик материал А. Чеховның «Хирургия», «6 нчы номерлы палата», «Ат фамилияле кеше», «Сагыш», «Бүре», «Сөргендә», «Качкын» кебек татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләреннән тупланылды. Әлеге

әсәрләрнең тәрҗемә вариантларында медицина лексикасының түбәндәге тәрҗемәви үзенчәлекләре күзәтелә.

Әсәрләрнең барысында да диярлек, *больниц*а сүзе кулланыла, әмма тәрҗемә вариантында, *хастаханә* дигән эквиваленты булуга карамастан, бу берәмлек үзгәрешсез, ягъни, оригиналь тексттагы кебек, *больница* дип тәкъдим ителә. Әлеге берәмлек төрле сүзтезмәләрдә дә очрый: *больница йортлары* (здания больницы), *земство больницасы* (земская больница), *зәңгәр больница халатлары* (синие больничные халаты). Кулланылыш ешлыгы һәм тәрҗемә ителеше ягыннан д*октор* сүзе дә шундый ук үзенчәлеккә ия булган тел берәмлеге, ул барлык әсәрләрдә дә тәрҗемә ителмәгән хәлдә калдырылган. “Бүре” исемле хикәядә аның синонимы булган *врач* сүзе очрый. Шул ук вакытта татар телендә бу төшенчәне гарәп-фарсы алынмасына нигезләнеп, *табиб* сүзе белән бирергә мөмкин булыр иде. Бирергә шуны искәртергә кирәк, А. Чехов әсәрләре татар теленә башлыча узган гасырның 50 нче елларында тәрҗемә ителгән булган, ә бу вакытта нәкъ менә шушы атамалардан, ягъни *больница, врач, доктор* сүзләреннән актив файдаланыла. Аларның татар вариантлары чагыштырмача соңрак, XX гасырның 80-90 елларында кулланыла башлый. Татар теленә тәрҗемәсе булмаган *фельдшер (фельдшерица), хирург, медицина, операция, палата* сүзләре белән хәл башкача тора, чөнки бу медицина төшенчәләренең татар телендә үз эквивалентлары юк. Чир исемнәрен тәрҗемә иткәндә, күпчелек очракта, шундый ук хәл күзәтелә. Мәсәлән, тәрҗемәчеләр кайбер медицина төшенчәләренең эквивалентларын табуны кирәк дип санамаганнар. *Рожа* исемле авыру, тәрҗемәсе булуга карамастан, оригиналь тексттагыча калган. “Медицина терминнарының рус-татар аңлатмалы сүзлеге”ндә әлеге авыру «рожа, тире кызару авыруы» [1: 210] буларак билгеләнә. *Чахотка* (чахотка, ютәл авыруы, туберкулез) кебек гади сөйләм сүзе шулай ук татар телендә киң кулланылган. Шуңа күрә тәрҗемәчеләр дә аны шул килеш калдырганнар булса кирәк. А. Чехов әсәрләрендә *горячка* исемле авыру тәрҗемәдә х*аста* (авыру) сүзе белән бергә кулланыла. Ул *тир хастасы* дигән искергән гади сөйләм сүзтезмәсен хасил итә. Хәзерге сүзлектә исә бу авыру «бизгәк, кызышу, саташу» [2: 57] дип бирелә. *Тиф авыруы* да тәрҗемәчеләр тарафыннан оригиналдагыча калдырылган. Татар телендә исә бу авыруның *«корсак хастасы»* исемле эквиваленты булуын онытмаска кирәк. Рус телендә кулланыла торган *кашель* сүзе татар телендә, әлеге чирнең нинди формада булуына нигезләнеп, төрле вариантларда бирелә ала. Мәсәлән, ул гади *йөткерү* була ала, яки буылдырып, сулышны кыса торган булса ютәлләү рәвешен ала. Болар барысы татар теленә тәрҗемәдә дә чагылыш тапкан. А. Чехов

әсәрләренең татарчага тәрҗемәләрендә дару атмаларының барысы да диярлек, оригиналдагыча калган: *опий, скипидар, йод, спирт, хинин* (оригиналь текстта хина), *карболка* (оригиналь текстта карболовый раствор).

Медицинага караган кайбер инструмент һәм әйбер атамалары татар теленә тәрҗемәдә дә оригиналдагыча калдырган: *скальпель, термометр*. Күбесе татар телендә үз эквивалентларын тапкан: *мамык – вата, чүкеч – молоток, култыкса – костыль*. «Хирургия» исемле хикәядә «*Зубы разные бывают. Один рвешь щипцами, другой козьей ножкой, третий ключом*» дигән җөмләдә автор стоматологиядә кулланыла торган төрле инструментлар белән таныштыра. Шуларның берсе «*козья нож*ка» дигәне тарихи сүз булып «инструмент с крючкообразной рабочей частью и массивной ручкой, применявшийся для удаления зубов и корней зубов» дигәнне аңлата. Әлеге үзенчәлекләр татар теленә тәрҗемәдә чагылыш тапкан: «*Тешнең бит аның төрлесе була: кайсын кыскыч белән суырасың, кайсын кәҗә сыйрагы белән, ә кайберләрен ачкыч белән...*» [4: 23]. Югарыда китерелгән мисалларда «козья ножка» дигән инструмент татар теленә «*кәҗә сыйрагы*» дип тәрҗемә ителгән, әмма «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә әлеге төшенчә «Кәгазьне озын бүрәнкә сыман итеп төреп, аны урталай бөгеп, махорка-фәлән тутырып ясаган тәмәке төреме» дип бирелә [3: 200]. Күренгәнчә, тәрҗемәче калькалаштыру алымын кулланып, тәрҗемәдә төгәлсезлек күрсәткән.

А. Чехов әсәрләрендә табигыйлек, экспрессивлык төсмерен алган, «медицинага якын лексика» («околомедицинская лексика») да очрый. *Ломит* дигән сүз татар теленә тәрҗемә ителгәндә үзенең экспрессивлыгын югалтып *сызлый* (болит, ноет) дип тәкъдим ителә. В *ухо отдается* дигән сүзтезмә тәрҗемәдә *колагыма кадәр чәнчешә* дип бирелә, *стреляет* сүзенең үзенең туры эквиваленты булмау сәбәпле, тәрҗемәче авыру ситуациясенең бөтен катлаулылыгын күрсәтү максаты белән *чатный* сүзенә мөрәҗәгать итә. Шул рәвешле, тулаем алганда, җөмлә үзенең эмоциональлеген югалтмаган.

Мисаллардан күренгәнчә, матур әдәбиятта теге яки бу өлкәгә караган терминологик лексика әһәмиятле урын алып тора. Аларны автор әсәрдә сурәтләнә торган даирәнең, анда барган вакыйгаларның тулы картинасын тудыру максатында файдалана. А.П. Чехов бу максатка тулысынча ирешкән, аның югарыда телгә алынган әсәрләрендә медицина терминнары үзләренең лаеклы урыннарын алганнар, әмма аларның татарча вариантларында бу төр лексиканы тәрҗемә итүгә бәйле сораулар да бар. Әлеге мәкаләдә тикшерелгән мәсьәләләр, беренчедән, XX гасыр уртасында медицина лексикасын

тәрҗемә итү торышын күз алдына китерергә мөмкинлек бирсә, икенчедән, киләчәктә бу юнәлештә фәнни тикшеренүләр алып бару юлында бер этәргеч булыр дип ышанабыз.

**Әдәбият**


1. Русско-татарский словарь / под ред. проф. Ф.А. Ганиева. – Казань: Татар. кн. изд., 1996. – 214 с.
2. Русско-татарский толковый словарь медицинских терминов: около 10 000 слов. – Казань: Магариф, 2004. – 351 с.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. – Казан: ТӘҺСИ, 2017. – 744 б.
4. Чехов А.П. Сайланма әсәрләр. – Казань, Татгосиздат, 1953. – 232 б.
5. Шамсутдинова Р.Р. Медицинская терминология в татарском языке. – Казань: Регентъ, 2001. – 360 с.
6. Чехов А.П. Тексты произведений. – Режим доступа: ilibrary.ru, свободный.


## СЕРІК САҒЫНТАЙДЫҢ «ҚАРҒА» ӘҢГІМЕСІНІҢ ТЕМАТИКАСЫ МЕН ПРОБЛЕМАТИКАСЫ


*Намаз Ж., Абай атындағы ҚазҰПУ, II курс студенті*

*Ғыл. жет. – пед. ғыл. маг., аға оқытушы Юсуп А.Н.*


Тәуелсіздік жылдары қазақ әдебиетінде шығарманың тақырыбы мен проблематикасын ұсынуда қаламгерлердің тарапынан өзіндік сүрлеу қалыптасты. Әлеуметтік қоғамда болып жатқан өзгерістер жазушылардың шығармашылығына да тікелей әсер етті. Бұл өзгерістер қаламгерлерден бұрын айтуға тыйым салынған тақырыптарға қатысты сөз қозғауға, өзіндік пікір білдіруге итермеледі. Тіпті мұндай үрдіс шығарманың атауынан да айқын көрінді. Қоршаған ортада болып жатқан мұндай өзгерістер шығармада өзекті мәселелерге қатысты астарлап айту арқылы көркем әдебиеттің проблематикасының да маңызын арттырды. З.Қабдолов айтқандай, «Тақырып – жазушының шындық болмыстан таңдап, талғап алып, өзінің көркем шығармасына негіз, арқау еткен өмір құбылыстарының тобы» [1, 160]. Сол себепті онда әлеуметтік қоғамды толғандырған мәселелердің көтерілуі де заңды дүние. Мұның өзі оқырмандарға түрлі ой салу арқылы көркем әдебиет әлемін түсінуге, өзіндік интерпретация жасауға әкеледі.

Қазақ әдебиетіндегі ең күрделі эпикалық түрдің бірі – әңгіме жанры. Көлемі шағын болса да, әңгімеде роман мен повестьтен кем емес, келелі мәселелер көтеріледі. Осы ретте әңгіменің көтерер жүгі де ауыр десек болады. Еліміз егемендік алған жылдардан бастап, ақын-жазушылар тарапынан да, оқырмандардан тарапынан да әңгімеге деген қызығушылық артты. Авторлар мүмкіндігінше әңгімелерінде оқиға мен тартысты шағын көлемге сыйғыза отырып, жаппай көпшілікке ой салу арқылы оқырман санасын оятуды көздейді. Яғни, әңгіме С.Қирабаев атап көрсеткендей, «Әңгіме – әдебиеттің ең қиын жанрының бірі. Ол шағын көлемде үлкен міндеттерді шешеді. Тіпті кейде әңгіме романның,

драманың не поэманың қызметін атқарып кетеді. Адамды суреттеуде, оның психологиясын зерттеуде, олардың ойын, сезімін, күрес жолын көрсетуде үлкен жанр мен әңгіменің арасында айырма жоқ. Өйткені әңгіме үлкен жанрлар сияқты адамдар арасындағы қатынасты, өмір шындығын суреттейді. Өмірде шағын тақырып, ұсақ сезімдер деген атымен жоқ» [2, 447]. Біздіңше, академиктің айтқан дәл осы сөздері біз талдағалы отырған С.Сағынтайдың «Қарға» әңгімесіне де қатысты айтылғандай боп көрінеді.

Серік Сағынтай – қазақ әдебиетінде өзіндік қолтаңбасы, ерекше стилімен танылған бөлек қаламгер. Оның қаламына қазақ әдебиетінде Ж.Аймауытов салған лирикалық прозаның элементттері тән. Дегенмен, жеке тілдік тұлға ретінде жазушының прозасы өзіндік ерекшелігімен танылатын соны дүниедей көрінеді. Қаламгердің қазіргі кезде бәрімізге белгілі «Жазу», «Фәни-құс» атты өлеңдер жинағы, «Қарға» атты әңгімелер жинағы бар. Ол өзінің әр шығармасында жеке адамға, адамзат баласына, әлеуметтік қоғамға қатысты әртүрлі проблемаларды сөз етеді. Оның өмір мен өлім, махаббат пен жауыздық, жақсы мен жаман, т.б. ұғым-түсініктер жайлы ойлары әр шығармасының бойында кестеленіп өріліп отырады. Соған сәйкес қаламгер адам өміріндегі бүкіл дағдарыс формаларын әңгімелерінің проблематикасы етіп атап көрсетеді. Мұндай үн қатулар арқылы өмірді, әлемді өзгерткісі келеді, оқырманның жадын жаңғыртып, санасына ой салады. Оның шығармаларының кейіпкерлері шындықтан, рухани діңгектен, өмірлік ұстанымнан қол үзгендей болып көрінеді.

«Қарға» әңгімесі – адам жанына әсер ететін кесек туындылардың бірі. Шығарманың өң бойында соңғы әдеби үдерістерге қатысты туындаған түрлі формалар кездеседі. Адамның табиғатқа, қоршаған әлемге деген қатынасы арқылы оқырманның жан-дүниесін алай-дүлей етеді. Сол арқылы әлемді өзгерткесі келетінін анық байқатады.

Жазушы аталған шығармасы арқылы өз шығармасында әлеуметтік тематиканы басты тақырып етіп алғаны айқын байқалады. Қоғам трагедиясын, адам трагедиясын сипаттау арқылы адамзат баласын әлемдік қауіп-қатерден, немқұрайдылық пен қатыгездіктен сақтандырғысы келеді. Адам баласының бойындағы ашкөздік, зұлымдық, қатыгездік, пайдакүнемдік секілді жаман қасиеттерді сынға алады. Осыған қарап біз оның шағын көлемді прозалық шығармаларында сыни көзқараспен қатар сентиментальдық пафос та көрінетін байқаймыз.

Әңгімені алғаш оқыған адам қарға жайлы баяндалған этнографиялық әңгіме деп ойлап қалуы мүмкін. Әңгіменің басы былай басталады: «...Қарғалар өзара сөйлеседі екен. Қарқ-қарқ етіп, қиялай

ұшып бара жатқанда маңындағы тамырына әлденені ескертіп айтадымыс. Не айтатынын кім білген?! Өз кебімізге түсіріп, «Қу құлқын шығар?» дейміз кейіп. «Қарқ-қарқ. Кеттік. Егістік жаққа барып қайтайық, туыстарымыз келе бастаған сыңайлы. Бұл қораның маңында аса мардымды тағам жоқ тәрізді, қарқ-қарқ...». Осылай қарғаны сипаттаған автор «Бұл қарғаны сипаттамаған жан жоқ шығар бұл әлемде? Қарғаның тілін кім ұққан?» [3] деп қарға жайлы топшылаулар жасайды. Қарға автор үшін жұмбақ, тылсым құбылыс. Оның өзінің тілі, болмысы бар. Қанша ғалымдар зерттеп-зерделегенмен, қарғаның тілін ұққан жан жоқ. Сол себепті автор қарғаның тілін ұққысы келеді. Ол: «Бірақ, бірде қарғаның аузынан, жаңылам, тұмсығынан шыққан үннің бәрін ұға кеттім. Бір топ қарға еді. Жабыла жалбарынғандары, шырқырай шыққан үндері керемет ұғынықты еді. Қарғалар адамнан да түсінікті тілде сөйлейді екен...» [3] дей келе, Қояншоқыда болған негізгі оқиғаның сюжетін бастап кетеді.

Әңгіменің композициясын да шартта түрде бірнеше бөлікке бөлуге болады. Автор мұндай композициялық құрылымды әдейі таңдап алғандай көрінеді. Шығармада түрлі үзік ойлар, тіпті соңына қарай адам баласының жауыздығын айқындайтындай Құран Кәрімдегі «Мәида» сүресінде берілген ескі аңыз да беріледі. Бұл аңыз арқылы автор шығармада айтайын деп тұрған ойын түйіндеп, қорытындылағандай көрінеді. Адамның қатыгездігі бір жағынан ақылды дана саналатын, екіншіден өлім мен қауіпті шақыратын, түріне қарап ешкім ұнатпайтын қарғадан да асып кетеді. Адам пайда табу үшін ашкөздіктен қатыгездікке барады.

Одақ ыдырағаннан кейін адамдарда да дағдарыс басталады. Баяғы колхоз, совхоз жоқ. Әркім өз күйін күйттеп кетеді. Шығарманың кейіпкері Жәкем де күнкөріс қамымен ауылда шемішке зауытын салуды ойлайды. Бала-шағасымен осының қамына кіріседі. Күзде керемет өнім алып баюды ойлайды. Алайда кейіпкердің ойына кедергі болған қарға сахнаға шығады. Қарғадан қалай құтылудың амалын ойластырған кейіпкер ойы сан-саққа кетіп, дал болады. «Іздегенге сұраған дегендей» бір күні «шарасыздық шалдықтырған Жәкемді ауылдағы Қабыл досы іздеп келсін бір күні. Қан майданның өтінде жүргенде келді. Қараборбайланып, қажыған бізге мысқылмен қарап тұрды-ау. Осы қарғадан құтылудың амалын айтсам не бересің, Жәке? – деді сәл тыныстан соң. Е, сұрағаныңды ал... Онда, маған үш қаз үйітіп бересің. Қаз сөз боп па, үш жүз қарға қосып үйітіп берейін, – дейді Жәкем күйініп. Қап, арзандау айтып қойдым. Дегенмен, барға қанағат. Ал енді бәрің бері келіңдер, – деп, бізді ашық алаңға бастады білгішбек. Қарғалар назар аудармасымызды аңдап, хан талапайды

қыздыра бастаған». Қабыл «Қарға аулау білесіңдер ме?» деген сұрағының өзі оқырманға алда бір сұмдық болатынан хабар бергендей болады. Автор адам жанын түсінгісі келеді. Оның табиғат Анаға деген осы зұлымдығы түбінде бір трагедияның болатынын аңғартады. Қарғаға соғыс ашқан бүтіндей бір әулет ұстап алған он қарғаның жанын қинайды. «Қазір бастаймыз. Мен мына магнитофонға, таспаға жазуды бастаған сәтте қолдарыңдағы шегемен қарғаларды басқа-көзге қарамай піскілейсіңдер. Дауысынан қорықпаңдар. Бәлемдердің үндерін жазып алып, басқа қарғаларға тыңдатамыз. Сосын келіп көрсін бұл маңға! Ал, кеттік...», – деген Қабылдың сөздері бәрін қанаттандырғандай болады. Өздері не істеп жатқандарын толық түсінбеген адамдар «Күйсандықтың тетігі шырт ете қалғанда Жәкемнің қолындағы көр шеге алдындағы қарғаның төсіне кірш етіп қадалды. «Қғғғ-ғғарррррр!» деген аса аянышты үн құлақты тесіп, миыма шағылды. Орнымнан қалай ұшып тұрғанымды білмеймін. Бәріміз сілейіп қалыппыз. Төсіне темір кірген бейбақ құйқа шымырлатар үнмен бебеулеп жатыр. «Не қарап тұрсыңдар!» Қабыл айғай сала, ұрандап, менің қолымдағы бізді жұлып алып, жерде сілейіп жатқан қарғаға пісіп-пісіп жіберді. «Қрррр-ғғғақққ! Қиқққ-ғғарррқ! Қаққ-қаққ!» Қарға жылап жатқан секілді. Қарға жанына батқан жарадан аһ ұрып, айғайлап көмек сұрағандай болды. Сол сәтте қанды топалаң басталды да кетті», – дейді автор. Мұндай трагедияны қазақ даласы көрген, естіген емес. Заманға қарай адам пиғылының өзгеруі түптің түбінде қайғылы жағдайға әкеледі. Жәкем шемішке зауытын салады, мынандай сұмдық соғыстан кейін Сарыесік маңында қарға түгіл құс атаулы да безіп кетеді. Осындай қойылымның режисссері болған Қабыл масаттанып, ерлік істегендей кейіпке түседі. Әділ бала суға кетеді. Жазушының кейіпкерлер тағдырына қатысты шығарған үкімі осы. Гуманистік ой иесі шығарманы осылай қорытындылайды. Қарға екеш қарға да Алланың пендесі, табиғат Ананың тумасы. Ол да өмір сүргісі келеді. Оған қиянат жасау арқылы түптің түбінде баяндаушының көкесі де ұлынан айрылады. Трагедеи ядеген міне осы. Жай трагедия емес, өте аянышты жағдай.

Әңгіменің композияциясы өте күрделі. Қаламгер сөзінің дәледемесі ретінде әңгіменің басында эпиграфты да тектен текке алмаған секілді. Мына берілген эпиграфтар, яғни Жан Поль Сартрдің «Бывают дни, когда человек вселяет в меня ужас...» пен Мұхаммет Салықтың «Ей, ұшып жүрген қара кітап...» деген сөздері адамзат баласының хайуаннан арман жауыз екенін аңғартатындай.

«Қарға» әңгімесі ұлылардың айтқан осы сөздермен үндес. Адам әлеуметтік қоғамда, қоршаған ортада өзінің пәрмендігімен, беделімен

барлық тіршілік иелерінен үстем болып, биік тұрғанымен, жазалаушы, үкім шығарушы бола алмайды. Ол да алланың пәрменінің алдында дәрменсіз. Өзінің жасаған қиянаты мен күнәсі үшін жазасын артады. Ондай шешім ұзақ күттірмейді. Түптің түбінде жазыдан құтылмайды. Өзі жазасын тартпағанмен, ұрпағы көреді дегенді меңзегендей болады. Сол себепті әңгіменің соңына қарай туысының өлігін жасыруға жіберілген қарға бейнесі арқылы, Қабылға ақиқатты нұсқаған Құранның сүресі келтірілген. Бұл әңгіменің эпилогі іспеттес. Демек шығарма, тек бір адамның қатыгездігін ғана сипаттап тұрған жоқ, бүкіл адамзат баласының әр кезеңде, әр сәтте жасаған қатыгездігі жайлы сыр шертеді десек те болады. Бұдан біз болашақ үшін алаңдаған, күйзелген автордың жан күйзелісін байқаймыз. Әңгіменің басында айтылған дүниелер жеке адам тағдырындағы тағдырындағы проблематика болса, «Қарға» жалпыадамзаттық пәлсапалық проблема ретінде көтеріледі.

Сөзімізді түйіндер болсақ, Серік Сағынтайдың «Қарға» атты әңгімелер жинағы адамзат баласының санасын оятатын, жанын жаңғыртатын пәлсафалық ойлардан тұрады. Себебі, осы жинағы арқылы автор бүкіладамзаттық проблемаларды көтеріп, оны шешудің жолын іздегендей болады. Адам жанының табиғатын тану арқылы өмірде болып жатқан күрделі конфликтерді қалай шешуге болатындығы жайлы ой қозғайды.

**Әдебиет**


1. Қабдолов З. Сөз өнері. – Алматы, «TST - Company». – 2006. – 360 б.
2. Қирабаев С. Көп томдық шығармалар жинағы. – Алматы: «Қазығұрт» баспасы, 2007. Т.1. – 456 б.
3. https://adebiportal.kz/kz/news/view/3026.


## Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «КӨЗ» ПОВЕСТЕНДА ДӨНЬЯ ТЕЛ-ӘДӘБИ СУРӘТЕ


*Нәбиуллина Э., ИЯЛИ им Г.Ибрагимова АН РТ, аспирант*

*Фән. җит. – филол. фән. канд. Ахунов А.М.*


«Көз» повесте – Гаяз Исхакыйның ватаныннан читтә яшәгәндә иҗат иткән әсәрләренең берсе. Әсәр 1923 елда языла, тик бу чорда авыр матди шартларда яшәвенә бәйле, Исхакый повестьны 1938 елда гына Берлинда үзе оештырган «Милли юл» нәшриятында чыгара. Әсәрдә татар тормышының революциягә кадәрге чоры сурәтләнсә дә, аны «татар эмиграция әдәбиятының классик үрнәге дип атарга мөмкин» [2: 10]. «Милли байрак» журналының 130 нчы санында чыккан «Яңа әсәр» исемле мәкаләдә (авторы Х.Ф. дип күрсәтелгән): «...хикәяне күңелле булган өчен генә, ләззәт алу өчен генә түгел, милли әдәбиятне, ил тормышын белер өчен, шуның аркасында милли рухны сүндерми яшәтер һәм мөхәҗерәттә аксап калган телне төзәтер өчен уку кирәктер», – диелә. – «Мәшһүр әдибебез Гаяз Исхакый бәкнең (…)

«Көз» исемле хикәясе чын мәгънәсендә без яшьләр күрми үскән милли тормышны күрсәтүче кыйммәтле әсәрләрдер» [2: 528], – дип яңа әсәрнең әһәмиятен ассызыклый мәкалә авторы.

Хәзерге филология фәнендә кеше һәм аның теленә бәйле дөнья сурәте феномены чагыштырмача яңа һәм актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Әдәби әсәрдә авторның яшәү, фикерләү рәвеше, билгеле бер чор җәмгыять һәм милләт вәкиле буларак дөньяга карашы чагылыш таба, ә тел чынбарлыкны танып белүдә төп чара ролен үти.

Әсәр тукымасында дөнья сурәте иң элек макродөньядан, ягъни авторның дөньяны күзаллавы нигезендә булган конструкттан гыйбарәт; икенчедән, күпсанлы микродөньялардан тора, әлеге микродөньялар аерым геройларның яки әсәрдәге җыелма образларның дөньяны кабул итүенә нигез була [1]. Әсәр геройларының эчке дөньясын, карашларын чагылдырганда, язучы тарафыннан мифологик, дини, фәнни, әдәби, милли дөнья сурәте кулланыла. Шушы күзлектән Гаяз Исхакыйның «Көз» повестен өйрәнү аны яңача кабул итәргә, әдәби әсәрнең яңа катламнарын ачарга мөмкинлек бирә.

Әсәрнең сюжеты бер-берсе белән моңа кадәр таныш булмаган ике геройның Нәфисә белән Гөлсемнең бер урында – Идел буйлап барган пароходта очрашып, үзләренең тормыш юлларын сөйләү, узган елларны искә алу буларак корылган. Повесть вакыйгалар барган урын һәм вакытны тасвирлау белән башланып китә. Вакыт һәм урын төгәл билгеләнгән кебек булса да *(“Көз иде”, “Иделнең ярларын каплап алган”),* геройлар өчен бу шомлы һәм билгесез бер урын, аның төгәл чикләре дә юк: *“күзгә төртсәң күренмәс караңгы төн”, “караңгылык”, “очы юк”, “кырые юк”, “томан куера”.*

Шушы билгесезлектә Нәфисә үзенә уңай урын тапкан: ул “*каютаның почмагына кереп поскан да утырган*”, “*йылы китап эченә чумган*”. Димәк, чынбарлыктан үзе теләгән дөньяга кереп китеп, караңгылыкта үзенә уңайлы булган чикләр кора алган. Озак та үтми бу “*коры якты булмәгә*” Гөлсем килеп керә, үзе белән *“юешлек, караңгылык”*ны алып керә: “*унике сәгать параход көттек юешләнеп беттек*” – дип хәбәр итә. Шул рәвешле Г. Исхакый безне геройларның эчке дөньясына алып кереп китә. Кешенең эчке дөньясы аның яшәгән даирәсе, көндәлек тормышында барган вакыйгаларга бәйле – бу фикерне автор әсәрнең буеннан буена үткәрә: *“Бала-чага нинди тирә-юньдә үссә, шуның гадәтен ала”.*

Исхакый геройларының дөньяны күзаллавы әйләнә-тирәне төрлечә кабул итүгә нигезләнә (дини, милли, фәнни, сәнгати) һәм персонажны характерлаучы бер чарага әйләнә. Нәфисәнең гаиләсе милли-дини карашлар белән яши, бу, билгеле, гаилә әгъзаларының телендә дә

чагыла: *“ячы килгән икән”, “малай-салай белән чуалып йөрергә рөхсәт юк”, “йолага сыймый”, “Ничек ата-анамның йөзенә кара ягам дип, Алладан курыкмадың?”* Шул ук вакытта Нәфисәгә дөньяны романтик кабул итү дә хас, ул үз бәхете өчен көрәшеп, теләгәненә ирешә. Хәлилне эзләп чыгуы, аларның вәгъдәләшүе дә аның характерын шул яктан ача: *“Миңа сагынмалык бер нәрсә калдыр”, “Тургеневның “Беренче мәхәббәт” хикәясен сузды”.* Хәлил нечкә күңелле кеше булуына карамастан, дөньяны рациональ кабул итә, үз тормышы өчен җаваплылыкны үз кулына ала: *“Урыс арасында тора торган кеше, үзен-үзе саклап, мөселман гаиләсенә катышырга тели”.*

Гөлсемнең дөньясы үзгә, ул русча укыган, рус даирәсендә тәрбияләнгән: *“Тирә-юнебездә һәммәсе рус иде, өйдә дә русча сөйлиләр иде”.* Ул хәтта үзен төгәл кем булуын да белми үскән, үзен “*әллә нинди икенче рус”* булуын аңлап, хәтта *“чынлап рус булмавыннан”* хурланган да, ягъни балачактан үз асылыннан ераклаштырыла һәм гомерлеккә шушы идеалларның корбаны булып кала.

Әсәр татарлар яшәгән географиянең күнегелгәннән киңрәк булуы белән дә кызыклы: вакыйгалар бер авыл, шәһәр яки өлкә белән генә чикләнми. Кулланылган топонимнарга игътибар итсәк (Нәфисә Оренбург шәһәрендә туа, әтиләре Орскийлар белән вәгъдәләшә, Уфага барып никах укытырга уйлыйлар, Мәскәүдә хезмәт итәләр, Идел буе шәһәрләрендә яшиләр, Кырымга, Германиягә ялга йөриләр һ.б.), Г. Исхакый әлеге әсәрне һәр җирдә яшәүче милләттәшкә адреслый. Шул ук вакытта автор географик чикләр белән билгеләнмәгән, тик менталь яктан төрле булган рус һәм татар дөньясын икегә аера: берәүләр шушы чикнең уртасында, кайсы якка авышырга белми яши (Гөлсем), икенчеләр инде гомумән үз асылыннан читләшкән (Гөлсемнең тутакае), өченчеләр чит җирдә яшәргә мәҗбүр булсалар да үз асылын саклый (Нәфисә, Хәлил).

**Әдәбият**

1. Аюпова С.Б. Языковая художественная картина мира и ее признаки (на материале произведений И.С. Тургенева) // http://www.den-za-dnem.ru/page.php?article=2055 (Дата обращения: 25.01.2022)

2. Исхакый Г. Әсәрләр, 15 томда. 5 том. – Казан, 2009. – 559 б.

3. Попова М.К. Картина мира как проблема гуманитарных наук // Картина мира и способы ее репрезентации: Научные доклады конференции «Национальные картины мира: язык, литература, культура, образование» (21-24 апреля 2003 г., Курск). — Воронеж, 2003. – С. 13-38.

## ТАТАР ЛЕКСИКАСЫН ӨЙРӘНҮДӘ АКЫЛ КАРТАЛАРЫН КУЛЛАНУ

*Нәҗипова Г., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Әшрәпова А.Х.*

Хәзерге ФГОС таләпләре буенча уку предметларын өйрәнгәндә, укучылар мәгълүмат белән эшләү күнекмәләрен камилләштерергә һәм

аларны тулыландырырга тиеш. Алар текстлар белән эшләгәндә, андагы мәгълүматны үзгәртә һәм интерпретацияли алачак, шул исәптән: әзер мәгълүмат объектларында булган мәгълүматны системалаштыру, чагыштыру, анализлау, гомумиләштерү һәм интерпретацияләү; төп һәм өстәмә мәгълүматны аерып күрсәтү; кыскартылган сүз формасында (план яисә тезислар рәвешендә) һәм күрсәтмә-символик формада (таблица, график схемалар һәм диаграммалар рәвешендә, карталар – концептуаль диаграммалар, таяну конспектлары рәвешендә) мәгълүматны тәкъдим итү; таблицаларны, схемаларны, диаграммаларны, текстларны тутыру һәм тулыландыру кебек күнекмәләрне үзләрендә булдырачак.

Укучының шәхси үсеш ысулы буларак акыл карталарын куллану мөмкин. Акыл карталары – ул кәгазь бите кулланып, уйлап табу, истә калдыру, искә алу ысулларын чагылдыру, шулай ук мәгълүматны эшкәртүнең эчке процессларын да күрсәтү, аларга үзгәрешләр кертү, камилләштерү. Универсаль уку гамәлләре формалашу өчен уку процессында акыл карталары куллану төрле булырга мөмкин: укучыларның индивидуаль, төркем һәм коллектив эшчәнлеген оештыру; укучыларның яшь үзенчәлекләре нигезендә укыту эчтәлеген конструкцияләү; укучыларның проект эшчәнлеген һәм мөстәкыйль эшен оештыру. Акыл карталары куллану ысулы балаларны сүзлекләрдән, белешмәләрдән һәм башка язма һәм телдән мәгълүмат чыганакларыннан кирәкле мәгълүматны эзләү һәм аларны системага салуга өйрәтәчәк. Акыл карталары укучыларның иҗади, интеллектуаль һәм интуитив сәләтләрен, фикерләү процессын, хәтерен үстерә. Әлеге ысулның идеясе шунда: рәсем яки язу формасында өйрәнү предметы битнең үзәгендә урнаша. Төп фикерләр үзәк рәсемнән чыккан ботаклар формасында сурәтләнә, өстәмә фикерләр исә нечкә сызыклар ярдәмендә үзәк сызыкларга кушыла. Акыл карталарында сүзләр генә түгел, рәсемнәр, символлар куллану кулайрак дип санала.

Татар теле дәресендә акыл карталары укучы тарафыннан шәхси планда төрле форматта кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, яңа теманы узганда, укучы төп мәгълүматны аерып чыгарып, акыл карталарын төзи, җавап биргәндә шул схемага нигезләнеп теманы сөйли. Проектлар өстендә эшләгәндә, укучылар үз идеяләрен тәкъдим итәргә, чишелеш табарга, үз чишелешләренең нәтиҗәләрен фаразларга, яңа проблемаларны күрергә, эшне планлаштырырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәнәләр. Бу ысулның авторы фикеренчә, акыл карталары теләсә кайсы телнең лексикасын өйрәнергә ярдәм итәргә мөмкин. Үзенең “Mind maps for kids” исемле китабында Тони Бузан үрнәк итеп француз телендәге фигыльләрне алган [1: 76]. Акыл карталары ярдәмендә, автор

фигыльгә төрле затларда нинди фигыль кушымчаларын ялгарга кирәк булганын өйрәтә. Димәк, бу ысулны татар теле лексикасын өйрәнгәндә дә куллану мөмкин дигән фикергә килеп була.

Дәресләрдә акыл карталары ярдәмендә “Гаилә”, “Хайваннар”, “Кием”, “Спорт”, “Төсләр”, “Җиләк-җимешләр”, “Яшелчәләр”, “Бәйрәмнәр” кебек темаларга багышланган лексиканы өйрәнергә мөмкин. Үрнәк итеп, “Яшелчәләр” темасын өйрәнү өчен акыл картасын ясап карыйк. Кәгазь бите уртасына зур хәрефләр белән “Яшелчәләр” дип язып куябыз, янына яшелчәләр ясап куярга да мөмкин. Икенче этап итеп, төрле төстәге калын сызыклар ясала, алар өчтән ким булырга тиеш түгел, оптималь саны – 5-6 ботак. Һәр ботак өстендә яшелчәнең исеме языла, мәсәлән, “кәбестә”, “кыяр”, “суган”. Шулай һәр сүз янына схематик рәвештә рәсем ясап була. Соңыннан калын ботактан нечкә сызыклар ясыйбыз. Беренчесе өстенә – сүзнең тәрҗемәсен, икенчесе – яшелчәнең төсен, өченчесе –формасы, дүртенчесе – бу яшелчәләр кергән ризыклар исеме, бишенчесенә табышмакны яисә бу яшелчә белән бәйле мәкальне “Мич башында шалкан пешми” язып була. Өченче төр сызыкларга бу мәкаль белән бәйле ассоциацияләрне “ялкаулык”, “эш” дигән сүзләрне дә язарга мөмкин. Бу очракта акыл карталары укучыларга яңа лексиканы өйрәнергә генә ярдәм итми, укытучылар өчен сораштыру вакытында нигез булып тора.

Хәзерге көн татар теле укытучылары өчен төп бурычларның берсе буларак укучыларның актив сүз хәзинәсен синонимнар белән баету тора. Шул уңайдан укучыларны телнең синонимик байлык белән таныштыру, сөйләм телендә кулланырга өйрәтү мөһим проблемаларның берсе булып тора [2: 16]. Бу төр эштә дә акыл карталары төп ярдәмче булып тора. Бу ысулны кулланганда, сүзнең синонимнарын гына түгел, аларның кайсы стильдә куллануын истә калдырырга мөмкин.

Акыл карталары - татар теле дәресләрендә лексиканы өйрәнүдә актив кулланылырга лаеклы ысул. Аларның яңалыгы укытучының белем бирүче позициясендә генә түгел, укучыларның танып белү эшчәнлегенең оештыручы булудан гыйбарәт. Карталар укучыларга мәгълүматны үзләре табып үзләштерергә, укытучы белән һәм үзара фикер алышырга өйрәтә. Акыл карталары укытучыга уку процессында уен элементларын кулланып, уңай эмоциональ даирә урнаштырырга ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. Tony Buzan. Mind Maps for Kids. – Thorsons: Reissue edition, 2005. – 128 p.
2. Шәкүрова М.М. Татар мәктәпләрендә татар телен укыту методикасы. Лекцияләрнең кыскача конспекты. – Казан, 2014. – 62 б.

# МӘДӘНИЯТАРА КОММУНИКАЦИЯНЕ ФОРМАЛАШТЫРУ ЧАРАСЫ БУЛАРАК МУЛЬТИПЛИКАЦИЯ

*Нәүмәтова Р., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Хәзерге чорда сүз мәдәниятеннән визуаль образлар мәдәниятенә кискен борылыш ясалды. Әйләнә-тирә турындагы мәгълүматны тапшыру, кабул итү чыганаклары арасында визуальләштерү алымы төп урынны били. Визуаль контент – тексттан кала, аның белән янәшә килә торган барлык мәгълүмат. Фотосурәтләр, рәсем, карикатура, логотип, схема, график, диаграммалар, шулай ук слайд-шоу, анимация, клип, видеоязмалар текстны кабул итүне җиңеләйтә, ә кайбер чакта аны алыштырып та килә. А.А.Градюшко әйтүенчә, бүген укый торган кеше чорын мәгълүматны визуальләштерү гасыры алмаштыра [1: 79]. Соңгы вакытта визуаль чыганаклар арасында кино сәнгате (шул исәптән мультипликация) киң таралыш алды.

Мәгълүматны аудиовизуаль чара ярдәмендә кабул итү өстенлек иткән шартларда, мультипликация яшь буынның дөньяга карашын формалаштыру, милли-мәдәни кыйммәтләргә игътибарын арттыру, чит мәдәниятне аңлату чарасы буларак кулланыла.

Балалар өчен мультипликация кешелек кыйммәтләрен, нормаларны, мәдәниятне тапшыруда арадашчы функциясен башкара. Ул коммуникациянең туган җиргә, табигатькә мәхәббәт, дуслык хисе, ата-анага хөрмәт кебек сыйфатларны формалаштыра торган иң уңайлы каналы буларак кабул ителә. Мультипликациядәге сурәтләү чаралары ярдәмендә бала үзе яшәгән җирлек тормышы белән генә түгел, чит халыклар тормышының бер өлеше белән дә таныша, персонажларның тәҗрибәсе нигезендә сәбәп-нәтиҗә элемтәләрен бәйләргә өйрәнә. Бу факторлар ярдәмендә баланың кешелек җәмгыятендә адаптациясе күпкә тизрәк һәм уңайлырак үтә.

Мәдәниятара коммуникация (ингл. cross-cultural communication, intercultural communication), мәдәни хезмәттәшлек, мәдәниятара багланышлар – төрле мәдәният вәкилләре арасындагы элемтә, аралашу.

Кино сәнгате милли, этник мәдәниятне чагылдыра торган сәнгать төре буларак билгеле. Нәкъ менә кино сәнгате чаралары ярдәмендә милли идеяләрне гәүдәләндерә торган образлар тудырырга мөмкин. Моннан тыш, нәкъ менә кино сәнгате, визуаль мәдәният шартларында милли образларны чагылдырып, милли мәдәниятне саклап калу һәм яңадан торгызу өчен кирәкле иьтимагый-мәдәни киңлек булдыра. Кино сәнгатенең аерым бер милләтнең тарихы, әдәбияты (шул исәптән фольклор, мифологиясе) белән бәйле әсәрләрне экранлаштыру мөмкинлеге бу миссияне тормышка ашыруга ярдәм итә.

А.А. Семенова милли кино сәнгате әсәрләрен булдыруның түбәндәге принципларын билгели: үзенчәлекле милли образларны визуальләштерү, традицион милли проблемаларны тәнкыйтьләү, милли тарихи вакыйгаларны визуальләштерү, персонажлар тарафыннан дөньяны милли, дини күзлектән кабул итүне актуальләштерү, милли герой образын визуальләштерү [3: 147].

Кино сәнгатендә анимацион кино (мультипликация) аерым урын алып тора. Соңгы елларда компьютер технологияләре камилләшү нәтиҗәсендә мультипликация өлкәсе җитештерү, сәнгати бөтенлек, иҗадилык ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрелде. Балаларга юнәлтелгән мультипликацион фильмнарда иҗтимагый һәм мәдәни чынбарлыкның төрле феноменнары, шул исәптән чит халыкларның мәдәнияте һәм телләре чагылдырыла. Шуңа күрә балаларның этномәдәни күзаллаулары формалашу вакытында мультипликация мөмкинлекләрен исәпкә алырга кирәк.

Анимация өлкәсен өйрәнүгә зур өлеш керткән Н.Г. Кривуля, анимацияне мәдәни феномен буларак өйрәнгәндә, мультипликацион фильмнарны тамашачыга мәдәни, әхлакый нормаларны тапшыру яссылыгыннан карый. Мәдәниятнең аерылгысыз өлеше буларак, анимация аның матди ягын, рухи өлешен өйрәнү өчен мөмкинлекләр ача. Автор анимациянең ике төп аспектын аерып чыгара: милли сәнгать образларын тапшыра һәм саклый торган форма (фольклор анимациясе) һәм төрле мәдәният вәкилләре арасында үзара аңлашуга корылган, элемтәләр урнаштыруга юнәлтелгән форма (этнографик анимация) [2: 15].

Фольклор анимациясенә караган мультфильмнар – халык әкиятләрен, җырларын, мәкаль-әйтемнәрен, риваять һәм мифларын экранлаштыру һәм адаптацияләүгә юнәлдерелгән. Этнографик анимацион фильмнар теге яки бу халыкның яки җәмгыятьнең тарихы, көнкүреше, милли гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, диннәре, тарихи шәхесләре турындагы мәгълүматны үз эченә ала. Фольклор һәм этнографик юнәлештәге мультфильмнар мәдәниятара диалог урнаштыру, башка халыкларның тормыш-көнкүреше белән танышу өчен мөмкинлекләр ача.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: мультфильм – киң масса тамашачыга юнәлтелгән үзенчәлекле сәнгать төре. Ул аудиторияне мәдәният төшенчәсе белән таныштыру, төрле халык мәдәниятләре арасында элемтә формалаштыру, дөньядә мәдәни төрлелек турындагы белемнәрне киңәйтү өчен зур мөмкинлекләргә ия.

**Әдәбият**

1. Градюшко А.А. Перспективные стратегии вебжурналистики в глобальном информационном пространстве // Международная журналистика-2014: диалог культур и

взаимодействие медиа разных стран: материалы Третьей Междунар. науч.-практ. конф., 20 февр. 2014 г., Минск. – Минск: Изд. Центр БГУ., 2014. – С. 77-89.

2. Кривуля Н.Г. Анимация как феномен культуры // Анимация и мультимедиа между традициями и инновациями: материалы V международной научно-практической конференции «Анимация как феномен культуры», Москва, 7–8 октября 2009 г. / сост. Н.Г. Кривуля. – М.: ВГИК., 2010. – С. 4–20.

3. Семенова А.А. Визуальная культура модернизированного социума // Вестник Волгоградского государственного университета. Серия 7, Философия. Социология и социальные технологии. – Волгоград: Вестник ВолГУ., 2012. – № 3. – С. 145-149

## УЗЛУКСИЗ ТАЪЛИМДА БУХОРО БОЛАЛАР ФОЛКЛОР ҚЎШИҚЛАРИНИ ЎРГАТИШ ДОЛЗАРБ МЕТОДИК МУАММО СИФАТИДА

*Орипова Н., БухГУ, студент I курса*

*Науч. рук. – доц. Тўхтасин Р.И.*

Миллий ғоя ва мафкура ўз мазмунида маънавий ва маданий меъросимиз, миллий қадриятларимизни мужассам этади. Маданий ва маънавий мерос авлод-аждодларимиз томонидан яратилиб бизгача етиб келган бебаҳо хазинадир. Унда ёш авлод тарбиясида фойдаланиш, шу орқали уларни она ватанга, халқимиз тарихи, тили, маданияти, урф-одат ва анъаналарига муҳаббат руҳида тарбиялаш таълим тизими олдидаги ўз долзарблигини йўқотмайдиган вазифалардандир.

Ўзбек халқ мусиқа мероси хазинасида катталар билан кичик ёшдаги болалар маънавий дунёсини ўзида уйғунлаштирган, боллалар фолклор мусиқа асарлари, болалар қўшиқлари ҳам муҳим ўрин тутади. Бундай қўшиқлар ўзида болалар ҳаёти, руҳияти, болаларга хос турли ўйинлар, айтишувлар, ҳайвонот ва ўсимликлар табиат ҳодисалари билан боғлиқ ҳолатларни ўзига хос ифода этиши билан ажралиб туради. Болалар қўшиқлари ҳам халқ мусиқасининг оммавий турлари сингари бадиий ва ғоявий мазмунга эга бўлиб, матни содда, ниҳоятда ихчам, ўйин-рақсбоп характерга эгалиги билан ўзига хослик касб этади.

Умумтаълим мактабларининг бошланғич синфларида болалар тафаккурига хос, кўпроқ ўйин билан боғлиқ Бухоро болалар фолклор қўшиқларини, куй ва енгил айтимларни ўргатиш мусиқа таълимининг миллий асосини шакллантиришда муҳим рол ўйнайди. Демак, мусиқа дарсларида халқимизнинг миллий мусиқа мероси таркибидаги Бухоро болалар фолклор қўшиқларидан мақсадга мувофиқ ҳолда фойдаланиш, уларни ижро этиш услубларини унинг мақсад ва шева маъноси эътиборга олган ҳолда тадбиқ этиш ҳар бир мусиқа ўқитувчисидан ўзига хос педагогик ёндошув, билим малака ва маҳоратни талаб қилади.

Биз биламизки, Ўзбекистон Республикаси бешта махаллий услубларга бўлинган бўлиб булар: Бухоро – Самарқанд, Қашқадарё – Сурхондарё, Фарғона – Тошкент, Хоразм ва Қорақалпоқ воха

услубларидир. Бу воҳалар урф одатлари, анъаналари, тўй маросимлари, қўшиқлари шева ва ижро услублари билан бир – биридан фарқ қилади.

Бунга мисол Бухоро болалар фолклор қўшиқлари ўзининг ўйноқи ва шўхчан хазил лапар айтишувлари, рақслар,жумбоқлар, чистонлар(нима у?) билан бошқа воҳалардан фарқ қилиб, асосан икки тилда ижро этилади(ҳам ўзбек ҳам тожик).

Бухоро болалар фолклор қўшиқларига мисол:

1. Қўшиқ Бобожон
2. Қўшиқ аху-аху
3. Халқ ўйини Занжира бофтем
4. Хазил қўшиқ Чи гуйм шудас
5. Қўшиқ Бузғола
6. Халқ ўйини Сандурчайи қутича
7. Қўшиқ Вой поям
8. Қўшиқ лапар Солинав Муборак
9. Қўшиқ айтишув Дупар газит
10. Қўшиқ санама Учтурбачамон.

**Бобажон қўшиғи**

Болалар узоқдан бобони кўриб қоладилар ва унга яқинлашадилар, салом берадилар кейин ундан эртак айтиб беришни илтимос қиладилар. Бобо кўнмайди, зўрға уни эртак айтиб беришга кўндирадилар. Н-т:

Бобо бобо пештар бет,
Дамо яктет ушуг гуед
Бобо-бобо бобочае
Фалак-фалак зомичае.
Нукра-нукра намакдоне
Тилло –тилло сўзандоне.
Н-т:
Бобо бобо пештар бет,
Дамо яктет ушуг гуед
Кашвак-кашваки сурхане
Да пойга – пойга монаме
Салли-Сали симобине
Да бухча-бухча монаме.

Н-т:

Бобо бобо пештар бет,
Дамо яктет ушуг гуед

Ҳамма Бобожон эртак айтиб беринг.

Шу тариқа ўйин ва қўшиқлар ижро этилиб, бир-бирига уланиб кетади.

Мактабда бошланғич синф ўқувчиларини халқ мусиқаси ва шу ўринда Бухоро болалар фолклор намуналари билан зарур эҳтиёжни қондирадиган даражада таништириб бориш энг биринчи навбатда мусиқа ўқитувчиларидан ўз касбига фидойиликини, халқ мусиқа ижодиётига чуқур муҳаббат ва юқори даражадаги касбий маҳоратни талаб қилади. Дарс жараёнига Бухоро болалар фолклор қўшиқларини самарали тадбиқ этиш ўз ўрнида бир қатор вазифаларни ижобий ҳал этишни ҳам таъкидлаш ўринлидир.

Хуллас, Бухоро болалар фолклор қўшиқлари орқали ўқувчи-ёшларни мусиқий маданиятини, маънавий ва бадиий эстетик тарбиялашнинг педагогик ва методик тизимини яратиш, бугунги кунгача тўпланган мавжуд тажрибаларни ўрганиш, турли вилоятларда фаолият юритаётган фолклор-этнографик ансамбиллар фаолиятини ўрганиш, улар репертуаридаги Бухоро болалар фолклорига тегишли намуналарни тўплаш, умумлаштириш ва таълим жараёнига тадбиқ этиш орқали мусиқий таълимнинг миллий асосларини мустаҳкамлашга эришиш мумкин.

**Литература**


1. Ражабов Т.И. Тематическая классификация узбекской детской народной музыки игр. – М.: Наука, 2020. – С. 61-63.
2. Ражабов Т.И., Ибодов У.Р. Обеспечение национального наследия в обучении песням бухарского детского фольклора на уроках музыки // Вестник науки и образования. – 2020. – С. 55-58.
3. Раджабов Т.И. Описание вековых ценностей в песне «тутовое дерево-балх» и его место в воспитании учащейся молодежи. – Ташкент, 2019. – С. 70-71.
4. M.B. Kh, TI Rajabov, FG Nurullaev. Teaching Bukhara children folk songs in music lessons as an actual problem. International Journal of Psychosocial Rehabilitation. 24 (04), 6049-6056.


# ВИДЫ ИНТЕРАКТИВНЫХ МЕТОДОВ ОБУЧЕНИЯ В ТАТАРСКОМ И АНГЛИЙСКОМ ЯЗЫКАХ И ЛИТЕРАТУРАХ


*Пайгина М., КФУ, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ашрапова А. Х.*


Интерактивные методы обучения (interactive learning methods) – методы обучения, построенные на активном взаимодействии обучающихся с преподавателем, контентом и между собой в коллаборативном обучении (collaborative learning). Учебный процесс организуется с учетом включенности в процесс познания всех обучающихся группы без исключения. При совместной деятельности каждый вносит индивидуальный вклад, тем самым в ходе урока происходит обмен идеями, знаниями и навыками. Интерактивные методы основаны на принципах взаимодействия, активности обучаемых и обязательной обратной связи. При подобной работе создается среда образовательного общения, которая характеризуется

открытостью, взаимодействием участников, а также возможностью взаимной оценки. Данные методы обучения призваны решать главную задачу, сформулированную в ФГОС – научить ребенка учиться.

В современной системе образования существуют множество видов интерактивных методов, благодаря которым уроки становятся познавательными и занимательными. На конкретных примерах рассмотрим несколько из них.

Сюжетно-ролевые игра – вид деятельности, в процессе которой ученик примеряет на себя поведение, отношения и действия людей. При данном методе дети учатся играть разные роли, выражать свою позицию, влиять на других участников, вести диалог и находить компромисс, решать конфликтные ситуации. Более того сюжетно-ролевая игра помогает закрепить пройденный материал. Одной из разновидностей сюжетно-ролевый игры является драматизация. Например, после прохождения различных тем (семья, путешествие, еда, преступление) ученики могут отыграть разные роли, работая в группах по 7-10 человек. Для лучшего запоминания произведений по литературе детям советуется театрализовать его. Сюжетно-ролевая игра подходит для учеников младшей и средней школы.

Игры на ассоциации. Данный метод интерактивного обучения улучшает память и внимание, развивает образное и логическое мышление, обогащает словарный запас и помогает быстрее запомнить материал. Игры на ассоциации бывают нескольких видов: вербальные (на словах), образные (с использованием изображений), предметные (с применением предметов). Данный метод успешно применяется в изучении иностранных языков. На уроках литературы игры на ассоциации можно использовать при изучении биографий писателей и поэтов, героев какого-либо произведения, а также важных деталей в рассказах. Вышеизложенный метод подходит для учеников младшей и средней школы.

Мини-исследование. Данный метод учит детей собирать и анализировать данные и формулировать их, подбирать факты для ее обоснования или опровержения, защищать свою точку зрения. Мини-исследование можно использовать во всех уроках. При формулировании выводов исследования дети могут придумать креативные задания, используя приложения WordWall, Kahoot, Woodwardenglish и другие. При вышеописанном методе дети ничем не ограничены. Они включают свою креативность и работают по-своему усмотрению. Метод предназначен для учеников младшей, средней и высшей школы. Примером мини-исследования является эксперимент. Группа учеников определяет проблему и проводит эксперимент в

классе или дома, опрашивает других людей, собирает сведения, анализирует их.

Кейс-метод (разбор ситуаций) – интерактивный метод обучения, использующая описание реальных ситуаций. При этом дети учатся применять теоретические знания для решения практических задач; материал усваивается более эффективно за счет эмоциональной вовлеченности; развиваются коммуникативные навыки. Метод подходит для использования на уроках по любому предмету. Примером кейс-метода может послужить метод инцидентов. Ученики получают неполный кейс в виде краткого сообщения «Случилось...». Задача учащихся – разобраться в проблеме, определить, каких знаний не хватает для принятия решения. Они задают учителю вопросы и, получив достаточное количество сведений, анализируют их и выносят решение.

Интерактивная экскурсия. Занятие-экскурсия – это такая форма обучения, при которой обучающиеся воспринимают и усваивают знания на месте расположения изучаемых объектов и ознакомления с ними. Преимущество виртуальных экскурсий – не покидая кабинет ознакомиться с объектами, расположенными за пределами кабинета, города и даже страны. Это повышает информативность и производительность учебной деятельности. На уроках татарской литературы такими источниками могут послужить биографии писателей. Метод предназначен для учеников младшей, средней и высшей школы.

Таким образом, внедрение интерактивных методов обучения – одно из важнейших направлений совершенствования образования в школах. Их использование в процессе обучения позволяют приобрести: конкретному обучающемуся – и развитие личностной рефлексии; учебной группе – развитие навыков анализа и самоанализа в процессе групповой рефлексии, а также формирование единства коллектива.

**Литература**

1. Беспалько. В.П. Слагаемые педагогической технологии. – М.: Педагогика, 1989. – 182 с.

2. Иванов Д. А. Компетенции и компетентностный подход в современном образовании // Оценка качества образования / отв. ред. Л. Е. Курнешова. – М.: Московский центр качества образования, 2008. – С. 3-56.

## ҚАЗАҚ ТАТАР ТІЛІНДЕГІ СӨЗ ӘДЕБІНІҢ ЭТНОМӘДЕНИ СИПАТЫ

*Рамазан А., Абай атындағы ҚазҰПУ, IV курс студенті*

*Ғыл. жет. – аға оқытушы Бақбергенова Р.*

Адам баласы білімді, тәлім-тәрбиені тіл арқылы алады. Сонымен қатар мәдениетті, өнерді, ғылымды, техниканы тіл арқылы үйренеді. Тіл – ұлт ерекшеліктерінің бірі, ұлт мәдениетінің бір формасы. Қазақ

халқында: «Жақсы сөзге жан семірер, жаман сөз жанға тікен» деген нақыл сөз бар. Сөз әдебі күрделі ұғым. Ол фонетикалық, лексикалық, грамматикалық нормаларды қарастырып қана қоймай, тыңдаушыға жеткізетін сөзді жүрекке жылы жеткізу мақсаты да көзделеді. Сөз мәдениеті-тілдің бір бөлшегі, микросистема ретінде қарым-қатынас, яғни коммуникативтік қызметте жан-жақты ашылады, ал танымдық қызметінде ол жетекші роль атқармайды. Мәселен, дәстүрлі «*Қалың қалай?», «Не жаңалық бар?», «Мал-жан аман ба?»* сияқты қалыпты сұрақтар анық жауапты талап етпейді. Бұл сұраулы сөйлемдер өз кезегінде айтылуға тиіс болғандықтан, оған дәстүрлі «*Шүкір!» «Өзіңде не жаңалық бар?»* деген тәрізді қалыпты жауаптар беріледі. Бұл мысалдар (сөз орамдары) сөйлеушілердің әңгімені бастап кетулеріне «кілт», яки бір нәрсені сұрау, оған жауап беру қызметінде емес, негізінен, қарым-қатынасты үзбеу, жалғау қызметін де атқарады.

Однако зачастую школьный учитель использует уже имеющиеся материалы без возможности выбора, поэтому необходимо использовать дополнительные методы просвещения учащихся. Для оптимальной работы с аспектом культуры, очевидно, необходимо использовать аутентичные материалы, которые бы в полной мере отвечали требованиям урока и возрасту учеников. На наш взгляд, наиболее подходящим средством для этого является аутентичное видео. Необходимость использовать аутентичный материал мотивируется тем, что передача «национального духа» через учебные подготовленные материалы не представляется возможным. Аутентичные материалы располагают полной информацией о культуре английского языка, а их сказочный нарратив может помочь учителю

удержать фокус внимания учащихся на материале. Выбор аудиовизуального средства является ключевым, так как развитие навыков аудирования является важнейшим для подготовки учеников к процессу ведения диалога на изучаемом языке. Визуальный же ряд улучшает общее понимание звучащего текста за счет невербальных средств коммуникации.

Для введения в процесс обучения аутентичного видео, которое поможет познакомить учеников с культурой Великобритании, можно обращаться к отдельным видео, которые ярко описали бы героев фольклора. Например, для знакомства учащихся с таким героем, как Леприкон (A leprechaun) учитель может предложить ученикам видео по мотивам народной сказки Pot Of Gold. Данное видео является аутентичным анимированным материалом, с помощью которого учащиеся могут познакомиться с самим героем, его особенностями и характеристиками. Учитель может расширить понятие учеников об особенностях английского языка, связывая историю о том, что на конце радуги можно найти Леприкона с горшочком золота, с идиомой *chase a rainbow*.

Однако, учитывая, что учащимся может быстро наскучить классическая репрезентация мифологический существ, учитель может использовать более современные анимационные или кино-адаптации фольклорных героев. Так мультфильм Gravity Falls может стать путеводителем учащихся в мифологизированное сознание британцев и познакомить их с фольклорными существами. Gravity Falls располагает огромным спектром героев – от более современных (Бигфут, Зомби) до ранних мифологических (единорог, гномы, гремлины, лилипуты, русалки, феи, трикстер т.д.). Обилие героев и удобная членимость серий (1 серия – 1 мифический герой) позволят учителю постепенно познакомить учеников с большим количеством мифологических существ. Использование же дополнительной информации об изученных героях только укрепит их знания о мифологии интересующих стран.

Итак, знакомство учащихся с культурологической стороной языка и стран-носительниц может позитивно сказаться не только на формировании языковых навыков и развитии личностных качеств, но и стать стимулом к изучению языка, углубиться в проблему его особенностей. Использование же актуальных для учащихся материалов может способствовать активному усвоению информации и формированию интереса к фольклорному базису языка, что исключительно позитивно отразится на мотивации учащегося к изучению английского языка.

**Литература**

1. Гальскова Н.Д. Современная методика обучения иностранным языкам: Пособие для учителя. – М.: АРКТИ-ГЛОС-СА, 2000. – 70 с.
2. Evans V. Spotlight 7. – М.: Просвещение, 2016. – 11, 21, 31, 61, 71, 81, 91, 101 с.
3. Яковлева Л.Н. Межкультурная коммуникация как основа обучения второму иностранному языку // Иностр. языки в школе. – 2001. – №6. – С. 4-6.

# ЯЗЫКОВАЯ КАРТИНА МИРА В АСПЕКТЕ МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ

*Хамидова Ш. БухГУ, студент II курса*

*Науч. рук. – ст. преп. Болтаева М.Ш.*

Межкультурная коммуникация как научно-прикладная дисциплина занимается проблемами понимания и взаимопонимания: понять чужое (другое), адекватно объясниться с чужим, правильно интерпретировать иные, не свои культурные знаки. В плане своего генезиса, предметной соотнесенности, а также с точки зрения исследовательского инструментария, межкультурная коммуникация имеет междисциплинарный статус. Она интегрирует знания ряда наук, таких как культурная антропология, лингвистика, прагмалингвистика, теория коммуникаций, этнопсихология, социология.[1].

Существуют два подхода к определению сущности межкультурной коммуникации: лингвистический, относящий процессы межкультурной коммуникации по природе к речевой деятельности; культурно-антропологический (собственно её и породивший как термин и как новую дисциплину), опирающийся на достижения многих наук.[2].

Лингвисты В.Г. Костомаров и Е.М. Верещагинов в рамках разработанной ими в 80-х годах лингвострановедческой теории слова определяют межкультурную коммуникацию как «адекватное взаимопонимание двух участников коммуникативного акта, принадлежащих к разным национальным культурам».

Межкультурная коммуникация, т.е. общение языковых личностей, принадлежащих различным лингвокультурным сообществам, представляет собой процесс общения (вербального и невербального) между коммуникантами, являющимися носителями разных культур и языков.

Языковая картина мира – «совокупность сведений о мире, активизируемых с помощью различных механизмов вербализации, а также хранимых и передаваемых от поколения к поколению с помощью вербального кода; часть «картины мира вообще, которая опосредована языковыми знаками или даже – шире – знанием языка, его единиц и правил и, главное, содержанием его форм» [3].

Концептуальная картина мира – «динамическое образование в сознании человека, служащее обработке информации о мире и одновременно накапливающее эту информацию в обобщенном виде». [4].

Вопрос о соотношении культурной (понятийной, концептуальной) и языковой картин мира чрезвычайно сложен и многопланов. Его суть сводится к различиям в преломлении действительности в языке и в культуре. В книге «Человеческий фактор в языке» приводится утверждение, что концептуальная и языковая картины мира соотносятся друг с другом как целое с частью. Языковая картина мира – это часть культурной (концептуальной) картины, хотя и самая существенная.

Язык – часть культуры, но и культура – только часть языка. Значит, языковая картина мира не полностью поглощена культурной, если под последней понимать образ мира, преломленный в сознании человека, то есть мировоззрение человека, создавшееся в результате его физического опыта и духовной деятельности». [5].

Итак, окружающий человека мир представлен в трех формах: – реальная картина мира, – культурная (или понятийная) картина мира, – языковая картина мира. В вопросе изучения языковых картин мира большой интерес вызывают билингвы, то есть люди, которые имеют два родных языка, а также преподаватели иностранных языков и переводчики, которые профессионально владеют другими языками. В сознании билингвов сосуществуют одновременно две языковые картины мира, у специалистов по иностранным языкам вторичная языковая картина мира накладывается на первичную, сформированную родным языком.

Таким образом, специфика языковой картины мира заключается, прежде всего, в культурно-специфической лексике и фразеологии. Языковая картина мира играет важную роль в изучении иностранных языков. Выучив иностранное слово, человек как бы извлекает кусочки мозаики из чужой картины и пытается совместить его с имеющейся в его сознании картиной мира, заданной родным языком.

Взаимодействие первичной и вторичной языковых картин мира – сложный психологический процесс, требующий определенного отказа от собственного «я» и приспособлению к другому видению мира. Под влиянием вторичной картины мира происходит переформирование личности.

**Литература**

1. Анисимова Е.Е. Лингвистика текста и межкультурная коммуникация: Учебное пособие для студ. фак. иностр. яз. вузов. – М.: Издат. центр Академия, 2003. – 128 с.

2. Балыхина Т.М. Методика преподавания русского языка как неродного (нового): Учебное пособие для преподавателей и студентов. – М.: Изд-во Российского университета дружбы народов, 2007. – 185 с.

3. Болтаева М.Ш. Языковая картина мира в психологическом формировании мировоззрения учащихся // Филология ва методика масалалари. – Ташкент: «Навруз» нашриёти., 2017. – Б. 120-123.

4. Верещагин Е.М., Костомаров В.Г. Язык и культура. – М.: Русский язык, 1990. – 266 с.
5. Воробьев В.В., Саяхова Л.Г. Русский язык в диалоге культур. Элективный курс для 10–11 классов школ гуманитарного профиля: Учебное пособие. – М.: Ладомир, 2006. – 286 с.

## ИСТОРИЯ ФОНЕТИКИ АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА НА РУБЕЖАХ XX-XXI ВЕКОВ

*Хасанова Д., КФУ, студент III курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ашрапова А.Х.*

Современный английский язык – это результат длительного исторического процесса. Несмотря на влияния других языков, таких как французский, скандинавский во времена воин и завоеваний, английский язык упорно продолжал развиваться внутри себя. Развитие промышленности, появление новых технологий, развитие экономики и политики, общение с иностранными государствами также способствовали расширению и пополнению словарного состава, совершенствованию фонетического и грамматического строя [1: 260]. Изменения в области фонетики претерпели длинный путь, чтобы достичь такой вариант, который изучают современники.

Как известно, учёные разных стран были заинтересованы в изучении природы произношения звуков. Они пытались сформулировать концепцию фонетической системы звуков. Выделялись несколько подходов, однако самым выдающимся и часто использующимся в современном языке считается теории Д. Джоунса. Представленная Д. Джонсом работа в 1917 году «Система кардинальных гласных», вызвала интерес у британских деятелей. Благодаря фонетисту Э. Батчеру данная теория стала популярной в обучении произношения студентам из-за довольно простого и доступного языка объяснения [4: 852].

Одним из последователей Д. Джонсана был Гарольд Пальмер – английский лингвист. Он в своём труде «Prosodic Analysis» обращает внимание на структурные единицы интонации: начало, заглавие, верхушка (ядро), заключение. Темой интонации также интересовались такие британские учёные как; Д.Д. О’Коннор, Дж. Ф. Арнольд, Л. Шубигер, К. Квирк, А. Джейсем [4: 854].

1912 год можно условно описать, как новый этап в фонетике. В это время благодаря деятельности Л. В. Щерба появилась грань в изучении звукового строя. Он продолжил деятельность Бодуэна де Куртенэ и развил концепцию «фонемы», придав ей современный вид [5: 20].

В конце XX в Англии происходили колоссальные изменения, связанные с иммиграцией темнокожих, появлением инновационных технологий, появлениями субкультур. В данный период известны

следующие лингвисты, фонетисты: Уильям Лабов, Питер Ладефогед, Джон Кунисон Кэтфорд.

Уильям Лабов – американский лингвист, в начале 1970 года исследовал лингвистические особенности афроамериканского народного английского (AAVE). Он также изучил более современные изменения, произошедшие в фонетике; произношение в Соединённых Штатах Америки; модель цепных сдвигов гласных. Его труды высоко ценились, к ним относятся: «Изучение нестандартного английского языка» (1969), «Язык во внутреннем городе: исследования чернокожего английского языка» (1972), «Социолингвистические паттерны» (1972), «Принципы языковых изменений».

Питер Ладефогед – британский лингвист, собирал данные по исчезающим языкам по всему миру. Он оставил огромное наследство своего труда: «The nature of vowel quality» 1962, «Elements of acoustic phonetics. University of Chicago Press» 1962, «A phonetic study of west African languages» 1964, «Three areas of experimental phonetics» 1967, «Preliminaries to linguistic phonetics» 1971, «A course in phonetics» 1975, «The Sounds of the World's Languages» 1996, «Vowels and consonants: An introduction to the sounds of languages» 2001.

Джон Кунисон Кэтфорд – британский лингвист и фонетик. Егоработы: «A Practical Introduction to Phonetics», «Fundamental Problems in Phonetics», «Word-stress and sentence-stress: a practical and theoretical guide for teachers of Basic English», «A Linguistic Theory of Translation», «Ergativity in Caucasian Languages».

В XXI веке английский язык приобретает всемирную популярность, становится мировым языком, на нём желают говорить люди из разных уголков мира. Следовательно, растёт спрос на обучение данному языку в детских садах, школах, университетах [2]. Исходя из этого, появляется потребность в новых методах обучению английскому. Одним из знаменитых современных методистов является Джереми Хармер. Он является автором методических публикаций: «How to teach English», «The Practice of English language», «Teaching» and «How to Teach Writing». Джереми Хармер считает, что учителя заставляют студентов изучать грамматику и лексику, практиковать навыки аудирования и чтения, не уделяя при это должного внимания произношению должного. Однако обучение фонетике помогает ученикам развивать речь и выражать свои мысли правильно. Сосредоточение внимания на звуках, где они воспроизводятся; расстановка правильного ударения и интонации – все это дает обучающимся информацию о разговорной речи на английском языке и помогает достичь цели улучшения понимания и разборчивости слов.

Следующим современным методистом является Джеральд Келлой - опытный преподаватель и тьютор. Он является автором книги «How to Teach Pronunciation» (Longman, 2000), которая призвана помочь учителям получить теоретические знания, а также улучшить навыки преподавания. Джеральд также пишет учебные материалы для веб-сайтов, где предлагает множество практических идей, навыков для занятий в классе. Книга показывает учителям, как сочетать произношение с грамматикой и лексикой, чтобы заинтересовать учеников [3: 154].

Исходя из вышеизложенного, следует сделать вывод, что фонетика занимает неотъемлемую часть в изучении языка. Она развивалась на протяжении тысячелетий и до сих пор продолжает трансформироваться. Произношение зависит от людей и эпох, в которых они жили. Нельзя не упомянуть, что современный английский язык является одним из сложных в объяснении правил фонетики, ведь во многих случаях, нельзя дать точный ответ на вопрос: «Почему в данной ситуации звук должен произноситься именно так?». Единственный верным ответом часто бывает – данный случай нельзя аргументировать, так как это исторический аспект. Многие учёные проделали огромный труд, чтобы современники могли понять, что такое наука фонетика.

**Литература**


1. Аракин В.Д. История английского языка: Учеб. Пособие. – 2-е изд. – М.: ФИЗМАТЛИТ, 2003. – 272 с.
2. Иванова Е. Значение английского в современном мире https://www.englishdom.com/blog/znachenie-anglijskogo-v-sovremennom-mire/ (дата обращения: 27.01.22).
3. Келлой Дж. How to Teach Pronunciation: Учеб. Пособие. – 1-е изд. – Pearson Education Limited, 2000. – 154 с.
4. Короткова М.Д., Богачева Е.А. Эволюции фонологической теории Д. Джоунза в современной английской фонологии // ООО «Грамота», 2021. – С. 851-855 https://cyberleninka.ru/article/n/evolyutsiya-fonologicheskoy-teorii-d-dzhounza-v-sovremennoy-angliyskoy-fonologii/viewer (дата обращения 26.01.22).
5. Салимова Р.М. Фонологические подходы к изучению фонемы как многогранной единицы языка // Вестник ЮУрГУ. Серия «Лингвистика». – 2018. – Т. 15. – № 1. – С. 16-23.


## ОБУЧЕНИЕ ЧТЕНИЮ НА НАЧАЛЬНОМ ЭТАПЕ ИЗУЧЕНИЯ ИНОСТРАННОГО ЯЗЫКА


*Хафизова А., КФУ, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ашрапова А.Х.*


Чтение обогащает человека, позволяет ему глубже познавать окружающий мир, тем самым чтение занимает важное место в жизни человека. Чем больше мы читаем, тем больше расширяем запас слов, эрудицию, укрепляем навыки письма и способность правильно

говорить. Поэтому так важно с детских лет привить любовь к чтению, интерес к книге и показать ее роль в жизни человека, вооружить учащегося умением читать – соответствующим уровнем технических навыков, осмысленным чтением вслух и молча, и умением работать с разными видами текстов и детской книгой [1: 304].

Чтение – специфическая форма языкового общения людей посредством печатных или рукописных текстов, одна из основных форм опосредованной коммуникации.

В современной педагогике чтение рассматривают как один из видов речевой деятельности. А речевая деятельность представляет собой активный, целенаправленный, опосредованный языковой системой и обусловленный ситуацией общения процесс передачи или приема сообщения.

Следовательно, речь – это язык в действии, общении. Когда мы принимаем сообщения, мы слушаем или читаем; когда передаем сообщения, мы говорим или пишем. Таким образом, существует четыре вида речевой деятельности, связанные между собой: слушание и чтение, говорение и письмо.

Чтение более тесно связано со слушанием, так как в обоих процессах принимается сообщение. Чтение относится к письменным видам общения (как и письмо) [3: 207].

Речевая деятельность и чтение имеет определенную структуру, предметное содержание, речевые механизмы. В структуре речевой деятельности выделяется три уровня.

Первый – мотивационное звено, наличие мотивов и цели действия.

Второй уровень – ориентировочно-исследовательский, уровень планирования, внутренней организации речевой деятельности.

Третий уровень – исполнительский. Результатом работы с текстом становится его понимание.

Итак, предмет речевой деятельности – мысль, а результат – ее понимание.

Важно сформировать изучающее чтение в двух формах – вслух и молча (про себя). Чтение вслух предназначено для слушателей, т. е. это четкое, внятное, безошибочное чтение целыми словами, в нормальном темпе. В школьном обучении оно способствует орфоэпической грамотности, формированию навыков восприятия.

Чтение про себя – это чтение глазами, без внешних речедвижений. Наличие шевеления губами не является чтением про себя. Чтение про себя также необходимый компонент в обучении чтению, потому что правильно поставленное молчаливое чтение способствует развитию

самостоятельности учащихся при восприятии и усвоении ими содержания читаемого.

Работа по формированию всех качеств полноценного чтения осуществляется в ходе изучения текста, а также на специально структурно выделенных частях урока чтения: на речевой гимнастике и пятиминутке чтения.

Овладение основами техники чтения молча должно происходить параллельно с обучением чтению вслух. При этом соотношение этих форм должно постепенно изменяться в пользу первого (молча).

На этапе овладения грамотой ведущее место принадлежит чтению вслух, с которым чтение молча должно чередоваться (70 и 30%).

Современная методика понимает навык чтения как автоматизированное умение по озвучиванию печатного текста, предполагающее осознание идеи воспринимаемого произведения и выработку собственного отношения к читаемому. В свою очередь такая читательская деятельность предполагает умение думать над текстом до начала чтения, в процессе чтения и после завершения чтения. Именно такое «вдумчивое чтение», основанное на совершенном навыке чтения становится средством приобщения ребёнка к культурной традиции, погружение в мир литературы, развития его личности. «При этом важно помнить, что навык чтения - залог успешного учения, как в начальной, так и в средней школе, а также надёжное средство ориентации в сложном потоке информации, с которыми приходится сталкиваться современному человеку» [2: 370].

В методике принято характеризовать навык чтения, называя четыре его качества (критерия): правильность, беглость, сознательность и выразительность.

**Литература**

1. Бьюзен Т. «Учебник быстрого чтения». – М.: Попури, 2019. – 304 с.

2 Жинкин Н.И. Механизмы речи / Акад. пед. наук РСФСР. Ин-т психологии. – М.: Изд-во Акад. пед. наук РСФСР, 1958. – 370 с. – URL: https://search.rsl.ru/ru/record/01006184637 (дата обращения: 02.12.2021).

3. Клычникова З.И. Психологические особенности обучения чтению на иностранном языке: тема Пособие для учителя. – М.: Просвещение , 1983. – 207 с.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БУЛҮНЕ БЕЛДЕРҮЧЕ ДЕСТРУКТИВ ФИГЫЛЬЛӘР

*Хафизова Г., М.Акмулла ис.БДПУ, V курс студенты*

*Фән.җит. – филол. фән. канд., доц. Халиуллина Н.У.*

«Деструктивлык» төшенчәсенең асылы төрлечә аңлатыла. Киң мәгънәсендә «Деструкция – нәрсәнең дә булса гадәти структурасының бозылуы яки җимерелүе» А.М. Бабкин һәм В.В. Щендецов авторлыгындагы «Словарь иноязычных выражений и слов» хезмәте деструкцияне «җимерү» буларак карый, ә «Краткий словарь

современных понятий и терминов» сүзлеге «деструктив» сыйфатына түбәндәге аңлатманы бирә: «җимерүче, билгеләнгән тәртипне, формалашкан нормаларны бозучы» [2: 168].

Деструкциянең түбәндәге әһәмиятле билгеләрен аерыла: 1) таркату, җимерү, үзгәртү, ниндидер объектларның формасын бозу һәм, деструкция нәтиҗәсе буларак, юкка чыгару; 2) төрле көчләр (механик, физик һәм башкалар) тәэсирендә нәрсәнең дә булса структурасын теләсә ничек үзгәртү һәм объектның элек аңа хас булган функцияләрен үти алмый башлавы; 3) температура, химик элементлар, микробиологик объектлар, табигый хәлләр һәм башкалар тәэсирендә объектның җимерелүе һәм моның үз-үзен җимерүе дип кабул ителүе.

Деструктив фигыльләрнең киң таралганнары – механик деструкция фигыльләре. Алар объект мөнәсәбәтен белдерәләр һәм гадәттә күпмәгънәле булулары белән аерылып торалар. Бу төркемнәрнең нигезе булып "бүлү, аеру, үзгәртү, зыян китерү, таркату, эшкәртү, чоку, казу" семалары тора.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә ***бүлү*** лексемасының сигез мәгънәсе күрсәтелә**:**

1) кисәкләргә, өлешләргә аеру; өләшү; хаслап аеру, атап билгеләү; аерып кую, бирү. Мәсәлән, *Авылны икегә бүлеп аккан инеш ярның читенә килдем* (С. Баттал);

2) төркемләү; төркемнәргә, төрләргә аерып карау. Мисал өчен шундый җөмлә китерергә мөмкин. *Эшне бүлгән выкытта һәркем үзе өчен бик кирәкле булган эшне эшли* (Г. Тукай);

3) бүлешү, уртаклашу кебек билгеләргә ия. Мәсәлән*, Соңгы телемен бүлде ул Үзенең халкы белән* (Н. Думави);

4) бер санның икенче санны ничә мәртәбә үз эченә алганлыгын белү; киресе: тапкырлау. Мәсәлән, *Беренче класста бүлү гамәлен өйрәнәләр* (Г. Бәширов);

5) туктатып өзеп тору (эшне, уйларны) фикерләрне бүлү. Мәсәлән, *Ташу суы минем юлымны бүлә* (М. Хуҗин);

6) ясау, кору (бүлмә, бүлемтек һ.б). Мәсәлән, *Председатель, канцеляриянең сул яклап такта белән бүленгән кечкенә ягына – "үзенең кабинетына" кереп, тунын, бүреген салды.* (Ә. Еники);

7) бирү, сарыф итү (көчне, вакытны). Мәсәлән, *Сина эшкә киләбез, сиңа көчне бүләбез. Яшәртәбез сине җир!* (М. Җәлил);

8) әзер продуктларны, иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән чыгып, җәмгыять членнары арасында урнаштыру, аларга бирү, өләшү. Мәсәлән, *Хезмәт көненә, былтыргы кебек, сигезәр-тугызар килодан бүлик* (Г. Әпсәләмов). [1: 476].

Бүлүне белдерүче фигыльләрнең деструктив билгеләре:

1) өлешләргә бүлү: бәлешне, алманы, бүрәнәне: *Бүрәнәне кискәләү;* 2) кем белән булса да кисәкләргә бүлешү, кисәкләү, кисеп, вак кисәкчекләргә, кисәкләргә бүлү: бәлешне, алманы, пирогны (*Бәлешне кире алып чыктылар һәм кисәкләп яңадан керттеләр* (Ә. Фәйзи).

Объектның нинди булуыннан чыгып, “бүлү” семасы ***табаклау*** – табакларга бүлү, бүлгәләү (калайны, кәгазьне): *Калайны табаклап сату,* ***телү*** – пычак белән телү, бүлгәләү: *Аркылы такталарның байтагын чыралыкка теләләр* (К. Нәҗми); ***яру*** – берәр үткен нәрсә белән буйга кисү, вак кисәкләргә бүлү (тактаны, утынны, түмәрне): *Ул, юып, ярып, котелок өстенә бәрәңге салды да, аркылы таяк куеп, шуңа котелокны элде* (Ф. Кәрим) фигыльләре дә керә.

Бүлү фигыленә ***аеру*** сүзенең мәгънә төзелеше якын. Ул бөтенне яки тоташ нәрсәне ике яки берничә кисәккә, өлешкә бүлү, яру, ике яки берничә итү дигәнне аңлата. Мәсәлән, *Бозлар чатнап-чатнап ярылдылар, баракны урталайга аердылар* (А. Алиш). Аеру фигыленең түбәндәге мәгънәләре дә бар: а) Ике яки берничә нәрсә арасында чик булдыру, чик ясау; әйберләрне бүлү. Мәсәлән*, Чәч аермасы, чәч юлы ясау. Хуш исле чүмеч гөлләр арасыннан чәчен уртадан аерып, ике толым итеп үргән яшь кыз күренде* (Г. Әпсәләмов); б) Бергә янәшә булган ике яки берничә кешене (яки нәрсәне) бер-берсеннән ераклаштыру: *Адәмне генә түгел, кошларны да Еллар үз иленнән аера* (Һ. Такташ); в) Аерма барлыкка китерү, төрле-төрле итү. Мәсәлән, *Аны биек каракүл папахасы да башка командирлардан аерып тор.* (Г. Бәширов) [1: 476].

***Кубару*** фигыленең мәгънәсе дә кызыклы. Беренчедән, *кубару* – ябышкан, нык береккән нәрсәне аерып алу, җирлегеннән каеру: өйнең түбәсен, ябыштырылган кәгазьне. Мәсәлән, *Кригер патша рәсеме астына ябыштырылган кәгазьне кубарып ала да укый* (Т. Гыйззәт). Икенчедән, күтәрү, чыгару мәсәлән, тузан, давылда шушы фигыльләр белән белдерелә: *Акларның җияүлеләре, атлылары тузан кубарып монда таба чабалар* (Г. Бәширов).

Димәк, бүлүне белдерүче деструктив фигыльләр кечкенә лексик система тәшкил итәлә.

**Әдәбият**

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Т.I-III. – I – Казан, 1977. – 476 с; II – Казан, 1979. – 726 с.; III – Казан, 1981. – 832 с.

2. Фаткуллина Ф.Г. Способы выражения переносных значений в поэтическом тексте (на материале деструктивной лексики) //Язык. Система. Личность. Материалы докладов и сообщений международной научной конференции. – Екатеринбург, 1998. – С. 168-169.

## “НӘҖИП” ҺӘМ “АЙ ӨСТЕНДӘ ЗӨҺРӘ КЫЗ” ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИЛЕК АЛЫМНАРЫ ҺӘМ ЧАРАЛАРЫ

*Хәбибуллина А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гыйлаҗев Т.Ш.*

Татар телендә белем бирү оешмаларында XX йөз башы татар язучысы – Ф. Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты өйрәнелә. Мәктәпне тәмамлаганда, укучылар татар әдәбиятының әдәби-тарихи, нәзари мәгълүматларыннан тыш, Ф. Әмирханның тормыш юлы һәм язучының күпьяклы әдәби эшчәнлеге белән дә таныша [4].

ФДББСна нигезләнеп төзелгән 5-11 нче сыйныф дәреслекләрен тикшерсәк, татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар Фатих Әмирхан иҗаты белән 5 нче сыйныфтан өйрәнә башлыйлар. ФДББС таләпләренә нигезләнеп төзелгән 5 нче сыйныф уку әсбабының авторлары – Ф.Ә. Ганиева һәм Л.Г. Сәбирова. Анда Ф. Әмирханның – “Нәҗип” һәм ”Ай өстендә Зөһрә кыз” хикәяләре тәкъдим ителә [1: 132]. Язучының иҗаты һәм тормыш юлы өйрәнелгәнче, хикәя турында нәзари мәгълүмат бирелә.

Әсәрләрдән соң бирелгән сорауларга килсәк, әлеге хикәяләргә әдәби образ аша мәдәни тәңгәллекне формалаштыруга караган сораулар бирелә. Мәсәлән, 1) Зөһрәнең портретын тасвирлаган сүзләрне табыгыз (“Ай өстендә Зөһрә кыз”); 2) Кызның тышкы матурлыгы белән эчке дөньясы тәңгәл килме? Аңа нинди сыйфатлар хас? (“Ай өстендә Зөһрә кыз”); 3) Хикәянең башындагы Нәҗип белән аның ахырдагы Нәҗип белән чагыштырыгыз? Аерма бармы? (“Нәҗип”); 4) Һөнәр – утта янмый, суда батмый торган хәзинә” дигән мәкальне Нәҗип мисалында аңлатыгыз. (“Нәҗип”)

“Нәҗип” хикәясенең төп герое Нәҗип исемле бала. Белгәнебезчә, Ф. Әмирхан – оста психолог. Ул хикәясендә 11-12 яшьләрдәге балалар кичергән хис- кичерешләрне төгәл сурәтли. Нәҗип нәкъ 5 сыйныфта укучы балаларга хас хис – үзен күрсәтү теләге белән яна. Ул макталырга теләп, төрле “батырлыклар” эшләп карый. Ләкин үз урынын таба алмау, аны борчый, тынычсызландыра. Әмма Нәҗип үз һөнәрен тапкач, бөтенләй башка якка үзгәрә. Ул инде “мине күрегез” дип батырлыклар кылмый, үзе башкара алган эшкә тотына. Рәсем ясау аңа көтелгән тынычлыкны алып килә. Ул ниһаять: «Аллага шөкер, хәзер минем дә инде бер һөнәрем була башлады бит!” – дип сөенә [2: 222].

Борынгыдан ук баланы эш-шөгыльле, һөнәрле итү турында кайгырту ата-ананың җаваплы бурычы булган. Хезмәт дөрес сайланган булса, бәхет кешене үзе эзәп таба дигән фикер яшәгән. Татар халкында һөнәрле булу бик мөһим. Моны татар халкының мәкалләре аша

аңларга мөмкин:“Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс”, “Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз” һ.б.

Шәхесне тәрбияләү максатында 5 сыйныф укучылары өчен әлеге әсәр бик файдалы дип уйлыйбыз. 11-12 яшьтә балаларда нинди дә булса түгәрәккә яки үзләренең оста якларын күрсәтү теләге уяна башлый. Балалык һәм яшьүсмерлек аралыгындагы укучылар үз-үзләрен эзлиләр. Әлеге әсәр аша алар үз урыныңны табу мөмкин дигән фикергә килә.

Моннан тыш, хикәядә татар халкына хас эш төрләре күрсәтелә. Һәр герой нинди дә булса һөнәргә ия. Мәсәлән, Гомәр матур итеп курайда уйный, Мәрфуга чигү белән шөгыльләнә. Шушы кечкенә детальләр аша татарларның тормышы, көнкүреш үзенчәлекләре ачыла.

Дәреслектә Ф. Әмирханның мифологиягә таянып иҗат ителгѐн “Ай өстендә Зөһрә кыз” әкияте дә бирелә [1: 136]. Сорау һәм биремнәр ике төркемгә бүленә: жанр һәм хикәя эчтәлегенең үзенчәлекләренә караган һәм автор позициясен укучыныкы белән чагыштыру өчен сораулар.

Геройларына килгәндә “Ай өстендә Зөһрә кыз” хикәсендә төп герой – Зөһрә. Ул – традицион кабул ителгән татар кызы итеп сурәтләнә. Ф. Әмирхан әлеге геройга татар кызларына хас булган сыйфатларны бирә. Зөһрә – татар кызлары турында күзаллауларның үрнәге һәм идеалы дип әйтергә мөмкин: “Айның нәкъ уртасында көянтә-чиләкләр күтәргән бер кыз басып тора бит. Ул татар кызы – Зөһрә кыз. Аның озын, бик озын кара чәч толымнары очында авыр-авыр чулпылар асылынып торалар. Аның озын керпекле оялчан кара күзләре җиргә карап торалар...” [2: 137]. “Беләсезме, ул кыз бик матур булган, ди. Аның керпекләреннән гөлләр тамган, тешләреннән нурлар чәчелгән, яныннан җофар исе килеп торган, ди” [2: 137]. Шулай ук, Зөһрәгә сабырлык, тырышлык кебек сыйфатлар да хас. Авыр чакта ул һәрвакыт Аллага ялвара, дингә сыена. Зөһрә образы аша татар халкының тормышында диннең нинди урын тотканын күрәбез.

Автор әкияте булганлыктан, хикәядә яхшылык-явызлык, үги ана, ай кебек үзенчәлекле детальләр бар. Хикәя татар халык әкиятләренә хас элементлар белән эшләнгән.

Әлеге әкият моңсу булуга карамастан, Ф. Әмирхан миф ярдәмендә балаларга айдагы “рәсемнең” Зөһрә булуын, Зөһрәне айга алып менгән йолдызны Зөһрә йолдыз дип атый башлауны бик уңышлы аңлата. “Үксез татар кызын айга илткән өчен ходай тәгалә аның нурын арттырган һәм фәрештәләр аңар “Зөһрә йолдызы” дип исем биргәннәр...” [2: 140]. Укучылар әлеге хикәя аша татар реалияләре белән таныша.

Гомумән, Ф. Әмирханның 5 сыйныф укучылары өчен тәкъдим ителгән хикәяләре уңышлы дип саныйбыз. Әлеге хикәяләр аша укучылар татар тормыш, көнкүреше, идеаллары турында күзаллау ала. Хикәяләр укучыларда шәхеснең һөнәре, максаты булырга тиеш дигән фикер тәрбияли.

**Әдәбият**

1. Әдәбият. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Ф.Ә. Ганиева, Л.Г. Сабирова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 175 б.

2. Әмирхан Ф. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 том. Хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 480 б.

3. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 4 том: XXйөз башы / [төз. Р.Ф. Рахмани; фән. мөх. Р.К. Ганиева]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 533 б.

4. Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләре (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа. / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан, 2013. – 36 б.

5. Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 311 б.

## ИНТЕРНЕТ-РЕСУРСЛАР ЯРДӘМЕНДӘ МӘДӘНИЯТАРА КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУ

*Хәмзина А., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сибгаева Ф.Р.*

Бүгенге көн кысаларында мәдәниятара компетенция формалаштыру бик актуаль булып тора. Бу җәмгыятьнең һәм шулай ук мәгариф системасының үсеше белән бәйле. Хәзерге заман төрле культураларның тәэсир итешүе, компьютер техникаларын киң куллану, телекоммуникация чараларының үсеше, җәмгыятьнең барлык өлкәләренең глобальләшүе, бигрәк тә интренет челтәрләрендә мәдәниятара һәм шәхесара аралашу көчәюе белән характерлана. Әлеге юнәлешләр мәгариф системасыннан укучыларны информацион җәмгыятьнең яңа шартларына әзерләүне таләп итә.

Мәдәниятара компетенөиянең формалаштыру проблемаларын татар, рус һәм чит ил галимнәре тарафыннан төрле аспектларда тикшерелә. И.И. Халеева, Н.В. Черняк, И.Л. Плужник, Н.Д. Гальскова, Ю. Рот, Р.Д. Льиюс, И.А. Зимняя, И.Л. Бим, А.А. Леонтьев, Е.С. Полат һ.б. мәдәниятара компетенциянең теоретик нигезләрен булдыралар.

Мәдәниятара коммуникатив компетенциянең асылын ачык итеп И.Л. Плужник билгели: ул (МКК) башка мәдәният вәкилләренең фикерләрен һәм карашларын функциональ аңлау осталыгын, коммуникация барышында конфликтларны җиңүне, төрле кыйммәтләрнең, үз-үзеңне тоту кагыйдәләренең яшәү хокукын тануны аңлата [2: 17].

Коммуникацияне булдыру өчен укучыларда табигый теләк һәм башкалар белән аралашу кирәклеген, үз-үзенә һәм үзенең көченә

ышанычны барлыкка китерә торган реаль аралашу моделен ясарга кирәк. Коммуникатив алым аралашуга өйрәтүне һәм мәдәниятара бәйләнешне формалаштыру сәләтен күздә тота. Бу Интернет функцияләвенең нигезе булып тора.

Башка илдәге яшьтәшләр белән аралашу электрон сообщенияләр аша башкарылырга мөмкин. Бу укучыларга хатны анализлауга һәм җавап турында уйлауга күбрәк вакыт бирә. Электрон хатлар белән алмашу — укучыларның коммуникация сыйфатларын һәм язу күнекмәләрен үстерүгә ярдәм итүче искиткеч чара. Яшьтәшләр белән чит телдә сөйләшү укучыларда мәдәниятара компетенцияне формалаштыра һәм белемнәрен арттыра [3: 5].

Уку процессының алдынгы этапларында укучыларда телдән сөйләм күнекмәләре булганда, өйрәнә торган мәдәниятнең вәкилләре белән “терелэй” аралашырга мөмкинлек биргән технологияләр кулланырга мөмкин. Шуларның берсе “Skype” сервисы бүгенге көндә иң киң таралганы булып тора.

Хәзерге заманда күп кенә дәресләрдә информацон технологияләр куллану зур популярлык казана. Шуңа күрә татар теле укытучылары үз дәресләрендә актив рәвештә интернет-ресурлар белән кулланалар. Ә бу үз чиратында интернет челтәрләрендә татар теленә кагылышлы материалларына ихтыяҗ арта баруга китерә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында татар теле дәресләре өчен шактый файдалы һәм кызыклы материаллар бар. Алар ярдәмендә укучыларда мәдәниятара компетенцияне формалаштырырга мөмкин.

“Укучының мәдәни көндәлеге” дигән проект кысаларында укучылар Татарстанның тарихи-мәдәни мирасы белән танышалар: төрле театрлар, кинотеатрлар, китапханә, музейлар, выставкалар, галереялар, һ.б. мәдәни учреждениеләргә бара алалар. Бу проект мәдәниятара компетенцияне формалаштыру яки үстерү өчен бик уңышлы. Башка культура вәкилләренә Татарстанның мәдәни мирасы белән танышу, ә татар балалары өчен үз республикасы белән тагын да ныграк кызыксыну өчен бар яклап уңайлы.

Татарстан һәм татар халкы тарихының электрон атласы "Tatarhistory" ярдәмендә төбәк халкы, аның шөгеле үзгәреше, материаль һәм рухи кыйммәтләр ничек барлыкка килгәне, яхшы күршелек традицияләре һәм төрле халыкларның тыгыз элемтәсе ничек төзелгәне күрсәтелә. Укучылар республикабызның тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында мәгълүмат ала алалар [4].

Татар телен өйрәнүчеләргә Азатлык радиосы тарафыннан эшләнелгән “Әйдә! Online. Изучаем татарский” дип исемләнгән проект

та бар. Бу интернет-ресурс татар телен берничә курста өйрәнүне күз алдында тота. Шулай ук бу проект кысаларында татар һәм чит ил язучыларның әсәрләрен оригиналда һәм тәрҗемә белән тыңларга яки укырга мөмкин. Бу үз чиратында нәкъ менә мәдәниятара компетенцияне формалаштыру яки үстерү өчен бик уңайлы булып тора. Чөнки әдәби тәрҗемә — ул мәдәниятара коммуникация булдыру өчен төп нигезләрнең берсе булып тора.

Әлеге проект фото, видео, аудио материалларга һәм төрле кызыклы текстларга бик бай. Алар ярдәмендә үзеңдә татар теленең сүзлек составын арттырырга мөмкин. Ул гына да түгел, билгеле бер сүзләрне көндәлек тормышта коллегалар, дуслар белән аралашканда яисә эш урынында ничек итеп дөрес сайларга яки кулланырга өйрәтелә. Һәрбер дәрес алган белемнәрне тикшерү максатыннан тест белән тәмамлана [1].

Шулай ук укытучы үзе интернет-ресурслар ярдәмендә башка эш төрләрен дә укучыларга тәкъдим итә ала: электрон сүзлекләр белән эшләү, эзләү системаларын кулланып, төрле биремнәр эшләтү, YouTube челтәреннән видеоязмалар күрсәтү һ.б.

Алга таба да мәдәниятара компетенция формалаштыру үзенең актуальлеген югалтмаячак, чөнки көннән-көн башка мәдәният вәкилләре белән аралашу ихтыяҗы арта бара.

**Әдәбият**


1. Азатлык Радиосы сайты [Электрон ресурс] URL: https://www.azatliq.org/ (дата обращения: 27.01.2022).
2. Плужник И.Л. Формирование межкультурной коммуникативной компетенции студентов гуманитарного профиля в процессе профессиональной подготовки: автореф. докт. дисс. / И.Л. Плужник. – Тюмень, 2003. – 26 с.
3. Сысоев П.В., Евстигнеев М.Н. Современные учебные Интернет-ресурсы в обучении иностранному языку // Иностранные языки в школе. – 2008. – №6. – С. 2–10.
4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайты [Электрон ресурс] URL: https://mon.tatarstan.ru/tat/ (дата обращения: 27.01.2022).


## ТАТАР, БАШКОРТ ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫ: ЧАГЫШТЫРМА ЛЕКСИК-СЕМАНТИК АНАЛИЗ


*Хәсәнова А., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәлахова Р.Р.*


Теләсә кайсы халык телендә, кешеләр арасында туганлык мөнәсәбәтләрен билгеләү өчен хезмәт итә торган сүз төркемнәре аеруча зур кызыксыну уята. Әмма тел белемендә «термин» сүзе төрле һәм еш кына аныксыз мәгънәләрдә кулланыла.

Эшнең максаты итеп туганлык атамаларының татар телендәге тасвирламасын башкорт һәм төрек телләрендәге туганлык атамалары белән чагыштырып, әлеге телләрдә күзәтелгән уртак һәм аермалы якларны ачыклау билгеләнде.

Туганлык-кардәшлек атамалары галимнәрнең игътибарын күптән җәлеп итеп килгән. Аерым алганда, әлеге атамаларның морфологик билгеләрен өйрәнүне максат итеп куйган (Н.Э. Гаджиахмедов, 1985), яки төрки туганлык атамаларын башка телләр белән чагыштырма планда тикшергән (Б. Осмоналиева, 1983), шулай ук туганлык атамалары нигезендә кеше исемнәре ясалышын өйрәнгән (Т.Г. Таймасханова, 1985) хезмәтләр күзәтелә.

Лексик-семантик яктан сүз төркемнәрен аерганда, төп күрсәткеч буларак, аларның гомуми лексик мәгънәләре күрсәтелә. Мөстәкыйль сүзләр лексик-семантик яктан реаль лексик мәгънәгә ия, ягъни алар чынбарлык күренешләрен атыйлар, предмет, күренеш, билге, эш-хәлләрне белдерәләр, яки аларга гомуми рәвештә ишарә итәләр. Туганлык-кадәшлек атамалары нигездә исем сүз төркеменә карыйлар, әмма алар башка сүз төркемнәре ясалуга җирлек тә булып торалар. Фәнни хезмәтебездә туганлык атамаларын өч тел яссылыгында чагыштырма планда тикшерү барышында без аларның лексик-семантик үзенчәлекләрен тикшереп, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Татар һәм башкорт, төрек телләрендәге туганык атамаларының мәгънәләре ягыннан охшашлыклар һәм аермалыклар.

1) Татар телендә: ӘБИ ис. 1) Хатынының әнисе, әбкәй; 2) Өлкән яшьтәге хатын кыз, карчык [2: 741].

Башкорт телендә: ӘБЕЙ и. 1) Олы яштәге хатын кеше. 2) Олы яштәге кешенең хатыны.

Төрек телендә: ANNEANNE – дәү әни, нәнәй *диал.,* әби *сөйл.*

BABAANNE – дәвәни, әби *(гадәттә әтинең әбисе);*

BÜYÜKHANIM – әби.

EBE – 1) кендек әбисе; 2) *сөйл.* дәү әни.

Өч телдә дә “әби” дигән туганлык атамасы мәгънә ягыннан охшаш. Төрек телендә ул берничә термин белән белдерелә.

2) Татар телендә: АБЫЙ ис. 1) Үзеңнән олы ир туган. Дәү а. Уртанчы а.

Кече а.; 2) Өлкәнрәк ир-атка мөрәҗәгать иткәндә кулланыла [2: 16].

АГА ис. 1) Яшь ягыннан олы ир туган, абый. 2) Өлкән яшьтәге хөрмәтле, ихтирамлы кеше [2: 19].

Башкорт телендә: АГАЙ и. 1) Үзеңнән олы булган бер туган (бертуган кушылып язылырга тиеш) ир-ат. Олы агаем. Кече агаем. 2) Үзеңннән олы, ата-бабадан кече булган һәр ир-ат.

Төрек телендә: ABI – абый, агай, ага.

AĞA – 1) ага, агай; 2) абый; 3) хөрмәтле ир кеше;

AĞABEY – абый;

AMCA – 1) ага, агай, абый *(әтинең ир туганы, бигрәк тә энесе)*. 2) ага, абзый, абый *(үзеңнән өлкәннәрне атау һәм аларга эндәшү сүзе);*

EFE – 1) ага, агай; 2) егет.

EMMI – *сөйл.,* абый, абзый.

“Абый” термины татар, башкорт һәм төрек телләрендә бер төрле мәгънәне белдерә. Башкорт телендә ул “ағай” дип йөртелсә, татар телендә аның 2 варианты, ә төрек телендә берничә варианты бар.

3) Татар телендә: КАЕНАГА, КАЕНАГАЙ ис. Иргә карата хатынның абыйсы һәм киресенчә [2: 220].

Башкорт телендә: КАЙНАГА и. Ирнең агасы (хатынына карата) һәм хатынының агасы (иренә карата).

Төрек телендә: KAYIN – каенага, биага.

“Каенага, каенгагай” термины өч телдә дә бер төрле мәгънәгә ия, алар охшаш.

2. Туганлык атамаларына кушымчалар ялганып яңа сүзләр ясалу:

Барлыгы татар телендәге һәм төрек телендәге 20 термин каралды. Туганлык атамаларына кушымчалар ялганып ясалган берничә яңа сүзләрне түбәндә күрергә мөмкин:

1) Татар телендә: ИР 1) Аерым бер сыйфатларга, табигый үзенчәлекләргә ия буларак, хатын-кыз затына капма-каршы җенестәге кеше.

ИР+ЛЕ с. Кияүгә чыккан, ире булган, ирдәге.

ИР+ЛЕК и. 1) Ир кеше булу.

Төрек телендә: ER – 1) ир, чын ир кеше; 2) солдат; 3) *сөйл.* ир (хатының ире).

KOCA – ир (хатынның ире);

KOCA – картаю, олыгаю;

KOCA+LI – ирле, иргә чыккан хатын;

KOCAK+LIK – ир булу (хатынның ире булу); 2) картлык.

“Ир” терминыннан татар телендә дә төрек телендә дә берничә сүз ясалган: “ирле”, “ирлек”. Төрек телендә “ир” сүзе ике вариантта кулланылган.

2) Татар телендә: АТА ис. Баласы булган ир кеше [2: 53].

АТА+ЛЫ – атасы булган кеше.

Төрек телендә: BABA – ата, әти.

BABA+CIL – атасын ярата торган, атачыл;

BABA+LI – аталы.

“Ата” терминыннан татар һәм төрек телләрендә “аталы” сүзе ясалган. Шулай ук, төрек телендә ясалган “атачыл” сүзе дә термин булып киткән.

Шулай итеп, татар, башкорт һәм төрек телләрендәге туганлык атамалары мәгънәләре ягыннан бер-берсенә охшаш, әмма аермалы яклар да бар. Аермалыклар нигездә, мәгънә киңлеге һәм сүз ясалышына бәйле. Мисаллардан күренгәнчә, туганлык атамалары арасында берничә мәгънәне белдергән терминнар да күзәтелә, бер мәгънә берничә термин белән дә бирелә ала.

Лексик-семантик берәмлекләр арасындагы системалы бәйләнешләр төрле факторларга бәйле була һәм төрле дәрәҗәдә чагылыш таба. Сүзләрне төркемләү, чынбарлыктагы күренешләрнең уртак якларына бәйле дә, семантик уртаклыкка, охшашлыкка бәйле дә булырга мөмкин. Әлеге үзенчәлекләрне өйрәнү тел белеме, тел тарихы өчен бик тә әһәмиятле.

**Әдәбият**


1. Акилова М.Ф. Некоторые термины родства в турецком, башкирском и русском языках // Вестник башкирского университета – 2019. – Т.24 – №3. – С. 2-3.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
3. Рамазанова Д.Б. Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 287 б.


## ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУДА ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР
### (сан сүз төркемен өйрәтү мисалында)


*Хәсбиуллина Г., КФУ, V курс студендты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Нуриева Ф.Ш.*


Әлеге эшебездә мәктәп укучылары белән “Сан” темасын үзләштергәндә информацион-коммуникатив технологияләрне куллану чараларын яктырттык. Лингвистик һәм коммуникатив компетенцияләр сөйләм теленең үсешен тәэмин итә. Моның өчен һәр дәрестә аралашу өчен уңай шартлар булдырылырга тиеш. Сөйләм эшчәнлеге төрлечә оештырылырга мөмкин: уку, сөйләшү, язу, аудио материаллар тыңлау. Телне аралашу аркылы өйрәтергә кирәк. Хәзерге вакытта укучыларның игътибарын җәлеп итәр өчен укытучыга күп тырышлык куярга кирәк. Бу яшәү темпының тизлегенә һәм яшьләр арасында социаль челтәрләрнең актив кулланылуына бәйле. Үзләренең яшь үзенчәлекләре буенча да, хәзерге тормыш реалияләренә бәйле дә мәктәп укучылары иътибарны озак вакыт дәвамында бер мәгълүматта тота алмый. Шул исәптән, материалны булдыра алганча укучыга кызыклы, заманча итеп бирү кулай. Информацион-коммуникатив чаралар күрсәтмәлелекне арттыра һәм укучыга яңа материалны үзләштерергә, аңларга, истә калдырырга ярдәм итә.

Информацион технологияләр – мәгълүматны эзләү, җыю, саклау, эшкәртү һәм тарату процесслары һәм методлары, аларны гамәлгә ашыру алымнары. Информацион-коммуникатив технологияләр кулланып укыту – ул укытучының укучыга мәгълүматны тапшыру,

укучының аны кабул итү, аңлау, истә калдыру һәм мәгълүмати-коммуникацион чаралар ярдәмендә дөрес куллану белән идарә кылу гамәлләре җыелмасы. Бу очракта ИКТ укыту нәтиҗәлелегенең дидактик “көчәйткече” ролен үти.

Безнең фикеребезчә, дәрескә презентацияләр әзерләү уңышлы. Иҗади хәзерләнгән презентация укучының игътибарын җәлеп итәргә ярдәм итә. Ясаучы тарафыннан уңышлы төсләр, кызыклы һәм темага туры килерлек рәсемнәр сайланылырга тиеш. Популяр PowerPoint программасында хәтта гади уеннар да ясау мөмкинлеге бар. Кабинетта интерактив такта булса, укучылар, аның янына чыгып, дөрес вариантны сайлап, шуңа төртеп күрсәтә ала.

Күп методистлар уен аша укытуны эффектив күрә, шул исәптән уен рәвешендә ИКТ ярдәмендә саннарны өйрәнү ысулларын да барладык.

“Kahoot” платформасында тестларны уен рәвешендә үткәрүе бик җиңел. Моның өчен проектор һәм укучыларның телефоннары кирәк. Экранда сорау һәм төрле төстәге шакмакларда җаваплары языла, ә укучыларның телефоннарында шул төсләрдәге шакмаклар барлыкка килә. Укучылар, кирәкле төстәгесен сайлап, шуңа басалар. Җаваплар өчен алар балл җыя һәм тест ахырында җиңүчеләр билгеләнә, бу укучылар өчен стимул булып тора. Әлеге эшне индивидуаль форматта да, парларда да, төркемнәрдә дә оештырып була. “Kahoot” тестларда фотолар, видеоязмалар һәм музыка кулланырга мөмкинлек бирә. Бу саннарны өйрәнгәндә укучыларга аудирование рәвешендә оештырылган биремнәрне үтәргә ярдәм итә. Мәсәлән, биремгә җырдан өзек куеп, “Әлеге өзектә нинди сан ишеттегез?” дип сорау куярга була. Гамәлдә укучылар әлеге платформада эшләнгән тестларны яратып башкара.

“Online Test Pad” ярдәмендә онлайн тестлар, сораулыклар, кроссвордлар эшләү мөмкинлеге бар. Әлеге сайтта укучыларның белемнәрен тикшерү өчен бик күп уңайлы шартлар тудырылган. Монда укучылар үзләре дә саннар турында кроссворд төзи ала. Укучылар бер-берсе ясаган кроссвордларны чишүне ошата.

“Quizlet” онлайн-сервисында да белемнәрне ныгытып була. Әлеге платформада телне өйрәткәндә карточкалар зур уңыш белән кулланыла, укытучылары арасында да Quizlet бик популяр. Саннарның төркемчәләрен карточкалар ярдәмендә аңлатып була. Аеруча, карточкаларга тәрҗемәне, төркемчә исемен яки аңлатманы сүзләр белән генә түгел, төрле рәсемнәр белән бирү уңышлы, чөнки болай эшләгәндә, укучыда ассоциацияләр барлыкка килә, шул рәвешле мәгълүмат яхшырак истә кала. “Quizizz” платформасы да интерактив тестлар өчен бик уңай.

Әлеге платформалар шунысы белән уңайлы, алар тестлар нәтиҗәсен үзләре формалаштыра. Укучылар эшләгән тестларның нәтиҗәсе укытучыга әзер документ булып килә. Шулай ук укытучылар югарыда күрсәтелгән сайтларда үзләре яңа тестлар эшли ала һәм башка укытучының әзер тестларын да куллана ала.

“PowToon” – анимация ясау өчен сервис. Мультфильм күрсәтеп, укучыларга саннарны истә калдырырга ярдәм итәргә була. Анимацияләргә тавыш кую мөмкинлеге бар, бу – укучыларга саннарның дөрес әйтелешен истә калдырырга яхшы чара. Әлеге сайтта укучыларга үзләренә дә мультфильм ясарга тәкъдим итәргә мөмкин. Безнеңчә, мәктәп укучыларына кызыклы булган социаль челтәрләрне дә эффектив кулланып була. Мисал өчен, теләге булган укучыларга яңа өйрәнгән саннарны кулланып TikTok өчен видео төшерергә тәкъдим итәргә.

Нәтиҗәдә, без татар телен өйрәткәндә, информацин-коммуникатив технологияләр кулланып, мәгълүмат белән таныштыруга иҗади якын килү өчен күп төрле чаралар кулланып булганын күрәбез. Информацион-коммуникатив технологияләр хәзерге заман балалары һәм яшүсмерләре өчен бик якын, шул исәптән, безнең фикеребезчә, аларны татар теле дәресләрендә куллану эффектив укытуга китерергә мөмкин.

**Әдәбият**


1. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзъясалышы – Казан: Мәгариф, 2009. – 271 б.
2. Харисов Ф.Ф. Рус мәктәбендә татар теле укыту методикасы (Методика преподавания татарского языка в русской школе) лекцияләренең кыскача конспекты – Казан: 2014 – 56 б.
3. Шәкүрова М.М. Татар мәктәпләрендә татар телен укыту методикасы – Казан: 2014. – 61 б.
4. Формирование коммуникативной и языковой компетенции на уроках татарского языка и литературы [Электрон ресурс] URL: https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2018/10/18/iz-opyta-raboty-formirovanie-kommunikativnyh
5. Информационные технологии [Электрон ресурс] URL: https://dic.academic.ru/dic.nsf/ruwiki/75511


